PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№2 (302) – ФЕВРАЛЬ 2017

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

ТР Президентының 60 адымы

Эшлисе килә

Төрки каганлыгы: тарих һәм мәдәният

ТИМУР ИБРАҺИМОВ: ИР-ЕГЕТ ВАТАН АЛДЫНДАГЫ БУРЫЧ ТӨШЕНЧӘСЕН АҢЛАРГА ТИЕШ

4 612750 670011

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Троицкая
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская,
Олеся Бондаревская
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Авторлар: Гөлүсә Закирова, Катерина Котова,
Руфия Рәхмәтуллина, Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Ната Смирнова, Александр Эшкинин
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин,
Олег Бурилов
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Диана Сиражиева
Тышлыкта Ната Смирнова фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: **3500** данә,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми. «Промо» һәм «Медиа» рубрикалары материаллары реклама-коммерция нигезендә басыла.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә **басылды**: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-364

Басарга кул куелды: 20.02.2017

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры:
Нина Әхмәтшина, nivlana@tatmedia.com,
тел. (843) 222-09-76

Сату бүлеге белгече:
Гөлфия Фәттахова

Махсус проектлар бүлеге белгече:
Жәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

КУРГАШ СОЛДАТ КЫНА ДИМӘГЕЗ...

Февраль – мәһабәт, баһадир, куркәм ай һәм ир-егетләргә юнәлтелгән продукцияне тәкъдим итүче үзәкләр, нокталар, интернет-кибетләр, үз товарларын сату өчен, аның нәкъ менә шушы сыйфатларына басым ясыйлар да. Аеруча галстук һәм ислемай белән сәүдә итүчеләр тырыша, чөнки боларга булган сорау февраль аенда чиктән тыш арта. Башка төр җитештерүчеләр дә артта калмаска тырыша, моның өчен үз товарларына, әлбәттә, тирән мәгънә салалар. Армия хезмәтенә ике-өч ел гомерен багышлаган баһадирлар, килешәсездер, бәйрәм көннәрендә сайлау хокукына ия булырга тиешләр: әлеге дә баягы галстуктан алып, вертолётка кадәр! Менә шунда күренәчәк тә инде: кем тормыш иптәшеннән уңган, ә кем – юк...

Безнең журналны укып баручы баһадирларга бәхет икеләтә елмайды. Бу санда барысы да алар өчен – геликоптерлар да бар биредә, дилбегәсе аларның ышанычлы кулларында булган олпат оешмаларның яңадан-яңа җиңүләре турындагы язмалар да. Бер нәрсәне генә онытып җибәргәнбез – кургаш содатларны. Хәер, хәзерге ир-егетләрне кайчандыр Андерсен үз әкиятендә данлаган бу уенчыклар белән шаккатырып булмас та иде. Социализм чоры предметларына исләре китүчән коллекционерлар булмасалар, билгеле. Ә бит юкка исләре китми коллекционерларның бу каһарманга! Чөнки нәкъ менә шул кургаш солдатлар тулы бер буында тәвәккәллек белән кыюлык тәрбияләгән дә, аннан инде аларны армия чын ир-егет иткән. Хәтерегездәме: «Кургаш солдатның күңеле шулкадәр нечкәрде ки, күзләреннән чак кына кургаш яшьләр тәгәрәп төшмәде, ләкин ул нәкъ вакытында исенә төшерде – солдатка суган суы сыгып тору килешми... Шуннан соң, ул гәүдәсен тагын да турайтыбрак басты һәм мылтыгын тагын да ныграк кысты...»

Бәйрәмегез белән Сезне, кадерле Ватанны саклаучылар!
Яратылып яшәгез һәм бәхетле булыгыз!

СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
864 сум 24 тиен

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ



Рәссам: Аида Илнамова

ФЕВРАЛЬ. БӨГЕЛМӘ РАЙОНЫ. СОЛДАТ ПИСМӘНКӘСЕ АВЫЛЫ.

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Президентның 60 адымы.
7 ел. Үсеш нокталары

32. Көн кадагында.
Эшсезлекне ничек җиңәргә

36. Энциклопедияне молекулага ничек тупларга.
Оптик мәгълүматны язу һәм саклауның яңа принцибы

38. Кара алтынга тугрылар.
Академик Мәзһәровның дөньякүләм ачышлары

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

46. «Татарстан»ның алтын запасы.
«Татарстан» фотобанкы нинди фотоларга баеды

52. Кече Ватан патриотлары.
Кадыйр Сибгатуллин беренче шигырен кемгә багышлаган

56. Җирдәге иң шәп урын.
Бөгелмә һәм аның хикәяләре

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

62. Халык ашлары.
Өлеш безгә кайдан килгән

66. Тыныч профессия генераллары.
Армия чын ир-ат булырга ничек ярдәм иткән

74. Төрки каганлыгы.
Тарих һәм мәдәният

78. Георгий Ибушев.
Ни өчен җырчы шагыйрь дә була ала

82. Гран-при – китап бастыру!
«Татарстан» журналының әдәби премиясе

84. Яңа китапларга күзәтү.
Әдипләр берлеге нәрсә ул

91. Татар авыллары.
Морт авылы тарихы

94. Борынгы заманнарда булган, диләр…
Кышкы су кызлары турында легенда

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:

www.protatarstan.ru

PRESSA.RU

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

13.02

Вячеслав Володин, Россия Федерациясе Федераль Җыенының Дәүләт Думасы Рәисе, – Татарстанга сәфәре вакытында:

– Депутатлар үз округларында тагын да нәтиҗәлерәк эшли алсын өчен, без Татарстан программистлары белән бергә депутатлар өчен махсус программа эшләячәкбез. «Халык контроле» программасын үрнәк итеп алуыбыз да ихтимал.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

13.02

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты, – Иннополиста укытучылар һәм студентлар белән очрашу вакытында:

– Беренче елны парк һәм скверларны төзекләндерүдән башладык, аннары игътибар су саклау зоналарына күчте. Быел исә без әлеге ике программаны берләштердек һәм «Җәмәгать урыннарын үстерү» дип атадык. Бирегә яр буйлары да, парк зоналары да, җәяүлеләр өчен эшләнгән үзәк урамнар да, йорт тирәсендәге территорияләр дә керә. Бүгенге көндә тәҗрибәбезне Россиянең Төзелеш һәм ТКХ министрлыгы өйрәнә, ә Татарстанның күп кенә башка проектлары илебезнең бүтән төбәкләрендә кулланыла инде.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

08.02

Доктор Йосыф бин Әхмәд әл-Осеймин, Ислам хезмәттәшлеге оешмасының Генераль сәркатибе, – Җиддәдә (Согуд Гарәбстаны) Татарстан Президенты белән очрашуы вакытында:

– Татарстанда дөньяның барлык дин вәкилләренең тату яшәвен яхшы беләм. Республикада мөселманнар да, мөселман булмаганнар да үзләрен яхшы хис итә, алар барысы да бертуганнар кебек яши. Киләчәктә дә шулай дәвам итәр, дип ышанам.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

7 ел президентлык дәверендә президент **НИЧӘ** адым ясады

Эшсезлекне **НИЧЕК** җиңәргә

Энциклопедияне **НИЧЕК** молекулага тупларга

Кара алтынга тугрылар **КАЙДА** эшли

PRESSA.RU

ПРЕЗИДЕНТНЫҢ 60 АДЫМЫ

Моннан җиде ел элек, 2010 елның 25 мартында, Рөстәм Миңнеханов рәсми рәвештә Татарстан Президенты вазыйфасына кереште. Россиянең башка төбәкләре белән чагыштырганда, республиканың инвестицияләр өчен иң уңайлы шартлар тудыруы, губернаторларның эш нәтиҗәлелеге исемлегендә (Гражданлык җәмгыяте үсеше фонды мәгълүматлары буенча) Татарстан җитәкчесенең өченче урында баруы – Президент Рөстәм Миңнеханов һәм аның командасының җиде еллык эшчәнлегенә тел шартлатып куярлык бәя. Икенче яктан карагандa, башкарылган эшләрнең масштабын чын-чынлап бәяләр өчен, кайчак коры, гомуми саннардан читкәрәк китеп, төгәл фактларга күз салу уңышлырак. «Татарстан» нәкъ менә шул юлны тәкъдим итә дә. Без бу елларга адымлап сәяхәт ясап, Татарстанның икътисадына, социаль өлкәсенә кагылышлы иң әһәмиятле вакыйгаларның кайберләрен генә сайлап алдык.

1 **01.07.2010 «АЛАБУГА» МАХСУС ИКЪТИСАДЫЙ ЗОНАСЫНДА «П-Д ТАТНЕФТЬ-АЛАБУГА ПЫЯЛА-СҮС» УРТАК ПРЕДПРИЯТИЕСЕ АЧЫЛДЫ.** Иң заманча технологияләр нигезендә төзелгән яңа завод сәнәгать һәм көнкүрешнең бик күп тармакларында кулланыла торган продукция – пыяла-сүс эшләп чыгара.

2 **27.10.2010 ТАТАРСТАНДА «ШӘЛЕ – САЕСКАН ТАВЫ» АВТОМОБИЛЬ МАГИСТРАЛЕ АЧЫЛДЫ.** **Әлеге юл – «Европа – Көнбатыш Кытай» транспорт коридорының беренче участогы.**



3 **03.09.2011 ТАТАРСТАННЫҢ МАМАДЫШ РАЙОНЫНДА, М-7 ЮЛЫНДА, НОКРАТ ЕЛГАСЫ АША ЯҢА КҮПЕР АЧЫЛДЫ.**

4 **12.2011 «ТАНЕКО» НЕФТЬ ЭШКӘРТҮ ҺӘМ НЕФТЬ ХИМИЯСЕ ЗАВОДЛАРЫ КОМПЛЕКСЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЧИРАТЫ КУЛЛАНУГА ТАПШЫРЫЛДЫ.** «ТАНЕКО» заводының проектта билгеләнгән куәтенә ирешеп, 7 млн тонна нефть эшкәртә башлавы Татарстанга Россия төбәкләре арасында бу тармакта алтынчы урынга күтәрелергә мөмкинлек бирде. «ТАНЕКО» – советлар чорыннан соңгы 30 елда, нульдән башлап, шундый зур масштабтагы инвестицияләр бәрабәренә төзелгән беренче сәнәгать объекты.

5 **19.01.2012 САБА РАЙОНЫНДА УРМАН СЕЛЕКЦИЯ-ОРЛЫКЧЫЛЫК ҮЗӘГЕ АЧЫЛДЫ.**

6 **04.04.2012** «Алабуга» махсус икътисадый зонасында **ROCKWOOL КОМПАНИЯСЕНЕҢ ТАШ МАМЫК ҖИТЕШТЕРӘ ТОРГАН ЗАВОДЫ ЭШЛИ БАШЛАДЫ.**

7 **25.06.2012 ТҮБӘН КАМАДАГЫ «ТАИФ-НК» ААҖ ЗАВОДЫНДА ҖИТЕШТЕРҮ ТУЛЫ КУӘТЕНӘ ЭШЛӘП КИТТЕ** һәм «Евро-5» экологик стандартындагы дизель ягулыгын сатуга чыгара башлады.

8 **25.08.2012** «Камский Бекон» компанияләр төркеменең (Яр Чаллы) **ЮГАРЫ ТЕХНОЛОГИЯЛЕ ЯҢА** дуңгызчылык комплексы сафка басты. Аның җитештерү куәте, тере авырлыкта исәпләгәндә, елына 14 мең тоннадан артык дуңгыз итен эшкәртүне күздә тота.

9 **09.04.2013** Лаеш районы Усады авылында **«ICL КПО ВС» КОМПАНИЯСЕНЕҢ ЯҢА СӘНӘГЫЙ ЭЛЕКТРОНИКА ЗАВОДЫ ЭШЛИ БАШЛАДЫ.**

10 **18.04.2013 «ТҮБӘН КАМА НЕФТЕХИМ» ААҖ КОМПАНИЯСЕНДӘ АБС-ПЛАСТИКЛАР ҖИТЕШТЕРҮЕН КУЛЛАНУГА ТАПШЫРУ ТАНТАНАСЫ УЗДЫ.**

11 **11.05.2013 ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНДА БЕРЬЮЛЫ ӨЧ МЕТРО СТАНЦИЯСЕ – «ЯШЬЛЕК», «ТӨНЬЯК ВОКЗАЛ» ҺӘМ «АВИАТӨЗЕЛЕШ» СТАНЦИЯЛӘРЕ АЧЫЛДЫ.**

Фото: president.tatarstan.ru, k-metro.ruz.net, tatcenter.ru

PRESSA.RU

12 **06.2013 РОССИЯНЕҢ ИҢ ЗАМАНЧА СТАДИОННАРЫНЫҢ БЕРСЕ – «КАЗАН АРЕНА» СТАДИОНЫ АЧЫЛДЫ.** **Казанда Универсиадага барлыгы 64 спорт объекты әзерләнде, 28 спорт корылмасы әлеге мөһим вакыйга өчен махсус төзелде.**

13 **18.06.2013 ТАТАРСТАННЫҢ КАМА ТАМАГЫ РАЙОНЫ СӨЙКИ БИСТӘСЕНДӘ ГИПС НИГЕЗЕНДӘГЕ ТӨЗЕЛЕШ МАТЕРИАЛЛАРЫ ҖИТЕШТЕРӘ ТОРГАН ЯҢА ЗАВОД ЭШЛИ БАШЛАДЫ.**

14 **20.06.2013 «КАЗАН» ХАЛЫКАРА АЭРОПОРТЫНДА ЯҢА ОЧЫП КИТҮ-УТЫРУ ПОЛОСАСЫ АЧЫЛДЫ, ПАССАЖИР ПЕРРОНЫ ҮЗГӘРТЕП КОРЫЛДЫ. ШУННАН АЛДАРАК МОНДА ЯҢА ТЕРМИНАЛ ЭШЛИ БАШЛАГАН ИДЕ.**

15 **25.06.2013 ТАТАРСТАН ЦИФРЛЫ ТЕЛЕВИДЕНИЕНЕҢ ИКЕНЧЕ МУЛЬТИПЛЕКСЫ ЭФИРГА ЧЫККАН ИҢ БЕРЕНЧЕ ТӨБӘК БУЛДЫ.**
Моңарчы, 2012 елның мартында, республикада 10 төп федераль каналдан торган беренче мультиплексның цифрлы тапшырулары башланган иде. Хәзер инде цифрлы тапшыруларны Татарстанның 70% халкы карый ала.

16 **27.06.2013 КАЗАНДА ҮЗГӘРТЕП ТӨЗЕЛГӘН ЛЕНИН ДАМБАСЫ ҺӘМ КАЗАНСУ КҮПЕРЕ БУЕНЧА АВТОМОБИЛЬ ХӘРӘКӘТЕ АЧЫЛДЫ.** **Гомумән алганда, Татарстан башкаласында Универсиадага 38 км дан артык озынлыктагы 17 юл салынды һәм төзекләндерелде, 11 транспорт чишелеше, 28 җәяүлеләр кичүе төзелде.**

17 **29.06.2013 КАЗАНДА БӨТЕНДӨНЬЯ ҖӘЙГЕ УНИВЕРСИАДА АВЫЛЫ РӘСМИ РӘВЕШТӘ ЭШЛИ БАШЛАДЫ.**

18 **06.07.2013 КАЗАНДА АВИАЦИЯ СӘНӘГАТЕ ӨЧЕН КОМПОЗИТ ДЕТАЛЬЛӘР ҖИТЕШТЕРӘ ТОРГАН «КАПО-КОМПОЗИТ» ЗАВОДЫ ЭШЛИ БАШЛАДЫ.**

19 **07.07.2013 «КАЗАН АРЕНА» СТАДИОНЫНДА БӨТЕНДӨНЬЯ ҖӘЙГЕ СТУДЕНТЛАР УЕННАРЫ АЧЫЛДЫ.**

20 **05.09.2013 МАМАДЫШ РАЙОНЫНДА НОКРАТ ЕЛГАСЫ АША КҮПЕРНЕҢ ИКЕНЧЕ ЧИРАТЫ КУЛЛАНУГА ТАПШЫРЫЛДЫ.**

21 **09.09.2013 «АЛАБУГА» МАХСУС ИКЪТИСАДЫЙ ЗОНАСЫНДА ГЕРМАНИЯНЕҢ SARIA КОНЦЕРНЫ ИТ ЭШКӘРТҮ КАЛДЫКЛАРЫН УТИЛЬЛӘШТЕРҮ БУЕНЧА РОССИЯДӘ БЕРЕНЧЕ ЗАВОДЫН ЭШЛӘТЕП ҖИБӘРДЕ.**

22 **12.09.2013 БИЕКТАУ БИСТӘСЕНДӘ ЯҢА БОЗ САРАЕ АЧЫЛДЫ. БУ – ТАТАРСТАН ӨЧЕН 38 НЧЕ ШУНДЫЙ СПОРТ КОРЫЛМАСЫ БУЛДЫ.**

23 **12.10.2013 СВИЯЖСК УТРАУ-ШӘҺӘРЕНДӘ ТАРИХИ ҺӘЙКӘЛЛӘР ТӘКЪДИМ ИТЕЛДЕ.** «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Свияжск утрау-шәһәре» комплекслы программасы кысаларында Изге Ана Успение монастыреның Кирмән өсте чиркәве, Троица чиркәвенең иконостасы, Туганнар корпусы, Иоанн-Предтеча монастыреның «Барлык Кайгыручылар Шатлыгы» соборы һәм Сергиев чиркәве төзекләндерелде.

24 **21.12.2013 ЛАЕШТА ЯКТЫЛЫК-ДИОДЛЫ ЯКТЫРТКЫЧ ЛАМПАЛАР ҖИТЕШТЕРӘ ТОРГАН «ФЕРЕКС» ЗАВОДЫ ЭШЛИ БАШЛАДЫ.**

25 **14.04.2014 «ТҮБӘН КАМА НЕФТЕХИМ» ААҖ ТАНТАНАЛЫ РӘВЕШТӘ ПОЛИСТИРОЛ ҖИТЕШТЕРҮ ЛИНИЯСЕН ЭШЛӘТЕП ҖИБӘРДЕ.**

26 **20.08.2014 КАЗАНДА БОЛГАР ТАРИХИ-АРХИТЕКТУРА КОМПЛЕКСЫН ЮНЕСКОНЫҢ БӨТЕНДӨНЬЯ МИРАСЫ ИСЕМЛЕГЕНӘ КЕРТҮ ТУРЫНДА СЕРТИФИКАТ ТАПШЫРУ ТАНТАНАСЫ УЗДЫ.**

27 **25.08.2014 БӨГЕЛМӘДӘ ТАТАРСТАННЫҢ КӨНЬЯК-КӨНЧЫГЫШ ТӨБӘГЕ ӨЧЕН ИҢ КУӘТЛЕ КАТНАШ АЗЫК ЗАВОДЫ САФКА БАСТЫ.**

28 **29.08.2014 «АЛАБУГА» МАХСУС ИКЪТИСАДЫЙ ЗОНАСЫНДА «ҖОШКУНОЗ» ТӨРЕК КОМПАНИЯСЕНЕҢ АВТОМОБИЛЬЛӘР ӨЧЕН КУЗОВ ДЕТАЛЬЛӘРЕ ҖИТЕШТЕРҮ ЦЕХЫ ЭШЛИ БАШЛАДЫ.**

29 **24.09.2014 «АЛАБУГА» МАХСУС ИКЪТИСАДЫЙ ЗОНАСЫНДА «КАСТАМОНУ ЭНТЕГРЕ» ТӨРЕК КОМПАНИЯСЕНЕҢ МДФ-ПАНЕЛЬЛӘР ҺӘМ АГАЧ ИДӘН ӨСЛЕКЛӘРЕ ЧЫГАРА ТОРГАН ЗАВОДЫ ЭШЛӘТЕП ҖИБӘРЕЛДЕ.**

30 **08.12.2014 «АЛАБУГА» МАХСУС ИКЪТИСАДЫЙ ЗОНАСЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ 600 МВТ КУӘТКӘ ИЯ ЯҢА ЭЛЕКТР БҮЛҮ-ТАПШЫРУ ПОДСТАНЦИЯСЕ КУЛЛАНУГА ТАПШЫРЫЛДЫ.** Әлеге подстанция резидент предприятиеләрне энергия белән иң югары ышанычлылык дәрәҗәсендә – беренче категориядә тәэмин итә.

31 **12.12.2014 ЯР ЧАЛЛЫДА 6,2 КИЛОМЕТР ОЗЫНЛЫКТАГЫ ЯҢА ТРАМВАЙ ЮЛЫ КУЛЛАНУГА ТАПШЫРЫЛДЫ.** Ул шәһәрнең яңа һәм иске өлешләрен тоташтырды.

32 **14.04.2015 АЗӘРБАЙҖАННЫҢ ГЯНДЖА АВТОМОБИЛЬ ЗАВОДЫНДА «КАМАЗ»ЛАР ҖЫЮ ЛИНИЯСЕ АЧЫЛДЫ.**

33 **22.04.2015 ЯР ЧАЛЛЫДА ТАБИГЫЙ ГАЗ БЕЛӘН ЙӨРИ ТОРГАН «КАМАЗ»ЛАР ЧЫГАРЫЛА БАШЛАДЫ.**

34 **15.05.2015 «АЛАБУГА» МАХСУС ИКЪТИСАДЫЙ ЗОНАСЫНДА УГЛЕРОД СҮСЕ ҖИТЕШТЕРӘ ТОРГАН «АЛАБУГА-СҮС» ЗАВОДЫН АЧУ ТАНТАНАСЫ УЗДЫ.**

35 **23.05.2015 ТАТАРСТАНДА СОЦИАЛЬ ИПОТЕКА ПРОГРАММАСЫ БУЕНЧА ЕЛ БАШЫННАН БАРЛЫК МӘЙДАНЫ 19,1 МЕҢ КВ. МЕТР ТӘШКИЛ ИТКӘН 348 ФАТИРЛЫ 32 ЙОРТ КУЛЛАНЫШКА ТАПШЫРЫЛДЫ.**

PRESSA.RU

36 **30.05.2015 «ПАРКЛАР ҺӘМ СКВЕРЛАР» ПРОГРАММАСЫН ТОРМЫШКА АШЫРУ КЫСАЛАРЫНДА** Татарстан Республикасының 44 районындагы 104 объектта эш башлана.

37 **09.06.2015 ТАТАРСТАННЫҢ ЮГАРЫ ОСЛАН РАЙОНЫНДА ТАНТАНАЛЫ РӘВЕШТӘ ЯҢА ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕ АЧЫЛДЫ.**

38 **17.07.2015 «АЛАБУГА» МАХСУС ИКЪТИСАДЫЙ ЗОНАСЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ 500 КВ КУӘТЛЕ ЩЁЛОКОВ ПОДСТАНЦИЯСЕН АЧУ ТАНТАНАСЫ УЗДЫ.**

39 **10.08.2015 КАЗАН 2019 ЕЛДА WORLDSKILLS COMPETITION ЯРЫШЛАРЫН УЗДЫРУ ХОКУКЫН ЯУЛАДЫ.**

40 **18.08.2015 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ЛАЕШ РАЙОНЫНДА БЕРЬЮЛЫ ӨЧ ЯҢА БАЛАЛАР БАКЧАСЫ АЧЫЛДЫ.** Республикада тиңдәше булмаган 30 социаль программа эшли, аларның күбесе авыл җирлекләрен үстерүгә йөз тота.

41 **18.08.2015 ЛАЕШ РАЙОНЫНДА ЯҢА «НӘФИС-БИОПРОДУКТ» МАЙ ЭКСТРАКЦИЯ ЗАВОДЫ ЭШЛӘТЕП ҖИБӘРЕЛДЕ.**

42 **01.09.2015 КАЗАННЫҢ ЯҢА САВИН РАЙОНЫНДА 1375 УКУЧЫГА ИСӘПЛӘНГӘН ЯҢА МӘКТӘП АЧЫЛДЫ.**

43 **03.09.2015 «АЛАБУГА» МАХСУС ИКЪТИСАДЫЙ ЗОНАСЫНДА ҖИҢЕЛ МАШИНАЛАР ӨЧЕН ДВИГАТЕЛЬЛӘР ҖИТЕШТЕРӘ ТОРГАН ЗАВОД ЭШЛӘП КИТТЕ.** Бу – Россиядә мондый юнәлештәге беренче чит ил компаниясе заводы. Моңарчы илебездә җыела торган чит ил машиналары өчен моторлар чит илләрдән кертелә иде.

44 **10.09.2015 «РОССИЯ ВЕРТОЛЕТЛАРЫ» ХОЛДИНГЫНА КЕРГӘН КАЗАН ВЕРТОЛЕТ ЗАВОДЫ ЯҢАРТУ-КАМИЛЛӘШТЕРҮ ПРОГРАММАСЫ КЫСАЛАРЫНДА** Ми-8/17, «Ансат» һәм Ми-38 вертолетлары өчен яңа агрегат-җыю корпусын сафка бастырды.

45 **05.10.2015 «АММОНИЙ» ААҖ КОМПЛЕКСЫН ГАРАНТИЯЛЕ СЫНАУ ЭШЛӘРЕНЕҢ ТӨГӘЛЛӘНҮЕ ТУРЫНДА АКТ** Токиода Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановка генераль подрядчылар тарафыннан тапшырылды. Аммиак, метанол һәм гранулаланган карбамид җитештерә торган уникаль «Аммоний» комплексы Татарстанның Менделеевск районында төзелде.

46 **21.10.2015 «АЛАБУГА» МАХСУС ИКЪТИСАДЫЙ ЗОНАСЫНДА НЕФТЬ ҺӘМ ГАЗ ТАРМАГЫ ӨЧЕН КОРРОЗИЯГӘ КАРШЫ СЫЕК ӨСЛЕКЛӘР ҖИТЕШТЕРӘ ТОРГАН «3М ВОЛГА» ЗАВОДЫ АЧЫЛДЫ.**

47 **04.11.2015 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ «БОЛГАР ИСЛАМ АКАДЕМИЯСЕН ТӨЗҮ ҺӘМ КАЗАН ИЗГЕ АНА ИКОНАСЫ СОБОРЫН ЯҢАДАН ТОРГЫЗУ ТУРЫНДА» УП-1066 НОМЕРЛЫ УКАЗГА КУЛ КУЙДЫ.**

48 **11.11.2015 «ТАИФ-НК» ААҖ КОМПАНИЯСЕНЕҢ ТҮБӘН КАМАДАГЫ БЕНЗИН ЗАВОДЫНДА «ЕВРО-5» СТАНДАРТЫНДАГЫ БЕНЗИННЫ СӘНӘГЫЙ МАСШТАБЛАРДА ЭШЛӘП ЧЫГАРА БАШЛАУ ТАНТАНАСЫ ҮТТЕ.**

49 12.02.2016 **РОССИЯ ПРЕЗИДЕНТЫ ВЛАДИМИР ПУТИН МЕНДЕЛЕЕВСКИДА АММИАК, МЕТАНОЛ ҺӘМ ГРАНУЛАЛАНГАН КАРБАМИД ҖИТЕШТЕРӘ ТОРГАН «АММОНИЙ» КОМПЛЕКСЫН ТАНТАНАЛЫ РӘВЕШТӘ ЭШЛӘТЕП ҖИБӘРДЕ.** «Һичшиксез, бу – кирәкле проект, аның продукциясе төзелештә дә, авыл хуҗалыгында да, башка тармакларда да киң кулланылачак», – диде Президент.

50 10.03.2016 **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БЕЛӘН «БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН АВИАТӨЗЕЛЕШ КОРПОРАЦИЯСЕ» ГАҖ АРАСЫНДА КИЛЕШҮГӘ КУЛ КУЕЛДЫ.** Әлеге хезмәттәшлекнең иң төп бурычларыннан берсе – Казан авиация заводында «Ту-160» стратегик бомбардировщикларын җитештерүне яңадан җайга салу.

51 06.04.2016 **КАЗАН ОПТИКА-МЕХАНИКА ЗАВОДЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ «СТЕЛЛА-К» ҖИТЕШТЕРҮ ЦЕХЫНА РӘСМИ РӘВЕШТӘ СТАРТ БИРЕЛДЕ,** әлеге ширкәт «Президент-С» күчмә зенит-ракета комплексының очкычларны саклау өчен өр-яңа төрдәге җиһазларын эшләп чыгара.

52 22.04.2016 **ЧАЛЛЫДА «МАСТЕР» КАМА ИНДУСТРИАЛЬ ПАРКЫ (КИП) ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ СУЫТКЫЧ ҖИҺАЗЛАР ҖИТЕШТЕРӘ ТОРГАН «ХАЙЕР» ЗАВОДЫН АЧУ ТАНТАНАСЫ УЗДЫ.**

53 23.05.2016 **КАЗАННЫҢ «ХИМГРАД» ТЕХНОПОЛИСЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ РОССИЯДӘ ЗАМАНЧА ТАРТМА-КАПЧЫКЛАР ҖИТЕШТЕРӘ ТОРГАН БЕРЕНЧЕ ЗАВОД АЧЫЛДЫ.**

54 30.08.2016 **ЧУЛМАН ЕЛГАСЫ АША САЕСКАН ТАВЫ АВЫЛЫ ЯНЫНДАГЫ КҮПЕРНЕҢ ИКЕНЧЕ ЧИРАТЫ АЧЫЛДЫ.**

55 01.09.2016 **«ЧЕЛТӘР КОМПАНИЯСЕ» ААҖ ТУКАЙ РАЙОНЫНДА ЭЛЕКТР ЭНЕРГИЯСЕ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ӨЧЕН ЯҢА ОБЪЕКТ – 220 КВ КУӘТЛЕ «БИГЕШ» ПОДСТАНЦИЯСЕН РӘСМИ РӘВЕШТӘ КУЛЛАНУГА ТАПШЫРДЫ.**

56 16.09.2016 **КАЗАНДА РЕКОНСТРУКЦИЯДӘН СОҢ «КРЫЛЬЯ СОВЕТОВ» ПАРКЫ АЧЫЛДЫ.** Аны төзекләндерү «Парклар һәм скверлар» республика программасы кысаларында башкарылды.

57 08.10.2016 **ТАТАРСТАННЫҢ АЛАБУГА РАЙОНЫНДАГЫ «АЛАБУГА» МАХСУС ИКЪТИСАДЫЙ ЗОНАСЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ «ШИШЕДЖАМ» ТӨРЕК КОМПАНИЯСЕНЕҢ ТӨЗЕЛЕШ ҺӘМ АВТОМОБИЛЬ ПЫЯЛАСЫ ҖИТЕШТЕРҮ БУЕНЧА ИКЕ ЯҢА ЗАВОДЫН ЭШЛӘТЕП ҖИБӘРҮ ТАНТАНАСЫ УЗДЫ.**

58 05.12.2016 «Алабуга» махсус икътисадый зонасында **«FORD KUGA» АВТОМОБИЛЬЛӘРЕ ҖИТЕШТЕРҮНЕ БАШЛАП ҖИБӘРҮ ТАНТАНАСЫ УЗДЫ**.

59 2016 елда **ТАТАРСТАНДА ТӨЗЕЛЕШ ҺӘМ КАПИТАЛЬ РЕМОНТКА БӘЙЛЕ 35 ПРОГРАММА ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛГАН. МОНЫҢ ӨЧЕН 11 МЛРД СУМНАН АРТЫК АКЧА ТОТЫЛГАН.** Аерым алганда, модульле ветеринария пунктлары, полиция участогының вәкаләтле хезмәткәрләре өчен блоклы-модульле административ-торак комплекслар төзү, машина-трактор паркына капиталь ремонт үткәрү программалары тормышка ашырылган.

60 2012-2016 еллар **ЭЧЕНДӘ ТАТАРСТАНДА ЕЛ САЕН ЯКЫНЧА 2 МЛН 400 МЕҢ КВ. МЕТР ТОРАК КУЛЛАНЫШКА ТАПШЫРЫЛГАН. 2016 ЕЛДА 2 МЛН 406 МЕҢ КВ. МЕТР ТОРАК САФКА БАСКАН.**

PRESSA.RU

ТИЗРӘК, ЮГАРЫРАК, **КӨЧЛЕРӘК!**

Бүген Татарстан – Россия Федерациясенең яңадан-яңа биекләкләр яулый торган алдынгы субъектларының берсе. Соңгы елларда тормышка ашырылган киң күләмле проектлар, һәм шулай ук әле башкарылырга тиешлеләре – моңа ачык мисал. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов сүзләре белән әйткәндә, «бүген без, тормыш куйган таләпләргә җавап бирергә өйрәнеп, заманча икътисадның үсеш нокталарына әйләнгән яңа җитештерү комплекслары төзедек». Россиянең әйдәп баручы институтларының берсе булган «Казан Гипронииавиапром» АҖ – безнең күз алдында барган үзгәртеп коруларда турыдан-туры катнашучы. Аның тарафыннан башкарылган эшләр ТР сәнәгате үсешенә яңа импульс өсти.

ЮГАРЫ НӘТИҖӘЛӘР

«Мин Россия Федерациясе авиациянең державасы булды һәм булып кала бирә, дип саныйм. Татарстан кебек төбәкләр авиация сәнәгате үсешенә үз өлешләрен кертергә тиеш», – дип билгеләп үтте Рөстәм Миңнеханов «АКТО-2016» күргәзмәсен ачу тантанасында. Президент республика каршында Татарстан оборона сәнәгатен яңарту буенча зур бурычлар торуына басым ясады. «Казан Гипронииавиапром» белгечләре төп республика проектларын гамәлгә ашыруда катнашып килә. Шуларның иң беренче һәм әһәмиятлеләреннән Казан вертолет заводын реконструкцияләү проекты булды.

Җитештерүнең үзенчәлеге, заводның инновацияләргә булган ихтыяҗы, оборона-җитештерү комплексы предприятиеләре чыгарган продукцияләргә карата катгый таләпләр, проектлаучылардан принципиаль яңа инженерлык карарларының тулы бер рәтен кабул итүне сорады.

Әйтик, «Казан Гипронииавиапром» АҖ проекты буенча КВЗ территориясендә составына «Mazak» («Мазак») җитештерү комплексы да кергән уникаль механик эшкәртү цехы төзелде. Аның белән идарә итүдә кешенең катнашуы таләп ителми. Яңа номенклатура чыгаруны көйләү инструментны һәм эшкәртү белән идарә итүне алмаштыру белән параллель алып барыла, болар барысы да автомат рәвештә башкарыла. Комплексны эшләтү өчен кирәкле шартлар тудыру максатында институт белгечләре тарафыннан ешлыкның инфракызыл диапазонында түбә панельләре аша нур һәм су белән җылытуның инновацияле системасы проектланды һәм төзелде.

Полимер композит материаллардан фюзеляж һәм вертолет калаклары җитештерү КВЗ өчен инновацияле проект булды. Элегрәк заводның үзендә тәҗрибә-конструкторлык участогы эшләгән, анда экспериментал үрнәкләр эшләнгән һәм чыгарылган. Технологияне серияләп җитештерү форматына күчерү этабында «Казан Гипронииавиапром» проектлаучы буларак катнашып китте. Асылда, бу әзер деталь автоклавлау ысулы белән композицион ярымфабрикатлардан ясала торган йомык җитештерү процессы. Материалларны катыру стадиясе тузан, әйләнә-тирә мохит һәм дым даими контрольдә тотыла торган аерым бинада барырга тиеш. Мондый бина-бүлмәләр өчен әйләнә-тирә мохитне контрольдә тотуның аерым системалары проектланды.

Институтның климат җиһазлары белән эшләү тәҗрибәсе вертолетларны ахыргы тапкыр буяу корпусын проектлаганда кулланылды. Элегрәк КВЗда «ачык» ысул белән буяу технологиясе кулланылды, бу вертолетның саклагыч өслеген ясаганда тиешле сыйфатка ирешергә мөмкинлек бирми иде. Тулысынча «Казан Гипронииавиапром» проекты буенча төзелгән яңа корпуста аерым буяу-киптерү камералары эшли, анда вертолетның өслеге буяуны һавасыз сиптерү юлы белән буяла, буяу һәм киптерүнең оптималь температурасы автомат рәвештә контрольдә тотыла. Шулай итеп, нәтиҗәнең иң югары сыйфатына ирешелә. Җитештерүнең чисталыгы вертолет корпусларын һәм кайбер төеннәрен аерым боксларда әзерләү аша тәэмин ителә.

ИРТӘГӘГЕ КӨН КАНАТЛАРЫ

«Казан Гипронииавиапром» бүген проектлауга бәйле берничә дистә өлкәдә эшли, кайвакыт бу стандарт күзаллаулардан шактый ерак проектлар да булырга мөмкин. Шулай да институт өчен «alma mater» –

Реклама

авиация сәнәгате өлкәсенә караган проектлар. Предприятиенең узган гасырның 40 нчы елларында башланган тарихы әлеге өлкәгә бәйле. Бүген Татарстан хөкүмәтенең гаять зур ышанычына, яңа технологияләрнең бай арсеналына таянып, «Казан Гипронииавиапром» тулысынча авиациягә әйләнеп кайтты.

Татарстанның республика оборона-сәнәгать комплексы кебек үк, институт өчен дә иң төп проектларның берсе булып «Туполев» ГАЖ филиалы – «С.П.Горбунов» исемендәге Казан авиатөзелеш заводы җитештерүләрен реконструкцияләү проекты тора. Үз чиратында Ту-214 самолетларын эшләү һәм стратегик бомбардировщикны модернизацияләү әлеге завод эшендә төп юнәлеш булып тора. 2016 елда Татарстан һәм Берләштерелгән авиатөзелеш корпорациясе арасында килешүне имзалау тантанасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов болай дип белдерде: «Ту-160 самолетын модернизацияләү республика тарафыннан җитди фәнни, интеллектуаль кертемнәр кертүне таләп итә. Без моңа әзер, чөнки проект гаять зур потенциалга ия».

С.П.Горбунов ис. КАЗ белән хезмәттәшлек кысаларында институт берничә проект өстендә эшли. Өстенлеклеләрдән берсе – цехны реконструкцияләү, анда яңартылган Ту-160 өчен титан детальләр җитештерү максатында инновацияле эретеп-ябыштыру җиһазлары урнаштырылачак. Бүгенгә «Казан Гипронииавиапром» көче белән 10 мең кв. метрга якын мәйданда иске түбә өслеге алыштырылды, пыяла яктырткычлар 16 мм калынлыктагы поликарбонатлыга алыштырылды, пульт урыны реконструцияләнде һәм башка кайбер эшләр башкарылды.

Моннан тыш, стенд базасын реконструкцияләү һәм техник яктан яңадан коралландыру эшләре алып барыла. Проектның максаты – яңа җиһазларны очышка әзерләү өчен Ту-214 самолеты базасында күпфункцияле сынау комплексын, шул исәптән Ту-214 базасында оча торган лаборатория төзү.

Берләштерелгән авиатөзелеш корпорациясе заказы буенча С.П.Горбунов ис. КАЗ өчен институт инженерлары тарафыннан башкарылган тагын бер проект – композит эшләнмәләр җитештерү заводы. Биредә Sukhoi Superjet 100 («Сухой Суперджет 100») һәм Иркут МС-21 самолетларын серияләп җитештерү өчен композит материаллардан канат җыю һәм аның элементларын төзү производствосы урнаштырылды. Самолет төзелешендә композит материалларны куллану ягулык чыгымнарын 5,5–6%ка киметергә, крейсер тизлекләре өчен канат аэродинамикасын оптимальләштерергә һәм аның белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттырырга мөмкинлек бирә.

С.П.Горбунов ис. КАЗның сынау очышларын башкару, һәм шулай ук граждан самолетларын кабул итү өчен файдаланыла торган «Борисоглебское» аэродромын яңарту проектын эшләү әлеге хезмәттәшлекнең табигый дәвамы булды.

Болар барысы да – Татарстан компанияләре һәм җитештерүләре өчен институт тарафыннан хәл ителә торган бурычларның бер өлеше генә. Әлеге проектларның барысын да тормышка ашыру республика хөкүмәтенең тотрыклы, алгарышлы, инновацияле үсешкә йөз тоткан курсны сайлавы һәм, бернигә дә карамый, әлеге юлдан алга атлавы нәтиҗәсендә мөмкин булды һәм була да. Бу, үз чиратында, иртәгәге көн икътисадын формалаштыручы республика предприятиеләренең күп җитәкчеләре өчен ориентир, аларны хәрәкәтләндерүче көч булып тора.

420127, Казан ш.,
Дементьев ур., 1
Тел. (843) 571-95-48,
факс (843) 571-96-56

75 вместе создаем будущее 1941–2016 КАЗАНСКИЙ ГИПРОНИИАВИАПРОМ

* alma mater – альма матер

АЛГАРЫШ ТРАЕКТОРИЯСЕ

Үсеш, эш белән комплексны тәэмин ителгәнлек, модернизация һәм яңа техника белән җиһазландыру программаларын кабул итү «В.И. Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» ФҖБ» АҖ, «Радиоприбор» АҖ, «Әлмәт «Радиоприбор» заводы» АҖ предприятиеләренең 2011–2015 елларда «Радиоэлектрон технологияләр концерны» АҖ («КРЭТ» АҖ) составындагы иң яңа тарихында әһәмиятле мизгелләрнең берсенә әйләнде. Шунысы символик мәгънәгә ия: программаларны раслау (аерым алганда, «Радиоприбор» АҖ буенча) 2010 елның 24 мартында ТР Премьер-министры Рөстәм Миңнеханов катнашында узган иде. Ә 25 мартта Рөстәм Нургалиевич рәсми рәвештә Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына керешә.

Радиоэлектрон берләшмә предприятиеләрен тулы куәткә эшләтә башлау республика җитәкчелеге, «Ростехнологияләр» Дәүләт корпорациясе («Ростех» ДК) тарафыннан кабул ителгән һәм расланган, «КРЭТ» АҖ белән килештерелгән финансларны сәламәтләндерү программаларына нигезләнеп эшләнгән комплексны чараларга ярашлы рәвештә башкарылды. Әлеге программаларда каралган күрсәткечләрнең үтәлешен Татарстан Президенты үзе даими контрольдә тотты, һәм аларга 2–3 ел дәвамында ирешелде. Кыска вакыт эчендә «В.И.Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» ФҖБ» АҖ, «Радиоприбор» АҖ, «Әлмәт «Радиоприбор» заводы» АҖ тотрыклы үсеш юлына чыгып кына калмадылар, бәлки җитештерү һәм чыгарыла торган продукцияне сату күләмнәренең системалы үсешенә башлангыч бирделәр.

Яңа башлангычлар көчле үсеш белән дәвам итте. Яңа мөмкинлекләргә һәм технология-финанс упкынынан чыгуның реаль планына ия булган радиоэлектрон кластер предприятиеләре, Татарстан Президенты, «Ростех» ДК һәм «КРЭТ» АҖнең актив булышлыгы белән, бу елларда Россия Федерациясенең стратегик предприятиеләре исемлегендә торгызылды һәм «РФ Оборона-сәнәгать комплексын 2020 елга кадәр үстерү» федераль максатчан программасына кертелделәр.

Программа тарафыннан авиация техникасы өчен заманча радиоэлектрон борт аппаратурасы чыгаруны үзләштерү максатларында производствога масштаблы реконструкция һәм технологик җиһазландыру үткәрү буенча инвестицияле проектларны уртак финанслау өчен федераль бюджеттан акчалар җәлеп итү күздә тотыла.

Заводларның җитештерү куәтләрен техник яктан тулысынча һәм этаплап яңадан коралландыру җитештерү әйләнешен үстерү өчен нигез булып тора. Яңартылган цехлар, заманча җиһазлар һәм яңа технологияләр кертү җитештерү процессын тизләтте, үзебездә җитештерелгән детальләргә булган кытлык кебек купьеллык проблемадан котылырга ярдәм итте. Моннан тыш, техниканың соңгы сүзе буенча коралландырылган заманча эш урыннары, югары технологияле автоматлаштырылган җиһазлар һәм предприятиеләрнең амбициоз максатлары югары көндәшлеккә ия продукция чыгарырга булышырлык креатив, инновацион фикер йөртүгә сәләтле яшь белгечләрне елдан-ел күбрәк җәлеп итә.

Әмма «В.И.Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» ФҖБ» АҖ, «Радиоприбор» АҖ, «Әлмәт «Радиоприбор» заводы» АҖ, зур уңышларга ирешсә дә, үсеш темпларын киметми. Оборона продукциясенә дәүләт заказы алу тендерларда катнашуны күздә тота, димәк, предприятиеләр продукциясе ышанычлылык буенча заманча таләпләргә җавап бирергә, иң яхшы техник һәм масса-габарит характеристикаларга ия булырга тиеш. Динамик үсештәге технологияләр фонында аның көндәшлеккә сәләтлелеген саклау җитештерү базасын даими камилләштерүне таләп итә.

Хәзер «В.И.Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» ФҖБ» АҖ, «Радиоприбор» АҖ, «Әлмәт «Радиоприбор» заводы» АҖ «2018–2025 елларда РФ Оборона-сәнәгать комплексын үстерү» федераль программасында катнашуга тәкъдимнәрен әзерли. Предприятиеләрнең яңа проектлары авиация өчен өр-яңа – самолетларны дошман һөҗүменнән саклау системаларын серияләп чыгаруны үзләштерүгә юнәлтелгән. Мондый системалар Россия очу аппаратларының ышанычлылыгын тагын да арттырачак. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов билгеләгән юнәлешләрнең берсе – алгарак китеп эшләүне тормышка ашырырга керешеп, предприятиеләр, киләсе максатчан программа буенча уртак финанслауны көтмичә, булган мөмкинлекләр һәм технологияләр базасында яңа аппаратура җитештерүне үзләштерә дә башладылар инде.

Ронис Шәрипов, «В.И.Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» ФҖБ» АҖ генераль директоры

Рөстәм Абдуллин, «Радиоприбор» АҖ башкаручы директоры

Айрат Хөснетдинов, «Әлмәт «Радиоприбор» заводы» АҖ башкаручы директоры

Реклама

ЯҢА УҢЫШЛАРГА ИРЕШҮ ӨЧЕН НИГЕЗ

Татарстанлыларның тормыш дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән Президент программаларының барлыкка килүе республикабызның кыска гына вакыт эчендә үсешендә шактый алга киткәнлегенә ачык мисал булып тора.

1990 нчы елларда һәм 2000 нче еллар башында икътисадны тотрыклы итү, сәнәгать һәм социаль потенциалны саклау, милләтара һәм конфессияләр арасындагы элемтәләрне ныгыту, бюджет төзи торган предприятиеләрнең технологияләрен һәм юнәлешләрен яңарту мәсьәләләре республика өчен беренче урында тора иде. Аларны уңышлы чишү төбәк тормышының күп өлкәләре өчен ныклы нигез булып торды, һәм 2010 нчы елларда Татарстан җитәкчеләре алдына бөтенләй башка – көндәшлеккә сәләтлелекне үстерү, үсешнең яңа этабына чыгу бурычлары килеп басты.

Шундый актив тышкы икътисадый эшчәнлек алып барганда, көндәшләр итеп дөньякүләм танылган компанияләрне җәлеп итәргә омтылганда, басымны яңадан-яңа технологияләргә һәм прогрессив, квалификацияле белгечләргә ясаган чакта, ниһаять, шактый күп федераль проектларда пилот төбәк статусын алган Татарстан торак инфраструктурасын үстерүне фундаменталь мәсьәләләрнең берсе буларак таныды.

Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев тарафыннан оештырылган халыкны тузган торактан күчерү программасы кысаларында республика һәм аның эре җитештерү предприятиеләренең хезмәттәшлек тәҗрибәсе ТР Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды тормышка ашыра торган чираттагы масштаблы проектта – социаль ипотека программасында зур роль уйнады. Шул ук вакытта торак төзелешенең Рөстәм Миңнеханов үзе күзәтчелек итә торган башка бик күп юнәлешләренә дә башлангыч бирелде. Төрле социаль төркем вәкилләрен – яшь белгечләрне, яшь гаиләләрне, ветераннар һәм ятим балаларны – уңайлы хәзерге заман торагы белән тәэмин итү Татарстанның зур шәһәрләренең дә, кечкенә торак пунктларының да үсешенә йогынты ясады.

Әлеге масштаблы эшнең нәтиҗәләре яңа өйләр һәм фатирларның миллионлаган квадрат метрлары белән исәпләнә. Бүген, Татарстан Президенты министрлыклар, муниципалитетлар, республиканың сәнәгать секторы алдына комплексны, инновацияле юнәлешләрне таләп итә торган күләмле бурычлар куйган вакытта, Дәүләт торак фонды аларны чишүдә актив катнаша. 2012 елдан торакны арендалау программасы кысаларында фонд тарафыннан 1209 фатирлы 20 йорт, шулардан Яр Чаллыда – 118 фатирлы беренче IT-йорт, Россиянең беренче IT-шәһәре Иннополиста 735 фатирлы 14 йорт, Алабугада, Әлмәттә, Югары Осланда, Теләчедә 5 йорт төзелде.

Социаль ипотека өчен йортлар төзелеше программасы кысаларында масштаблары ягыннан югарыда әйтеп үтелгәннәрдән ким булмаган ике проект буенча эш дәвам иттерелә. «Салават күпере» торак комплексында (Казан шәһәре, Залесный бистәсе) 1462 фатирлы 22 йортның 6сы, шулай ук М-14 торак комплексында (Казан шәһәренең Идел буе районы) гомуми мәйданы 5,28 мең квадрат метр булган 89 фатирлы йорт төзелеп беткән һәм файдалануга тапшырылды инде.

Торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү кысаларында бала туганда бирелә торган 200 мең сумлык компенсация, сайланган фатир өчен түләү буенча бурычны каплау өчен ана капиталыннан файдалану мөмкинлеге – болар барысы да Татарстан Республикасында демография хәленә уңай йогынты ясады, бу исә, үз чиратында, Дәүләт торак фонды алдына тагын яңа бурычлар куйды. Социаль-көнкүреш объектларын социаль ипотека йортларының беренче катларындагы торак булмаган биналарда урнаштырырга дигән карар кабул ителде. Шулай итеп, социаль ипотека программасы буенча төзелгән йортларда гомуми мәйданы 8,9 мең квадрат метр булган 4 нче номерлы шәһәр балалар хастаханәсе, шулай ук 5 мәктәпкәчә балалалар учреждениесе («Фиолетовая Корова» ХБМУ, «Сказочный» балалар бакчасы» ХБМУ, «Созвездие» балалар бакчасы» дәүләтнеке булмаган белем бирү учреждениесе, «Школа Кенгуру» дәүләтнеке булмаган белем бирү учреждениесе, «Бала Сити» ҖЧҖ» АКБО») ачылган. Әмма төзелеш һәм үзләренең торак хәлләрен, ә шуның белән бергә тулаем алганда тормыш дәрәҗәсен дә, тамырдан үзгәртергә мөмкинлек алган республика халкы санының саллы булуына карамастан, боларның барысы да – чираттагы этапны узу, Татарстанның билгеләнгән максатларга таба барган чакта яхшы нәтиҗә күрсәтүенә бер дәлил. Ә алда – яңа максатлар.

Реклама

PRESSA.RU

ИРТӘГӘНЕ **КҮЗДӘ ТОТЫП**

Быел үзенең 100 еллыгын билгеләп үтүче Казан «Электроприбор» заводы берничә ел эчендә предприятиене яңадан коралландыру кебек гаять зур бурычны хәл итә, авиация һәм сәнәгать билгеләнешендәге системалар һәм приборлар өлкәсенә караган продукцияне бәйсез җитештерүче сыйфатында яңа базарларга чыга алды.

Павел Шацких, Казан «Электроприбор» заводы ААҖ генераль директоры.

2005 елда Татарстан Премьер-министры Рөстәм Миңнеханов Казан «Электроприбор» заводына эш сәфәре белән килә. Ул сәнәгать предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләренә аеруча игътибар бирә. Җитештерү күләмнәренең елына 250 млн сумны тәшкил итүен белеп, ул предприятие өчен перспективада күләмнәрне 1 млрд сумга җиткерү бурычын куя. 2008 елга ирешелергә тиешле әлеге сан үзенә күрә ерактагы йолдыз, «Электроприбор» җитәкчелегенә замана куйган таләп була. Һәм совет чорыннан калган иске матди-техник базага таянуны дәвам итү урынына, завод тамырдан үзгәртеп кору юлын сайлый. Идарә итү, үзкыйммәтне, бәяләр куюны формалаштыру принциплары яңадан карала. 2007–2008 елларга завод эшчәнлегенең стратегик перспектив юнәлешләре билгеләнә.

Булачак Татарстан Президенты тарафыннан куелган бурыч уңышлы үтәлә. Әлеге максатка ирешү өстендә эшләп, завод билгеле бер динамикага ирешә һәм 2016 елны җитештерү күләмнәрен 1,5 млрд сумга җиткереп тәмамлый. Ләкин әлеге алгарыш җиңел генә бирелми. «Электроприбор» бер генә федераль максатчан программага да керми, һәм шуңа күрә финанс мөмкинлекләрен мөстәкыйль табарга мәҗбүр була. Җиһазлары искергән, белгечләрнең саны бик тиз кыскара барган һәм үзгәртеп кору елларыннан соң ФТИ, КБ белән элемтәләрнең тулысынча югалган һәм берничә ди дә заказлар килмәгән шартларда предприятиедә ниндидер яңа нәрсәләр җитештерү мөмкин булмый. Шуңа күрә иң беренче бурыч техник яктан яңадан кораллану була. Моннан тыш, НИОКР юнәлешен торгызырга һәм аның эшкәртмәләрен җитештерүгә кертергә кирәк. Югары технологияле беренче 10 эш урыны яңартылган цехта ачыла. Иске җитештерү стереотипларыннан бик ерак торган әлеге атмосфера перспективалы яшь белгечләрне җәлеп итә. Әкренләп модернизацияләү процессына бөтен җитештерү тартыла. 2009 елга җитештерүне үстерүнең стратегик юнәлешләре билгеләнә.

Шундый юнәлешләрнең берсе төрле билгеләнештәге видеокүзәтү системаларын җитештерү була. Мәскәү ФТИ белән хезмәттәшлектә завод тәҗрибә-конструкторлык эшкәртмәләренә керешә. Тәҗрибә-конструкторлык бюросы төзелә, аның составына иң тәҗрибәле хезмәткәрләр керә. Әкренләп бюро составы яшь белгечләр белән тулылына. Бүген аның активында – тәмамланган берничә дистә тәҗрибә-конструкторлык эше. Шулай итеп, предприятие бәйсез рәвештә үз идеяләрен алга этәрергә, аларны үстерергә һәм инновацияле продукция сыйфатында аларны сатарга мөмкинлек ала. «Электроприбор»ның видеокүзәтү чаралары өлкәсендәге эшкәртмәләре Россия һәм чит ил базарларында танылуга ирешә. Оборона билгеләнешендәге продукция экспортка бара торган авиация һәм вертолёт техникасы комплектациясенә керә. Завод берничә мәртәбә Россия Федерациясе һәм республикабыз күләмендә прибор төзелеше өлкәсендә елның иң яхшы экспортёры исеменә лаек була. Ләкин, тышкы бәяләр генә түгел, хезмәткәрләрнең хезмәт хакы дәрәҗәсе дә предприятиенең үсеш күрсәткече булып тора, дип саный «Электроприбор» җитәкчелеге. Бүген ул уртача базарныкына туры килә.

Яңа җиһазлар.

Реклама

«Авиакосмик технологияләр һәм җиһазлар» күргәзмәсендә, 2016 елның августы.

Завод өчен социаль юнәлешне кайгырту һәрвакыт мөһим була, хәтта катлаулы кризис елларында да. 1990 нчы елларда төп социаль инфраструктура – тулай торак, ял базасы, балаларны савыктыру лагере, бүген дә медицина хезмәте күрсәтү сыйфаты тиешле югарылыкта кала биргән сәламәтләндерү пункты – сакланып калганга, хезмәткәрләрнең дә төп өлешен югалтмау мөмкин була. Остазлык традицияләре, ветераннар һәм яшь буын арасындагы элемтәләр дә сакланып кала. Болар барысы да яңа корпоратив культураның бер өлешен тәшкил итә. Документ буларак теркәлмәгән, әмма ул тотрыклылык һәм хезмәттәшлекнең уңай атмосферасын тудыра.

«Электроприбор» җитәкчелеге тарафыннан төрле елларда кабул ителгән дөрес карарлар һәм адымнар завод киләчәккә омтылырлык ныклы нигез тудыра. Бу хәрәкәт Татарстанда Президент Рөстәм Миңнеханов инициативасыннан башланып, бүген дә дәвам иткән дөнья пространствосына интеграцияләнү һәм үсеш процесслары белән синхрон рәвештә бара. Әлеге югарылыктагы җитәкчеләрнең бик азына гына хас булган дәрт-дәрман, агымдагы нәтиҗәләр белән генә канәгатьләнеп калмау кебек сыйфатлар республика икътисадында һәм сәнәгатендә киң колачлы үзгәрешләр тудыра. Яшәеш принциплары республиканыкыннан бары тик масштаблары белән генә аерылып торган предприятиеләр җитәкчеләре өчен, аның республикага һәрдаим яңалык җәлеп итәргә омтылуы, планлаштыруның киң офыкларын күрсәтә, төбәктә гармонияле, уңай, продуктив атмосфера тудыра белүе – яхшы ориентир. Күптән түгел кабул ителгән Татарстанның 2030 елга кадәрге үсеше концепциясендә һәм Казанның 2030 елга кадәрге үсеше стратегиясендә ТР Президенты ачык иттереп шуны билгеләде: аның үсеш нигезен сәнәгать тәшкил итәчәк. Бу предприятиеләр үсеше өчен – тотрыклылыкка ышанычны һәм республика өметләрен аклау омтылышын үз эченә алган иң зур стимул.

Гиростабилизацияләнгән платформа.

PRESSA.RU

ТАТАРСТАН – ТРАНСПОРТТА ТАБИГЫЙ ГАЗ КУЛЛАНУ БУЕНЧА ЛИДЕР

2016 ел йомгакларына караганда, Татарстан Республикасы газ-мотор ягулыгы базарын үстерү темплары буенча лидер дип табылды. Төбәк территориясендә «Газпром»ның 19 автомобиль газ тутыру компрессор станциясен (АГТКС) үз эченә алган газ ягулыгы челтәре барлыкка килде. Мотор ягулыгы сыйфатында табигый газны куллану 2013 ел күрсәткечләре белән чагыштырганда өч мәртәбәгә артты.

2013 елда Татарстан Республикасы хөкүмәте, «Газпром» ГАҖ һәм «Газпром газ-мотор ягулыгы» ҖЧҖ арасында мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ куллануны киңәйтү буенча хезмәттәшлек турындагы килешү имзаланды. Татарстан Республикасы хөкүмәте тарафыннан «2013–2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» дәүләт программасы расланды. Эре шәһәрләрдәге автобусларда һәм коммуналь техникада газ-мотор ягулыгын куллану өлешен 50 процентка җиткерү күз уңында тотыла. Республикада 2023 елга метанда эшли торган техниканың гомуми саны 15 мең берәмлеккә җитәргә тиеш. Моның өчен республика табигый газда эшли торган техника сатып алуга субсидияләр бирү буенча федераль программаларда, һәм шулай ук транспортларын газга күчерергә теләгән физик һәм юридик затларның җиһаз сатып алуга киткән чыгымнарын кайтару буенча субсидияләр бирүне күз уңында тоткан үз программасын гамәлгә ашыра.

Үз чиратында «Газпром газ-мотор ягулыгы» төбәк территориясендә яңа газ тутыру инфраструктурасы төзелешен тәэмин итә. 2016 елда Түбән Кама, Яшел Үзән, Бөгелмә, Яр Чаллы, Казан, Азнакай, Алексеевск, Алабуга, Лениногорск кебек торак пунктларда заманча АГТКС пәйда булды. Бу «Газпром»ның Татарстандагы газ тутыру челтәрен ике тапкырга диярлек киңәйтергә мөмкинлек бирде: 20 объекттан 19 га кадәр. Шул ук вакытта челтәрнең җитештерүчәнлеге елына 148 млн куб. метр табигый газга кадәр артты. «Газпром» тарафыннан яңа инфраструктура булдыруга кертелгән

инвестицияләрнең гомуми күләме 1,5 млрд сумны тәшкил итте.

Республика автомобиль җитештерүчеләре шулай ук газ-мотор ягулыгы базарының актив катнашучысына әйләнделәр: «КАМАЗ» ГАЖ табигый газда эшли торган транспортның 40ка якын моделен чыгаруны җайга салды. «Форд Соллерс Холдинг» та иң популяр автомобильләрнең экологик версияләрен җитештерү мөмкинлеген карый.

Транспортны табигый газга күчерү республика өчен зур социаль һәм икътисадый әһәмияткә ия. 1 куб. метр зәңгәр ягулыкның бәясе ягулыкның сыек төреннән өч мәртәбәгә арзанрак – бары тик 13 сум. Табигый газның составы чиста булу нәтиҗәсендә атмосферага чыккан зарарлы матдәләрнең өлеше дә минималь. Татарстанда атмосферага чыгарылган зарарлы матдәләрнең күләме инде 4,5 мең тоннага кимеде.

«Татарстан Республикасы – Россиянең газ-мотор ягулыгы базарын үстерүгә комплекслы якын килүне гамәлгә ашыра торган беренче төбәге. Бу – проектның төбәк хакимияте органнары, иң беренче нәүбәттә республика Президенты Рөстәм Миңнеханов тарафыннан яклау табуы нәтиҗәсе», – дип билгеләп үтте «Газпром газ-мотор ягулыгы» генераль директоры Михаил Лихачёв.

PRESSA.RU

КМИЗ УҢЫШЛАРЫ

Соңгы җиде-ун ел Казан медицина инструментлары заводы өчен күп яклап истәлекле булды. Генераль директор Нур Шакиров сүзләренә караганда, совет чорының гадәти бер заводы заманча технологияле предприятиегә әверелде. Бүген КМИЗ – Россиядә стоматология, микрохирургия инструментлары һәм медицинада кулланылучы полимер эшләнмәләр җитештерүче иң эре предприятиеләрнең берсе.

Җитештерүне яңадан оештыру, аны заманча югары технологияле дәрәҗәгә күтәрү эше яңа җиһазларга инвестицияләр кертү һәм кадрларны әзерләүдән башлана. Җитештерү участоклары башлыклары – яңа буын җитәкчеләре инглиз телендә иркен сөйләшә. Алар базардагы яңа тенденцияләрне күзәтеп бару һәм аларны җитештерүдә куллану максатында һәрдаим халыкара күргәзмәләрдә катнашалар, үзләренең бөтен дөньядагы эшлекле партнерлары белән актив аралашып торалар.

Казан медицина инструментлары заводы – бүген Россиядә CE (Европа Советы) системасы буенча сертификацияләнгән стоматология, күз, пластик, коронар һәм нейрохирургия операцияләре өчен микрохирургия инструментлары һәм медицинада кулланылучы полимер эшләнмәләр җитештерүче иң эре предприятиеләрнең берсе.

КМИЗ тарихында төрле проектлар күп була, әмма барысының да максаты бер – бюджет акчалары турыдан-туры, өстәмә куллар аша үтмичә генә, республика дәваханәләрен кирәкле медицина инструментлары һәм эшләнмәләре белән тәэмин итсен, ә пациентларга югары сыйфатлы медицина ярдәме күрсәтелсен. Рөстәм Миңнеханов булышлыгы белән үз вакытында республиканың медицина учреждениеләрен кирәкле инструментлар белән тәэмин итү мөмкин булды. КМИЗда шуңа ышаналар: Президент ул чакта хупламаса, бүген завод кына түгел, ә хәзерге сәламәтлек саклау системасы да булмас иде.

Дөньяның алдынгы кардиологлары фикеренчә, КМИЗда эшләнгән микрохирургия инструментлары немец компанияләре эшләп чыгарганнан бер дә калышмый, ә хакы ун тапкырга арзанрак. Шулай да җитештерү – бер нәрсә, сату – икенче. Чит илләрнең шундый ук компанияләре белән көндәшлеккә чыгу объектив сәбәпләргә бәйле рәвештә җиңел түгел. Алай да КМИЗда җитештерелгән продукция Россиядә генә түгел, халыкара дәрәҗәдә дә абруй яулый бара. Аның инструментларын һәм материалларын үз эшендә күп еллар инде Александр Мясников исемендәге Клиник кардиология институтының, Россия Медицина фәннәре академиясенең, Россия кардиология фәнни-җитештерү үзәгенең һәм республиканың Төбәкара клиник-диагностика үзәгенең кардиология бүлеге хезмәткәрләре куллана.

Россиядән кала, бөтен дөньяда дәваханәгә анализлар өчен контейнер алып килү кабул ителмәгән. 2015 елдан КМИЗ контейнерлар белән Татарстан стационарларын да тәэмин итә башлады. Әлеге мөһим социаль проектны республика Президенты шулай ук хуплады.

Бүгенгә иң төп проект – Лаеш районының Хәерби авылында бер тапкыр кулланыла торган стериль инструментлар җитештерүне булдыру. Проект Татарстан өчен генә түгел, бөтен ил күләмендә актуаль.

Хикмәт шунда: бүген бер тапкыр кулланыла торган стериль медицина инструментларының 9 проценты гына Россиядә чыгарыла. Калган өлеше читтән кертелә. Төп проблема – стерильләштерү. Менә күп еллар инде КМИЗ стерильләштерү өчен үзенең продукциясен Мәскәү янына кадәр алып бара. Былтыр гына чыгымнарның бу матдәсе 70 млн сумны тәшкил иткән. Менә ни өчен бер тапкыр кулланыла торган стериль коралларны җитештерү проектының төп элементы – 36 куб газлы стерильләштерү камерасын урнаштыру. Беренче этапта алар икәү, аннан соң – дүртәү, ахырдан алтау булачак. Эшләп чыгаручысы – Италиянең дөньякүләм танылган DE LAMA (Де Лама) фирмасы. Аңа куркынычсызлыкның барлык юнәлешләре буенча абсолют гарантия бирелә. 2017 елда КМИЗ 1 млрд сумлык продукция җитештереп, аны стерильләштерергә планлаштыра, 2018 елда – 2 млрд сумлыкны. Ике стерилизаторны эшләтә башлауга, Татарстан Республикасының бюджеты 150 млн сумга тулыланачак.

КМИЗ башка юнәлешләр буенча да алга бара. Завод – Россиядә тутыкмый торган корычтан стоматологик эндоканал инструментлар җитештерүче бердәнбер тәэмин итүче. Планда – форманы хәтердә калдыра торган инновацион материаллар куллану. Бу пациентларга тагын да сыйфатлырак стоматологик ярдәм алырга мөмкинлек бирәчәк. Бүген

Реклама

Бүген Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов булышлыгы белән документлар пакеты тупланган һәм кластер теркәлгән. Аның составында 20 предприятие исәпләнә.

Польшадагы хезмәттәшләр белән җиһазлар комплекты булдырылган инде, тагын ике ай дигәндә, заводта алмаздан эшләнгән энә башлары һәм стоматология инструментлары көтелә. Швейцариядән Европа үрнәгендәге катыдан эретүче борлар җитештерү өчен станоклар сатып алынган.

Бүген Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов булышлыгы белән документлар пакеты тупланган һәм кластер теркәлгән. Аның составында 20 предприятие исәпләнә. Шушы ярдәм нигезендә партнер-компанияләр медицина инструментлары тармагының көндәшлек шартларындагы өстенлекләрен үстерү буенча тәгаен бурычларны хәл итәчәк, субсидияләр алачак, эчке базар үсешен һәм дөнья базарына чыгуны тәэмин итәчәк. Төркемдә катнашучылар арасында КМИЗ да бар.

– Һавалы кыяфәт һәм яңгыравык сүзләр белән генә берни дә үзгәртеп булмый. Ә менә дөрес итеп оештырылган эш, анализлый һәм фактларны үзара бәйли белү, өстенлекләрне дөрес куя барысын да үзгәртә ала. Бу товар җитештерүчеләр эшенә дә, хакимияткә дә кагыла, – ди «Казан медицина инструментлары заводы» АҖнең генераль директоры Нур Шакиров. – Республиканы федераль һәм дөнья күләмендә күрсәтә белү сәнгатенә төшенергә кирәк: бу исә соңгы еллардагы бик күп проектларга инвестицияләр җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк. Президентның иң зур ярдәме шуннан гыйбарәт тә инде. «Хакимият – җитештерүче» дигән тандемда эшләп, без Татарстанны тотрыклы, югары технологияле һәм ышанычлы киләчәк белән тәэмин итәбез.

«Казан медицина инструментлары заводы» АҖ
Тел.: 8 (843) 221-93-00 кабул итү бүлмәсе
221-93-43 факс

КМИЗ

PRESSA.RU

ДАИМИ ҮСЕШ ЭНЕРГИЯСЕ

Чыгара торган продукциясенең экологик чисталыгы һәм сыйфаты буенча бик күп җитештерүчеләрне артта калдырып, «Майский» теплица комбинаты бүген Европа яшелчә базарының лидеры саналган голландиялеләргә җитди көндәш булып тора. Әлеге бар яктан да алга киткән предприятиенең моннан берничә ел элек кенә юкка чыгу куркынычы алдында торганына ышануы да кыен. Әмма «Майский» өчен кризис һәлакәт түгел, бәлки үсешендә яңа чор башлану ноктасы булып чыга.

Илшат ГАНИЕВ, «Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖ генераль директоры:

– 2010 елда без, 1990 нчы еллар кризисыннан соң эшебезне бераз рәткә кертүгә үк, яңа сынау алдында калдык: җылылык энергиясе белән тәэмин итүчебез тарифларны икеләтә арттыру планын җиткерде. «Майский» өчен бу һәлакәт иде: без теплицаларны карап тотуга җылылык һәм электр энергиясен гадәти сәнәгать предприятиесенә караганда 8 тапкырга артыграк сарыф итәбез. Шунлыктан Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка мөрәҗәгать итеп, тарифларны элеккечә калдыруын яки аларның үсешен инфляция күләменнән арттырмавын үтендек. Хөкүмәт безгә ярдәм кулын сузды, әмма Рөстәм Нургали улы моның фәкать вакытлы чара икәнен искәртте, мәсьәләне тулысынча хәл итү өчен исә үзебезнең энергия һәм җылылык белән тәэмин итү системаларын булдыру зарурлыгын аңлатты. Шул мизгелдән «Майский» тарихында яңа чор башланды.

Үзебезнең максатчан программага таянып, без 2010 ел дәвамында 42 шәр МВт куәтле өч җылылык үзәге төзедек, 7,5 км арага югары басымлы газүткәргеч суздык һәм шул рәвешле теплицаларны җылыту өчен җитәрлек күләмне тәэмин иттек. 2011 елда РТЮның Мәскәү структурасы «Майский» территориясендә үзебезнең энергия үзәген төзү өчен безгә инвестор булырга теләген җиткерде. Россиянең агросәнәгать комплексы өчен бу проект уникаль иде. Аны гамәлгә кертүгә багышланган беренче киңәшмәдә Татарстан энергетиклары һәм Мәскәү делегациясе катнашты, Рөстәм Миңнеханов, барлык дәлилләрне тыңлаганнан соң: «Дөрес проект сайланган. Әйдәгез, төзибез!» – дигән нәтиҗә ясады.

Мәскәүлеләр төзегән беренче энергия үзәге бөтен өметләрне аклады. Анда җитештерелә торган электр энергиясенең бәясе базар бәясеннән 15 процентка арзанрак иде. Без мондый карарга килдек: үзебезнең ихтыяҗны тулысынча канәгатьләндерү өчен, безгә тагын шундый ике объект кирәк. Президент бу идеяне хуплады. Һәм шуннан соңгы өч ел дәвамында без, инде үз көчебез белән, куәтләре 23,5 МВт электр һәм 20 МВт җылылык энергиясе булган тагын ике үзәк төзедек.

Әлеге энергетика инфраструктурасы безгә продукциянең элекке күләмен кире кайтару гына түгел, бәлки технологияләрне шактый яңарту һәм оптимальләштерү мөмкинлеген дә бирде. Моннан берничә ел элек яшелчәләребезнең халыкара күргәзмәләргә эләгүе турында әле хыяллана да алмый идек, ә бүген инде, сыйфат, технологиялелек, уңышлылык һәм экологик чисталык буенча башкаларны узып китеп, хәтта орлыкчылык, селекция һәм яшелчә культураларының ген инженериясе буенча танылган лидерлар – голландлар белән ярыша алырлык дәрәҗәгә җиттек.

Әле 2000 нче елларда ук без экологиялелек ягыннан иң катгый таләпләргә җавап бирерлек продукция җитештерү бурычын куйган идек. Бүген бу күрсәткеч буенча яшелчәләребез балалар ризыгы таләпләренә җавап бирә.

Иң куркыныч матдәләрдән – агулы химикатлардан – без үзебезнең куәтле биолабораториябез эше нәтиҗәсендә котыла алдык, анда ел саен үсемлекләрне корткычлардан саклаучы 800 миллионнан артык энтомофаг үрчетелә.

Безнең комбинаттагы барлык җиһазлар, конструкцияләр һәм технологияләр – Россиядә җитештерелгән. Әлеге базага нигез инде 1990 нчы елларда ук салынган иде, ул чакта без су сибүнең автоматлаштырылган системаларын җитештерүне үзләштерүгә керештек. Вакытлар үтү белән, бу проекттан «Фито» фәнни-җитештерү фирмасы үсеп чыкты, без аның белән уңышлы хезмәттәшлек итәбез. Аларның эремә узеллары чит илдәге аналогларыннан күпкә яхшырак. Алар үсемлекләрне су белән тәэмин итеп кенә калмый, бәлки дренаж составын даими тикшерү нигезендә туклыклы эремәдәге макро- һәм микроэлементларның составын да үзеннән-үзе җайлый.

Моннан тыш, без дренаж суларын җентекләп чистартабыз. Алар

Реклама

махсус савытларга җыела, шунда фильтрлана, бактерицид лампалар ярдәмендә һәм термик ысул белән эшкәртелә. Шул рәвешле чистартылган су кабат сибү өчен файдаланыла. Шулай ук без үз скважинабыздагы артезиан суын да сибәбез. Европада дренаж суларын көнкүреш сулары белән бер канализация челтәренә агызуны тыя торган закон гамәлдә. Кайчан да булса Россиядә дә шундый норма кабул ителсә, без инде әзер.

2016 елда «Майский» комбинатының җитештерүчәнлеге 35,25 мең тонна яшелчәгә җитте. Җитештерү күләмнәренең еллык артымы соңгы берничә елда натураль чагылышта 7 процентка тәңгәлләште. Быел да шул күрсәткечкә ирешүне планлаштырабыз. Без инде бүген үк продукцияне узган елның шул чоры белән чагыштырганда 1500 тоннага артыграк җитештерәбез. «Майский» теплицаларының мәйданы 36 гектар тәшкил итә. Бу иң зур күрсәткеч түгел, әмма үстерелгән яшелчәләр күләме буенча без бүген – Россиядәге һәм Европадагы иң эре предприятие. Безнең төп кулланучыларыбыз – Татарстан халкы. Республика буенча заявкалар үтәлеп беткәннән соң, калган продукция илнең барлык эре агломерацияләренә – Төмән, Сургут, Киров, Пермь, Новосибирск, Чиләбе, Мәскәү, Санкт-Петербургка һ.б. җибәрелә.

Яктылык культурасы технологиясе безгә яшелчәләрне хәтта ел фасылларына бәйсез рәвештә үстерү һәм көндәшлеккә сәләтле бәяләрдән сату мөмкинлеген бирә. Моның өчен кирәкле яктылык техникасы җиһазларын – лампа, яктырткыч, автоматларны – без шулай ук Россия җитештерүчеләреннән алабыз.

Болар барысы да – технологияләр камиллеге, җайга салынган җитештерү процессы, продукциягә һәм аны сатып алуга ел әйләнәсе тотрыклы ихтыяҗ «Майский» комбинатына социаль юнәлешне актив үстерү мөмкинлеген бирә.

Соңгы берничә елда теплица хезмәткәрләре өчен өч тулай торак төзелде. Биш катлы торак йорт файдалануга тапшырылды, балалар бакчасында ясле төркеме булдырылды. Үткән җәйдә күркәм вакыйга булып узды: Татарстан Президенты катнашында тантаналы рәвештә спорт комплексы ачылды. Ул комбинат акчасына, аның 1 меңнән артык сандагы хезмәткәрләре өчен салынды. Без яшь гаиләләргә һәм пенсионерларга даими ярдәм итәбез. Ветераннарыбызны атна саен бушлай яшелчә белән тәэмин итәбез. Шулай ук атна саен бушлай кыяр, помидор һәм салатны Карамалы Тау, Васильево һәм Осиноводагы мәктәпләр һәм балалар бакчалары ашханәләренә җибәрәбез, районның 5,5 мең баласын шулай сыйлыйбыз.

Перспективада – уңышлы эшне дәвам итү. Бу көннәрдә генә биш катлы яңа торак йорт төзи башладык, аны 8–9 айдан файдалануга тапшыру планлаштырыла. Биолаборатория өчен яңа теплицалар монтажлау һәм аны зурайту, томат үстерү өчен Россиядә җитештерелгән алтышар метрлы яңа теплицалар төзү күздә тотыла. Энергия үзәкләренә кодинокслар – теплицаларны үзләренең углекислый газы белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк җиһазлар куелачак, хәзергә аны Тольяттида сатып алалар.

Голландиядәге коллегалар белән томат һәм кыярларның тәмен яхшырту буенча уртак эш дәвам итә.

Бүген күп кенә Россия компанияләре инде әзер «чит» технологияләрне кулланырга омтыла. Алар чит ил белгечләрен чакырта һәм әзер технологияләр үзләренә тиз арада базарга үтеп керергә һәм танылырга мөмкинлек бирер, дип өметләнә. «Майский» исә, туплаган тәҗрибәсенә һәм республика җитәкчелегенең ярдәменә таянып, үз юлын салуны дәвам итә. Һәм предприятиенең үсеш дәрәҗәсе дә, дөньяның иң шәп җитештерүчеләре продукциясеннән калышмый торган продукциясе дә бу юлның дөрес булуын дәлилли.

PRESSA.RU

УҢЫШ КҮКРӘП ҮССЕН, ӨСТӘЛЛӘРДӘ ИКМӘК БУЛСЫН ӨЧЕН...

Татарстан бүген, һичшиксез, Россия Федерациясе субъектлары арасында икътисадый лидерлардан исәпләнә. Биредә соңгы елларда тормышка ашырылган киң колачлы проектлар, аңлашыла ки, мелиорация кебек мөһим тармакны да урап узмады. 2,7 млрд сум – Татарстан Республикасы соңгы 5 ел эчендә генә дә мелиорациягә әнә шуның кадәр инвестиция ясады.

Әнвәр Залаков,
«Татмелиорация» Траст компаниясе» ААҖ генераль директоры

–Республикабыз Президенты Рөстәм Миңнехановның мелиорация мәсьәләләренә җитди һәм аңлап якын килүе нәтиҗәсендә, без бүген агросәнәгать секторына да, авыл хуҗалыгы җитештерүенең тотрыклылыгына һәм рентабельлелегенә дә ныклы нигез салу мөмкинлегенә ия булдык. Мелиорация комплексын модернизацияләү һәм торгызу кабул ителгән республика һәм федераль максатчан программалар кысаларында тормышка ашырылды, бу, үз чиратында, әлеге тармакның киләчәктә дә алга китешенә булышачак. Димәк, татарстанлыларның өстәленнән икмәк һәм ризык төшмәячәк, дигән сүз. Без бит әнә шуның өчен көч түгәбез. Моннан тыш, мелиорация үсеше продукциянең тулаем җитештерүенә генә этәрә дип уйларга ярамый. Ул гидротехник корылмаларның тотрыклылыгын һәм куркынычсыз эшләвен дә, аларның тәэсире булган өлкәләрдә гадәттән тыш хәлләрнең килеп чыгуын кисәтүне дә тәэмин итәчәк. Шунысы да мөһим: ул туфрагыбызны киләчәк буыннар өчен уңдырышлы итеп саклап калырга да мөмкинлек бирәчәк. Татарстан Россиядәге мелиорация буенча киң колачлы максатчан программалар тормышка ашырыла, объектлар төзелә, мелиорация техникасы өчен яңа производстволар ачыла торган сирәк төбәкләренең берсе. Республика мелиорациясенең шулай уңышлы һәм киләчәккә йөз тотып үсеш кичерүендә Рөстәм Нургалиевичның өлеше дә бик зур, чөнки ул безгә даими рәвештә, һәрьяклап ярдәм күрсәтеп килә.

«МЕЛИОРАЦИЯНЕ БАР КӨЧЕНӘ КУЛЛАНЫП КЫНА БЕЗ КӨНДӘШЛЕККӘ ИЯ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНА ИЯ БУЛА АЛАЧАКБЫЗ»

Идел буе һәрчак җир эшкәртүнең хәвефле зонасы булып исәпләнде. Татарстан авыл хуҗалыгында корылык ара-тирә була торган эпизодик күренеш кенә түгел, ә даими «кунак». Соңгы елларда республикада һәр җәй саен диярлек булып торды ул. 2010 елның яңгырсыз җәе республикадагы мелиорация тармагын үстерүнең ни дәрәҗәдә кирәкле икәнлегенә янә бер кат инандырды. Бу хакта Президент Рөстәм Миңнеханов Дәүләт Советына еллык Юлламасында да әйтте: «Бары тик мелиорацияне бар көченә кулланып кына без көндәшлеккә ия авыл хуҗалыгын үстерә алачакбыз».

МАКСАТЧАН ПРОГРАММАЛАР – УҢЫШНЫҢ НИГЕЗЕ

2010 елдагы корылыктан соң, Рөстәм Миңнеханов инициативасы буенча, кыска вакыт эчендә «2011–2012 елларда Татарстан Республикасында мелиорация комплексын модернизацияләү һәм энергетик нәтиҗәлелекле технологик яңарту» республика программасы уңышлы рәвештә тормышка ашырылды. 2011 елның сугару сезонында кырларда инде 240 заманча су сиптерү машинасы белән 169 суырту станциясе эшләп китте, 140 км дан артык магистраль торбаүткәргечләр сузылды. Болар барысы да 10 мең гектардан артык сугарылган туфракны яңартырга мөмкинлек бирде. Шул рәвешле, безнең республика үзенең бәрәңге белән яшелчәгә булган бөтен ихтыяҗын канәгатьләндерә алды. 2013 елда Татарстанда Президент күрсәтмәсе

2017 елда «Татмелиорация» республика системасы үзенең 95 еллыгын билгеләп үтәчәк. Бу республикабызның 40 предприятие һәм учреждениене берләштерүче һәм динамик үсешкә ия булган оешмаларының берсе. Болар арасында «Татмелиорация» Траст компаниясе» ААҖ да, 25 төзү оешмасы да, район күчмә механиклаштыручы колонналар да, «Татмелиоводхоз» идарәсе» ФДБУ да, мелиорация системаларын куллану буенча 13 идарә дә, шулай ук махсуслашкан предприятиеләр дә бар.

Реклама

Казан сугару техникасы заводы Россиядә беренчеләрдән булып заманча су сиптерү машиналарын эшләп чыгара башлады.

2016 елда республика басу-кырларында 14 «Казанка» су сиптерү машинасы урнаштырылды.

1994 ел. Биектау районы.

2014 ел. Биләр музей-тыюлыгы.

2016 ел. Лаеш районы. Халыкара басу көнендә.

Республиканың мелиорация бүлекчәләрендә бүген ике меңнән артык квалификацияле белгеч һәм эшчеләр хезмәт куя. Соңгы 10 ел эчендә алар төрле максатчан программалар кысаларында 430 мелиорация корылмасын төзеде һәм тергезде, 30 гектарга якын сугарылган җирләрне кулланугa тапшырды. 405 артезиан суы чыганагы булган скважина бораулады, 118 су манарасы урнаштырылды һәм 350 км су торбалары сузылды. Республиканың мелиорация бүлекчәләре «Чиста су», «Су хуҗалыгы комплексын үстерү» һ.б экология программаларын тормышка ашыруда актив катнашалар. 2016 елда гомуми күләме 1,5 млрд сумнан артыграк булган эш башкарылды. «Татмелиорация» Траст компаниясе» ААҖ аерым игътибарны хәйриячелек эшенә һәм иҗтимагый хезмәт күрсәтү традицияләрен торгызуга, игелеклелек, кешелеклелек кебек рухи кыйммәтләрне кайтаруга да юнәлтә. Соңгы 5 ел эчендә генә дә оешманың турыдан-туры хәйрия ярдәме 1 млн 781 мең сумны тәшкил итте.

буенча мелиорацияне үстерүнең 2020 елга кадәр исәпләнгән төбәк программасы эшләнде. Анда 35 мең гектар сугарылган җирне кулланугa тапшыру каралган. Шулай ук «2012–2017 елларда Татарстан Республикасында гидротехник корылмаларны торгызу буенча мелиорация эшләре» республика максатчан программасы да уңышлы тормышка ашырылып килә. Биш ел эчендә бу программа нигезендә 360 гидротехник корылма торгызылды, әле эш дәвам итә. Бүген Татарстанда алар – 823, күләмнәре буенча 395,6 млн кубометр сукуышка ия. Шулай ук 1 млн нан артыграк кубометр сукуышлы 80 бөяне дә искә алмый ярамас.

«КАЗАНСУ» КОРЫЛЫКТАН САКЛЫЙ

2016 елның 20 маенда Лаеш районының «Нармонка» хуҗалыгында Казан сугару техникасы заводы җитештергән һәм Россиядәге импортны алыштыруның беренче флагманы булган «Казанка» су сиптерү машиналары басуларга чыкты. Болар – Россиядә аналогы булмаган яңалык, һәм алар әлеге төр техникага куелган барлык техник һәм технологик таләпләргә дә җавап бирә. Стандарт машинаның озынлыгы 464 метрны тәшкил итә, су сиптерү мәйданы – 64 гектар. Ул авыл хуҗалыгы культураларының барлык төрләренә дә су сибә ала, югары энергетик нәтиҗәлелеге белән аерылып тора, тизлеге буенча да, куллануда экономияле булуы белән дә кулай санала. Реверс хәрәкәткә ия, ягъни сәгать теленең йөреше буенча да, аңа каршы якка да борыла ала. Кишәрлектәге культураларның нинди булуына карап, су сибүне үзе көйли һәм чиратка куя. Өстенлекләре – бихисап. Авыл хуҗалыгында бу могҗизага тиң техниканы күптәннән көтәләр иде инде. Әмма сайлау мөмкинлеге булмагач, сугару техникасы эшли торган үз заводыбызны булдырудан да кулайрак юл табылмады. Һәм менә Татарстандагы мелиорация өлкәсендә эшләүчеләр, Президент Рөстәм Миңнеханов белән Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы ярдәменә таянып, заманча технологик җиһазларны беренче булып эшләп чыгарып кына калмадылар, ә сынадылар һәм күпләп җитештерүгә дә куйдылар. Моның өчен бер елга якын вакыт эчендә яңа җитештерү бинасы төзелде, администрация белән остаханә биналары тергезелде, кешеләр яши ала торган блок белән берләштән, товар, матди байлыкларны саклый торган складлар сафка бастырылды. Бер үк вакытта конструкторлык документациясен әзерләү һәм гамәлгә кертү, детальләрнең векторлы моделен өлгертү буенча да эш алып барылды. Машиналар өчен станоклар, җиһазлар һәм башка кирәк-яраклар сатып алынды. 2016 елга республика басу-кырларында инде 14 «Казанка» су сиптерү машинасы урнаштырылган иде.

420073, РФ, ТР, Казан,
Гвардейская ур.,15
Тел. 272-72-70,
Факс 272-50-46
info@tatmeleo.ru

PRESSA.RU

ОЛИМПИАДАДАН УНИВЕРСИАДАГА КАДӘР

Илебезнең иң эре төзелеш берләшмәләренең берсе булган «Камгэсэнергострой»-ның тарихы ярты гасырдан элегрәк башланып китә. Зәй ГРЭС һәм Түбән Кама ГЭС кебек объектларны төзегәндә коллектив үзен яхшы яктан гына күрсәтә. Моннан соң төзүчеләргә иң җитди объектлар төзелешен ышанып тапшыра башлауларына гаҗәпләнәсе юктыр, өстәвенә, Татарстанда гына да түгел. Әйтик, «Камгэсэнергострой» 1980 елгы Мәскәү Олимпиадасының иң мөһим объектларын да төзи.

Соңгы дистә ел эчендә «Камгэсэнергострой» ГАҖ коллективына хәл итәргә туры килгән иң җаваплы бурычларның берсе Татарстан һәм гомумән Россия өчен стратегик саналган объект – «ТАНЕКО» нефть эшкәртү һәм нефть химиясе предприятиеләре комплексын төзүдә катнашу була. «Камгэсэнергострой»га биредә факел хуҗалыгын төзүне ышанып тапшыралар. Объект технологик яктан шактый катлаулы булып чыга, төзелеш-монтаж эшләрен башкарганда күп нәрсәне беренче мәртәбә эшләргә туры килә. Беренче тапкырдан һәм тиз генә килеп чыкмый. «Камгэсэнергострой»ның ул вакыттагы генераль директоры Александр Евдокимов сүзләренә караганда, беренче мәлләрдә төзүчеләргә тәнкыйть сүзләре дә ишетергә туры килгән, әлбәттә, алар нигезле булган. Ләкин нәтиҗәдә подрядчы тиешле тәҗрибәгә ирешә, авырлыкларны җиңеп чыга һәм кырыс графикны үти ала. Йөзгә кызыллык китерергә ярамый. Төзелешне Президент Рөстәм Миңнеханов күз уңында тота. «Ә ул барысына да җентекләп төшенә, тиз аңлап ала һәм карарларны оператив кабул итә белә торган кешеләр токымыннан. Һөнәре буенча төзүче булмаса да, аның ягыннан контроль профессиональ югарылыкта иде», – дип сөйли Александр Сергеевич.

«Камгэсэнергострой» республика һәм ил өчен уникаль булган тагын бер төзелештә – спорт объектын коруда катнаша. Предприятие 2013 елгы Универсиаданың һәм 2015 елгы Су спорт төрләре буенча дөнья чемпионатының ачылу тантаналары уздырылган стадион – «Казан Арена»-ның төзелешендә генераль подрядчыларның берсе сыйфатында эшли.

Россиядә футбол буенча дөнья чемпионатына дип төзелгән беренче стадионның архитектур концепциясе – төнбоек образы. Корылма җиңел-нәфис, хәтта ки челтәрсыман күренә. Әмма бу нәфислек төзүчеләргә җиңел генә бирелми. Проект буенча металл конструкцияләр (торбалар) югары ныклыкка ия корычтан эшләнергә тиеш, аларны Россиядә мондый корылмалар өчен күләмле конструкцияләрдә беркайчан да эшләмәгәннәр. Һәрвакыттагыча, бурычны кыска вакыт аралыгында хәл итәргә кирәк була. Стадионның металл конструкцияләрен урнаштыру һәм каркасны эш хәленә китерү өчен җиде ай вакыт бирелә.

«Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән гаять зур эш эшләнде, – дип искә ала Александр Евдокимов. – «Северсталь»дә таләп ителгән ныклыктагы корыч табаклар койдылар, Чиләбедә алардан торбалар ясадылар, Белгородта төп конструкцияләрне, терәкләрне эшләделәр... Рөстәм Нургалиевич гаять зур абруйга һәм хөрмәткә ия булуы нәтиҗәсендә Россия предприятиеләренең милек хуҗалары белән килешүгә, дүрт губернаторның ризалыгын алуга иреште. Ахыр чиктә республика барлык технологияләр сакланып, җиренә җиткереп төзелгән уникаль спорт объектына ия булды. Ә «Камгэсэнергострой» исә уникаль тәҗрибә туплады һәм заказчыларның олы ышанычын яулады».

Реклама

МИРАСНЫ САКЛАУ
ҺӘМ КИЛӘЧӘКНЕ ТӨЗҮ

Татарстанда тудырылган уңай инвестицион климат республикага төрле өлкәләргә караган киң колачлы проектларны тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Потенциаль инвестор бирегә бизнесны үстерү өчен кирәк булган инфраструктура тудырылганга да килә. «Таттелеком» ГАҖ әлеге мөмкинлекләрнең иң мөһимнәренең берсен – телекоммуникацияләрне җайга салучы.

Компания республика хөкүмәте ярдәмендә Татарстан территориясендә мәгълүмат тапшыру челтәрләрен яңарту буенча киң колачлы проектларны гамәлгә ашырды. Биредә иң заманча, куәтле һәм җиңел җайлашучан телекоммуникацион цифрлы инфраструктура булдырылды. Ул, дөньякүләм масштабтагы иң эре чаралар – 2013 елгы Бөтендөнья җәйге Универсиадасын һәм 2015 елгы Су спорт төрләре буенча дөнья чемпионатын үткәреп, җитди сынау үтте һәм оештыручылар тарафыннан югары бәя алды. Заманча телекоммуникацион цифрлы инфраструктураның мөмкинлекләре алга таба Конфедерацияләр кубогын, футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрү вакытында да тулысынча кулланылачак.

«Таттелеком» инновацияле технологияләрне гамәлгә кертү һәм камилләштерү буенча эшчәнлеген дәвам итә. Компания Россиядә беренчеләрдән булып 1800 МГц диапазонында эшли торган 4G –LTE* югары тизлекле мобиль челтәрне эшләтеп җибәрде. Бу Татарстан Республикасы территориясендә киң полосалы мобиль технологияләрне алга җибәрүдә һәм республика халкын соңгы буын мобиль элемтә белән тәэмин итүдә мөһим адым булып тора.

Уңышлы икътисадый эшчәнлек «Таттелеком»га рухи һәм мәдәни мирасны саклау һәм үстерү процессларында актив катнашырга мөмкинлек бирә. Тарихи һәм мәдәни җәүһәрләрне яңартуга аерым игътибар бирелә. «Әлеге проектлар – үзенә күрә бер игелек, алар кешеләрне яхшы якка үзгәртә», – дип билгеләп үтте бервакыт Татарстан Президенты. Компания җитәкчелеге әлеге фикер белән тулысынча килешә. Тарих һәм мәдәният һәйкәлләре гаять зур рухи потенциалга ия, күпмилләтле Татарстанның шанлы үткәнен һәм бай традицияләрен чагылдыра.

Әйтик, «Таттелеком» алып барган социаль сәясәтенең төп юнәлеше булган иганәчелек һәм хәйриячелек эшчәнлеге кысаларында Арча районы Кырлай авылында әдәби-скульптура паркын ачу проектын гамәлгә ашырды. Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның 130 еллыгын билгеләп үтү елында парк аның иҗатын хөрмәт итүчеләрнең барысы өчен дә кадерле урынга әйләнде.

«Менә диген музей, милли казанышыбыз... Үзен татар дип санаган һәркем биредә булырга, барысын да күрергә тиеш. Бу бик мөһим. Әгәр без балаларыбызга Тукайның кем икәнлеге, тормышының элек ничек булуы турында сөйләмәсәк, алар аны каян белергә тиеш?.. Әлеге хезмәт нәтиҗәләренең барысы да башкарган эшебез, туган республикабыз белән горурлану хисләре уята!» – дип билгеләп үтте экскурсиядән соң Татарстан Президенты.

Ул шулай ук мондый проектларны гамәлгә ашырганда битараф калып булмавына басым ясады. Һәр эштә аны башкаручылар күңеленең бер өлеше кала. Шуңа күрә мондый проектларны гамәлгә ашыруга безнең киләчәгебез булган яшьләрне җәлеп итү аеруча мөһим. ТР Президентының: «Әгәр без тарихыбызны белергә һәм аны хөрмәт итәргә өйрәнсәк, һичшиксез, бөтен дөнья да безнең илебезне, без яшәгән урынны ихтирам итәчәк!» – диган сүзләре республикада яшәүче һәр кеше өчен девизга әверелер, дип ышанасы килә.

«Таттелеком» ГАҖ
222-22-22
www.tattelecom.ru
ТАТТЕЛЕКОМ

Реклама
* 4G – LTE – 4 Г – ЛТЕ.

PRESSA.RU

ЕРАККА – ЯҢА ОФЫКЛАРГА

Татарстан даими рәвештә сәнәгать һәм граждан объектлары төзелешенең күләмнәре һәм сроклары буенча рекордларын арттыра тора. Болар барысы да гасырлар дәвамында хезмәт итсен өчен, диварларның нык булуы гына җитми, нигезе дә, нигез салынган урыны да ышанычлы булырга тиеш.

Артём Филиппов, «ТР Геоүзәге ФҖБ» ДУП генераль директоры

Менә 15 ел инде «Татарстан Республикасы геология һәм җир асты байлыкларын куллану буенча фәнни-җитештерү берләшмәсе» Дәүләт унитар предприятиесе («ТР Геоүзәге ФҖБ» ДУП) геологик мохитне файдалану, куркыныч янаучы геологик процессларны кисәтү, су асты суларының ресурс потенциалын бәяләп, аны рациональ файдалануны тәэмин итү мәсьәләләре белән шөгыльләнә.

Шушы еллар дәвамында «Геоүзәк» ТР Хөкүмәте ярдәме белән җир асты байлыкларын куллану өлкәсендә дәүләт программасын гамәлгә ашыруга зур өлешен кертә.

Тәҗрибәле, югары квалификацияле белгечләр – геологлар, гидрогеологлар, экологлар, картографлар, геодезистлар эшләгән татуның хезмәте нәтиҗәсендә, оешма республика җитәкчелеге куйган бурычларны уңышлы хәл итә, шулай ук эш юнәлешләрен киңәйтә алды. Предприятие эшендә барлыгы 40 ка якын белгеч катнаша.

Җир астын геологик яктан өйрәнү зарурлыгы җир асты байлыкларын чыгару һәм эшкәртү предприятиеләренең эшләнеш тизлегенең үсеше, торак һәм сәнәгать инфраструктурасы объектлары төзелешенең интенсив процесслары белән билгеләнә. Предприятие белгечләре җир асты байлыкларын файдалануны камилләштерү, гамәлдәге минерал-чимал комплексын саклау һәм үстерү, геологик мохитне куркынычсызлык таләпләренә ярашлы файдалану кебек юнәлешләргә аерым игътибар бирәләр. Мәсәлән, 2016 елда Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы заказы буенча «ТР территориясендә киң таралган файдалы казылмаларның минерал-чимал базасының торышын бәяләү һәм паспортлаштыру» дигән темага эш башкарылды. Әлеге эш киң таралган файдалы казылмаларның 198 чыганагы территориясен бәяләү белән бәйле булып, урыннарга барып тикшерүне һәм җирлекне картага төшерүне таләп итә.

2015 елдан башлап, «ТР Геоүзәге ФҖБ» ДУП җирле әһәмияткә ия булган җир асты участокларының файдалы казылмалар запасларына дәүләт экспертизасы үткәрү һәм оештыру буенча вәкаләтле эксперт органы статусын ала. Шушы вакыт аралыгында эксперт комиссиясе тарафыннан 69 хисап каралды, шулардан 41е – каты файдалы казылмаларны, 26сы җир асты суларын бәяләү буенча.

Шулай ук бүген көн кадагында торган бурычлар арасында Казан территориясенең геодинамик мониторингын оештыру да бар. Предприятие хезмәткәрләре күпьеллык мәгълүматларга һәм күзәтүләргә таянып, тискәре йогынтылы геологик процессларга бирешүче участокларны барлау һәм билгеле бер чорда гадәттән тыш хәл килеп чыгу ихтималын фаразлау белән шөгыльләнә. Бу мәгълүматлар куркыныч янаучы геологик процессларның торак пунктлардагы, шул исәптән Татарстан башкаласындагы торак йортларга һәм башка инфраструктур объектларга тискәре йогынтысын кисәтү һәм киметү буенча чаралар күрү өчен әһәмиятле.

Моннан тыш, «Геоүзәк» җир асты суларының сыйфаты һәм җыелу дәрәҗәсенең мониторингы белән дә шөгыльләнә. Җир асты байлыкларын кулланучыларның мәгълүматларына һәм үзләренең тикшеренүләренә таянып, экспертлар карталарына суның химик составы һәм пычранган участоклар турындагы мәгълүматларны кертәләр. Эксплуатацияләү һәм санитар зоналарны саклау шартларына гидрогеологик нигезләүләр үткәрелмәгән килеш расланмаган запасларга су коймалары урнаштыру әлеге скважиналардан чыккан суның эчәргә һәм көнкүрештә кулланырга яраклы булмавына китерергә мөмкин. Шуңа да су коймасы урнаштыру өчен эзләнү-өйрәнү, тикшерү һәм эксплуатацияләү запасларын бәяләү эшләре алып барылырга тиеш. Бу эшләрне «Геоүзәк» килешү нигезендә башкара. Моннан тыш, предприятие су бораулауны башкару проектларын эшли, чыганакларны эшкәртә, гидрогеологик скважиналарны ликвидацияли, һәм шулай ук җир асты сулары скважиналарының паспортларын булдыру, су коймаларының санитар сак зоналарын оештыру, судан файдалануга лицензия бирү белән дә шөгыльләнә.

Сулыкларны саклау елы кысаларында «Геоүзәк» су асты суларының мониторингы һәм хәвефле экзоген геологик процесслар буенча да зур күләмле эшләр башкарды.

Ә оешманың яңа функционалы – судан файдалану мәсьәләләре буенча күзәтү органнарында рөхсәт бирүче документларны җыю, әзерләү, эшләү һәм килештерү, шулай ук су объектын причаллар, гидротехник һәм башка корылмалар төзү өчен куллануга рөхсәт карары алу буенча да эш комплексы. Әйтик, мәсәлән, җир участокларын эре сусаклагычлар һәм елгалар юудан (абразиядән) саклау өчен, җир хуҗалары яр буйларын ныгытып, корылмалар төзи, моның өчен рөхсәт бирүче документ – Су объектын куллануга бирү турында карар бирелә. Әлеге документ җитди әзерлек таләп итә, шуңа да бу эшне оештыруны «ТР Геоүзәге ФҖБ» ДУП үз өстенә алырга әзер. Әлеге юнәлеш ТРда Экология һәм җәмгать пространстволары елында аеруча актуаль.

«Геоүзәк»нең геология разведкасы, төзелеш, су белән тәэмин итү, әйләнә-тирәне саклау һәм хәвефле табигый процесслар һәм күренешләрне фаразлау мәсьәләләрендәге тәҗрибәсен истә тотып, 2016 елда ТР Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды предприятие белгечләренә алга таба Казан янәшәсендәге «М-14» һәм «Каенлык» торак микрорайоннарын эчәр су белән тәэмин итүне оештыру өчен, су астындагы чыганакларны өйрәнү буенча эшләр комплексы алып барырга кушылды. Объектларны 2017 елда кулланылышка тапшыру планлаштырыла.

«ТР Геоүзәге ФҖБ» ДУП
(843) 277-82-97,
gupgeocentr@mail.ru

Геоцентр РТ

Реклама

РОСРЕЕСТР: ӨСТЕНЛЕК– СЫЙФАТКА

Күчемсез милекне хосусыйлаштыру буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының сизелерлек дәрәҗәдә үсеше – соңгы елларда Росреестрның Татарстан Республикасы буенча Идарәсе ирешкән төп казанышларның берседер, мөгаен. Ведомствоның заманча форматта күрсәткән хезмәтләре татарстанлыларга вакытларын, акчаларын янга калдыру мөмкинлеге бирә, шулай ук аларны алдавыч схемалардан саклый.

«Казан» Телефон аша хезмәтләндерү үзәге – Росреестр Колл-үзәгенең рәсми ачылу тантанасы.

УҢАЙЛЫЛЫК СИЗЕЛӘ

2009 елдан башлап, РФ Хөкүмәте күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән Росреестр Идарәсе күпфункцияле үзәкләр базасында халыкка дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итүнең нәтиҗәлелеген күтәрү эшен алып бара. Соңгы җиде ел эчендә ведомствоның 23 бүлекчәсе республика һәм федераль бюджетлар хисабына төзелгән яңа бинага күчте, калганнарына капиталь ремонт ясалды. Хәзерге вакытта муниципаль районнарда яшәүче халыкка төрле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр комплексны рәвештә, бер урында, уңайлы шартларда күрсәтелә.

...ҖАЙЛЫ

2015 елның февралендә күпфункцияле үзәкләргә киткән чыгымнарны оптимальләштерү һәм карарлар кабул иткәндә тизлекне арттыру максатыннан, Татарстан Президенты карарлары на ярашлы, КФҮнең үзәкләштерелгән структурасына күчелде – хезмәтләр бары тик «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе һәм аның филиаллары тарафыннан күрсәтелә.

Бер айдан да азрак вакыт эчендә республикада КФҮнең 50 филиалы булдырыла, кирәкле барлык оештыру чаралары уздырыла.

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов тарафыннан КФҮләрне Росреестр һәм Кадастр палаталары бүлекчәләре белән максималь рәвештә бергә урнаштыру турында карар кабул ителә. Бу гражданнарга җайлы булсын һәм иялнгән адресны саклап калу өчен шулай эшләнә, чөнки КФҮләр күрсәткән хезмәтләрнең 75 проценты Росреестрга карый.

...ОПЕРАТИВ

Соңгы елларда Росреестр өчен дә, тулаем Татарстан өчен дә тагын бер истә калырлык вакыйга булды – 2014 елда Казанда Росреестрның Телефон аша хезмәтләндерү ведомство үзәгенең икенче мәйданчыгы ачылды. Бу вакыйгага бәйле Казанның 200дән артык кешесе эш урынына, ә республикада һәркем тәүлек әйләнәсе күчемсез милеккә хокукларын теркәүгә бәйле мәсьәләләр буенча оператив консультация алу мөмкинлегенә ия булды.

Колл-үзәкнең ачылу тантанасында чыгыш ясап, ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, хәзер республикада төбәк өчен тагын бер әһәмиятле проект гамәлгә ашырылды, дип билгеләп үтте: «Бүген бөтен эшчәнлек мәгълүмати технологияләр белән бәйле алып барыла. Кайда булуыбызга карамастан, без теләсә нинди мәгълүмат ала яки тапшыра алабыз. Бу проект уңышлы булырга тиеш, ул бөтен ил буенча эшли һәм күчемсез милеккә хокукларны теркәү системасының бер өлеше булып тора».

Казандагы Телефон аша хезмәтләндерүнең ведомство үзәге (ВЦТО) – ведомствоның РФндәге икенче колл-үзәге. Росреестрның беренче телефон аша хезмәтләндерү үзәге Курск шәһәрендә 2011 елның сентябрендә ачылган иде. 8-800-100-34-34 күпканаллы телефоны аша тәүлек әйләнәсе күчемсез милеккә хокукларны теркәү белән бәйле мәсьәләләр буенча консультация алырга була. Үзәккә шалтыратып, Росреестрның теләсә кайсы төбәктәге бүлекчәсе җитәкчесенә язылырга, шулай ук ведомствоның эшчәнлегенә бәя бирергә мөмкин.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Аксубай районының КФҮндә булды.

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте (Росреестр) – күчемсез милеккә хокукларга һәм алар белән сделкаларга дәүләт теркәве үткәрү, күчемсез милеккә дәүләт кадастрын алып бару өлкәсендә дәүләт хезмәтләре, күчемсез милеккә, җир төзелешенә кадастр исәбен үткәрү, җирләрнең дәүләт мониторингын алып бару, транспорт комплексын навигация белән тәэмин итү функцияләрен, шулай ук дәүләт кадастр бәяләү, геодезия һәм картография өлкәсендә федераль дәүләт җир күзәтчелеге, үзкөйләнүле бәяләү оешмаларының эшчәнлеге күзәтчелеге, арбитраж идарәчеләрнең үзкөйләнүле оешмалары эшчәнлеген контрольдә тоту функцияләрен башкаручы федераль дәрәҗәдәге башкарма хакимият органы булып тора.

Реклама

ЧИКСЕЗ МӨМКИНЛЕКЛӘР ЯРМИНКӘСЕ

Татарстан Республикасы – Россия Федерациясенең сәнәгатьтә, икътисадта һәм социаль өлкәләрдә инновацияле табышларны актив рәвештә куллана торган лидер төбәкләренең берсе. Күп кенә компанияләр өчен Татарстан Республикасы – федераль дәрәҗәдә һәм алга таба БДБ илләре базарларына чыгу ноктасы. Куелган максатларга ирешүдә төп ысулларның берсе даими үткәрелә торган күргәзмәләр булып тора.

Лев Семёнов,
«Казан ярминкәсе» ААҖ генераль директоры

Татарстан Республикасының «Казан ярминкәсе» Күргәзмәләр үзәгендә Идел буеның сәнәгать һәм югары технологияле күргәзмәләре, Россия һәм БДБ илләренең масштаблы конгресс-күргәзмә чаралары уздырыла. «Казан ярминкәсе» ААҖ ел саен дөньяның 30 иленнән килгән вәкилләр катнашлыгында уздырыла торган 400дән артык чарага комплексы хезмәт күрсәтә, шул рәвешле Татарстан Республикасын Россия төбәкләре арасында лидер итүгә һәм Татарстанда эшләнгән тикшеренүләрне дөнья базарында танытуга үз өлешен кертә.

«Казан ярминкәсе» ААҖ җитәкчелегенең чит илләрнең күргәзмә оешмалары белән эшлекле элемтәләр урнаштыру буенча күп еллар дәвамында планлы рәвештә алып барган эшчәнлеге Европа һәм Азиянең алдынгы күргәзмә компанияләре белән килешүләр төзү мөмкинлеге бирде. Алар арасында – Messe Frankfurt GmbH[1], Messe Duesseldorf GmbH[2], IFWexpo Heidelberg GmbH[3], German Agricultural Society (DLG)[4].

2016 елның апрелендә ТР рәсми делегациясенең Финляндия Республикасына эш сәфәре вакытында «Казан ярминкәсе» ААҖ җитәкчелеге һәм «Тампере Күргәзмәләре» компаниясе арасында хезмәттәшлек итү турында килешү имзаланды. Халыкара дәрәҗәдә авыл хуҗалыгы күргәзмәләре үткәрү тәҗрибәсен истә тотып, 2016 елда Россия «Казан ярминкәсе» ААҖ йөзендә Европаның Авыл хуҗалыгы күргәзмәләрен оештыручылар ассоциациясенә (EURASCO)[5] кабул ителде.

«Казан ярминкәсе» күргәзмәләр үзәге TIAF supported by Automechanika[6] Халыкара автомобиль төзелеше форумы, Халыкара Басу көннәре һәм «Интерпластика. Казан» халыкара махсус күргәзмәсе кебек эре халыкара проектларны оештыручыларның берсе булып тора.

Татарстан Республикасының алдынгы һәм перспективалы кластерларын чагылдыручы һәм дистәләрчә башка тармакларда фәнни-техник прогресс юнәлешләрен билгеләүче мөһим күргәзмә проектлары арасында «Идел буе агросәнәгать форумы», «Энергетика. Ресурсларны саклау», «Машина төзелеше. Металл эшкәртү. Казан», «ВолгаСтройЭкспо», Татарстан нефть-газ химиясе форумы, «Авиакосмик технологияләр, заманча материаллар һәм җиһазлар» һәм «ДорТрансЭкспо» күргәзмәләрен билгеләп үтәргә кирәк.

«Казан ярминкәсе» күргәзмәләр үзәге тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләрнең гарантияле сыйфаты кат-кат расланган, бу турыда күпсанлы бүләкләр һәм дипломнар сөйли. Күргәзмә-ярминкә хезмәтләре күрсәтүне оештыру өлкәсендә югары нәтиҗәләргә ирешкән өчен «Казан ярминкәсе» «Россиянең иң яхшы 100 товары» программасының һәм «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары» бәйгеләренең лауреаты һәм дипломаты булды. 2016 елда «Казан ярминкәсе» ААҖ Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Сыйфат премиясе лауреаты булды, ә ел саен үзәк тарафыннан үткәрелә торган Татарстанның нефть-газ химиясе форумы «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» республика бәйгесендә җиңү яулады.

«Казан ярминкәсе» ААҖнең 10 күргәзмәсе РСВЯ билгесенә ия булды, бу исә Россия икътисады өчен күргәзмә чарасының аеруча әһәмиятле булуы турында сөйли. «Казан ярминкәсе» ААҖнең 4 күргәзмәсе UFI approved event[7] билгесе алды (Бөтендөнья күргәзмәләр индустриясе ассоциациясе тарафыннан танылды).

«Казан ярминкәсе» Күргәзмәләр үзәге – Россиянең әйдәп баручы күргәзмәләр үзәге һәм Бөтендөнья җәйге Универсиада 2013, 2014 елдан

башлап хәзергәчә һөнәри осталык буенча WorldSkills Russia[8] Россия чемпионаты, «Лесоруб-2015» урман кисүчеләр арасында Россия чемпионаты, «Берләштерелгән шәһәрләр һәм җирле хакимиятләр» Бөтендөнья оешмасының Башкарма бюросы утырышы (United Cities and Local Governments (UCLG)[9] кебек масштаблы спорт һәм һөнәри чараларның техник операторы һәм аларны оештыручыларның берсе.

4 ел дәвамында «Казан ярминкәсе» күргәзмәләр үзәгендә дөнья стандартларына ярашлы итеп уздырылучы WorldSkills Russia чемпионатының югары дәрәҗәсе Казанга WorldSkills Competition[10] 2019 эшче һөнәрләренең дөнья чемпионатын уздыру хокукына көрәштә җиңү яуларга мөмкинлек бирде. Чемпионат 2018 елга «Казан» аэропорты янәшәсендә төзеләчәк «Kazan Expo»[11] халыкара конгресс-күргәзмәләр үзәгендә узачак. «Казан ярминкәсе»нең әлеге проектны булдыру башлангычын Татарстан Республикасы Хөкүмәте хуплады.

Бүген конгресс-күргәзмәләр эшчәнлегенең роле илнең социаль-икътисадый үсешенең үтә дә мөһим бурычларын хәл итүдән гыйбарәт. һәм «Казан ярминкәсе» күргәзмәләр үзәге республиканың инвестицион яктан җәлеп итүчәнлеген күтәрүдә иң нәтиҗәле коралларның берсе буларак, дөнья тәҗрибәсен раслый.

ВЫСТАВОЧНЫЙ ЦЕНТР
КАЗАНСКАЯ ЯРМАРКА
«Казан ярминкәсе» ААҖ
(843) 570-51-11
kazanexpo@telebit.ru
Реклама

[1] Мессе Франкфурт ГмбХ, [2] Дюссельдорф, [3] ИФВэкспо Хеделберг, [4] Джерман Агрикультурал Социети, [5] ЕУРАСКО, [6] ТИАФ суппортед бай Автомеханика, [7] ЮФИ аппровед евент, [8] Ворлдскиллс Россия, [9] Юнайтед Ситис энд Локал Говернментс, [10] Компетишен, [11] Казан Экспо.

ТӨБӘК ТЕХНОПАРКЛАРЫ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов 2013 елның апрелендә Кытайга сәфәре вакытында Сучжоу индустриаль паркына барган иде. Ул аннан шундый фикергә килеп кайта: Татарстан районнарында зур булмаган индустриаль парклар төзегәндә, кытай тәҗрибәсе бик файдалы булырга мөмкин.

DoorHan* компаниясе – күчерелмә киртә конструкцияләрнең киң спектрын (секцияле көнкүреш һәм сәнәгать капкалары, урам капкалары, рольставня, ролькапкалар, ишекләр), склад җиһазлары, алюминий системалар һәм модульле конструкцияләрне Россиядә беренче җитештерүче.

Холдинг составына Россиядәге 8 завод, Кытай һәм Европадагы 3 завод, 23 җитештерү-склад комплексы һәм 11 сәүдә вәкиллеге керә. DoorHan продукциясе дөньяның 68 илендә мәгълүм.

Татарстанның Лаеш районында DoorHan компаниясенең җыю буенча производствосы эшли.

ТӘҖРИБӘ АЛМАШУ

Александр ХАНИН, Россиядә һәм чит илләрдә дистәдән артык үз заводы булган DoorHan компаниясенең генераль директоры:

– 2013 елда Сучжоуда Рөстәм Нургалиевич белән очрашкач, безгә ул болай диде: «Сезнең казанышларыгыз искиткеч. Кытайда уңышлы эшләүче Россия компаниясенең тәҗрибәсе безнең өчен кызыклы, без киләчәктә дә сезнең белән эшләргә һәм хәлдән килгәнчә булышырга әзер». Мин дә республика белән хезмәттәшлекне дәвам итәргә теләвемне белдердем, Рөстәм Нургалиевич кече һәм урта җитештерү предприятиеләре өчен технопарклар төзүдә кытай тәҗрибәсен файдаланып карарга тәкъдим иттем. Президент аныклык кертте: «Безгә районнарда зур булмаган технопарклар төзү мөһим».

Бүген ышанып әйтеп була: ниятләр чынбарлыкка әйләнде. Татарстанда без соңгы ун ел дәвамында актив эшлибез, безнең бизнес даими үсеш кичерә. DoorHan компаниясенең Татарстандагы беренче зур проекты Комлы Кавалда (Лаеш районы) 2010 елда башланган иде, ул чакта ТР Хөкүмәте безгә җитештерү-склад комплексы төзелешенә мәйданы ике гектарлы җир кишәрлеге бүлеп бирде. Әлеге проектның максаты – җитештерү күләмен арттыру, ТРнда импортны алыштыру буенча программаны гамәлгә кертү, логистика чыгымнарын киметү һәм яңа эш урыннары булдыру иде. Хәзерге вакытка проект тулысынча тормышка ашырылды. Моннан тыш мине тагын менә нәрсә сөендерә: Татарстан җитәкчелеге сәнәгать кластерын үстерүнең республиканың инвестицияләр җәлеп итү эшендә иң уңышлы юнәлешләрдән берсе булуын бик яхшы аңлый.

МАСШТАБЛЫ ПРОЕКТ

2014 елда «Ин Парк – Казан» индустриаль паркын төзү башланды. ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов исә алдынгы карашлы һәм ерак киләчәкне күздә тотып эшләүче җитәкче булуын тагын бер кат раслады:

– Эшкуарлыкка ярдәм итү – дәүләтнең төп бурычы, – дип басым ясады ул. – Без зур комплекслар булдыру өчен күп тырыштык. Ә менә DoorHan компаниясе проекты беренче булачак.

Чыннан да, проект республикадагы кече һәм урта бизнес предприятиеләрен үстерүгә юнәлтелгән. Парк территориясенең гомуми мәйданы 90000 квадрат метр тәшкил итә. Проектны тулысынча гамәлгә кертүгә 6–8 ел вакыт китәчәк һәм миллиард сумнан артыграк акча тотылачак.

Хәзер объектны төзү тулы куәтенә бара – металл конструкцияләрне торгызу, каркасны тышлау һәм түбәне монтажлау эшләре тәмамланган инде. «Ин Парк –Казан» индустриаль паркының беренче чиратын файдалануга тапшыру бу ел азагына планлаштырылган.

РЕЗИДЕНТЛАР ӨЧЕН МАХСУС КЛИМАТ

Минем фикеремчә, Татарстанда махсус инвестицион климат булдырылган, ул Россия Федерациясенең башка төбәкләрендәге капитал кертү шартларыннан яхшы якка аерылып тора. Шунлыктан без бу проектны сайлап алдык та инде, чөнки аның уңышка ирешәсенә иманыбыз камил. Аның бәхәссез өстенлекләреннән яхшы шартларны, акылга муафыйк бәяне һәм зур үсеш алган инфраструктураны атап була. Мин шуңа өметләнәм: «Ин Парк – Казаннан» соң Татарстанда шуңа охшаш яңа объектлар пәйда була башлаячак.

Сәнәгать мәйданчыклары – һәр муниципалитетта

Узган ел, Петербургтагы халыкара икътисадый форумда чыгыш ясаганда, Рөстәм Миңнеханов республикада кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү чараларының юнәлеше үзгәрүне билгеләп үтте:

– Әгәр без элегрәк «Химград», «Мастер» КИП, махсус икътисадый зоналар кебек эре проектларны хупласак, бүген исә һәр муниципалитетта эшкуарларга бизнес алып баруны җиңеләйтә торган сәнәгать мәйданчыклары булдырылды. Һәм якын арада андый мәйданчыкларның саны йөзгә җитәчәк.

* DoorHan – ДорХан.

Реклама

PRESSA.RU

ТР ТЕХНИК ИНВЕНТАРЬЛӘШТЕРҮ БЮРОСЫ **ЯҢАРЫШ ЮЛЫНДА**

Эшчәнлеген актив камилләштерү, өстәмә юнәлешләрне үстерү – болар соңгы еллар эчендә ТИБ Республика дәүләт унитар предприятиесенең эшендә иң әһәмиятлегә әверелде.

Техник инвентарьләштерү бюросы Республика дәүләт унитар предприятиесенең (ТИБ РДУП) генераль директоры Хәмзина Л.И.

90 ел эчендә республикада урнашкан күчемсез милек объектларының исәпкә алу-техник документациясен туплаган гаять зур дәүләт архивы булдырылган.

ИНВЕНТАРЬЛӘШТЕРҮ – КАПИТАЛЬ РЕМОНТ БЕЛӘН БЕРГӘ

Республика Президенты Рөстәм Миңнехановның уйланылган карарлары һәм сәяси ихтыяры нәтиҗәсендә 2015 елның декабрендә «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортларында гомуми милеккә капиталь ремонт үткәрүне оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертелде. Аның нигезендә 2016 елдан башлап капиталь ремонт программасын тормышка ашыру кысаларында күпфатирлы торак йортларга техник инвентарьләштерү үткәрелә.

Бүген ул – Татарстан Республикасы территориясендә тормышка ашырыла торган уникаль проект. Мисал өчен, 2016 елда гомуми мәйданы 4457 мең кв. м булган 641 күпфатирлы йортка техник инвентарьләштерү үткәрелгән, 2017 елга гомуми мәйданы 4518 мең кв. м булган 687 йортка техник инвентарьләштерү үткәрү планлаштырылган. Һәм нәкъ менә бу – соңгы ел эчендә ТИБның иң зур әһәмияткә ия булган эш нәтиҗәләренең берседер, мөгаен.

Республика ТИБ бүгенге көндә төбәкнең 90 еллык эш тәҗрибәсенә ия булган иң эре кадастр компаниясе булып тора. Предприятие бүлекчәләрендә 450 кеше хезмәт итә, шуларның 90нан артыгы кадастр инженеры аттестатына ия.

НИЧЕК КЕНӘ КАТЛАУЛЫ БУЛМАСЫН...

Оешма эшчәнлегендә республикада яшәүчеләргә уңышлы хезмәт күрсәтә торган юнәлешләр булып бәяләү, проектлаштыру һәм ызанлау эше тора. Шулай итеп, соңгы җиде ел эчендә ТИБның гомуми керемнәрендә профиль булмаган керемнәр өлеше өч мәртәбә диярлек – 8% тан 22,5%ка кадәр артты.

2017 ел башыннан кадастр исәбе һәм теркәве өлкәсендә бик зур үзгәрешләр булды. Бу ТИБның кабул итү зоналарына консультация һәм күчемсез милекне квалификацияле теркәү мәсьәләләрендә өстәмә эшкә китерде. Әмма комплекслы якын килү, белгечләрнең тәҗрибәсе һәм предприятиенең күп еллар эчендә тупланган техник документация архивы Техник инвентарьләштерү бюросына теләсә нинди катлаулылыктагы милеккә дә документлар әзерләп бирүне башкарырга мөмкинлек тудыра.

Милек буенча бәхәсләрне чишүгә экспертиза һәм проект карарлары буенча техник бәяләмәләр бирү элеккечә үк предприятие эшчәнлегенең иң күп сорауга ия булган юнәлеше булып кала. Узган елдан башлап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары буенча бюрога эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә тормышка ашыра торган барлык техник инвентарьләштерү оешмаларының техник паспортларын, бәяләү һәм башка исәп-техник документациясен саклау да йөкләнде.

Республика ТИБ хезмәт күрсәтүнең экстерриториаль принцибын истә тотып эш йөртә. Документлар кабул итү һәм тапшыру зоналары бөтен республика буенча урнашкан, ә Казан шәһәрендә мондый зоналарның эше электрон чират ярдәме белән җайга салынган.

Реклама

ДӨРЕС ЮНӘЛЕШ
САЙЛАНГАН ОЧРАКТА

«Тулпар» холдинг компаниясе – Яр Чаллының Автозавод районында биш гектар җирне алып тора торган тулы бер сәүдә шәһәрчеге.

Наил Сөләйманов – икътисад фәннәре кандидаты, Россия Күмәртәләп азык-төлек сату базарлары берлеге генераль директоры урынбасары, Татарстан Республикасы Сәүдә предприятиеләре берлеге президенты, ТР Министрлар Кабинетының Кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү мәсьәләләре буенча Координация советы әгъзасы, ТР Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы.

«Тулпар»ның йөрәге, тарихының языла башлау ноктасы, тәүге баскычы – халык арасында Автозавод базары исеме белән танылган бүгенге Экобазар. Аның үзәк бинасы 1976 елда төзелгән һәм кайчандыр КАМАЗ җиһазларын урнаштыру өчен хезмәт иткән. Склад биналары төзелеп килә торган автогигант эшчеләре яши торган районны азык-төлек продуктлары белән тәэмин итү ихтыяҗы килеп чыккан вакыттан сәүдә ноктасына әверелә. Ә катлаулы 90 нчы елларда, күп кенә инженерлар, технологлар, конструкторлар, ихтыярсыздан, һөнәрләрен алмаштырып, квалификацияләрен «сатучы»га үзгәрткәч, базарның әһәмияте берничә мәртәбә арта. Ул, күп кенә эшсезләргә хезмәт урыны биреп, бик тиз киңәя һәм, кызганычка каршы, әкренләп шәһәр һәм аның тирәсендәге авылларның иң җинаятьчел нокталарының берсенә әверелә...

Аның тарихындагы яңа чор 2000 елның башында Яр Чаллы администрациясенең Автозавод базарын Наил Сөләйманов җитәкчелегендәге «Тулпар» сәүдә компаниясенә бирү турындагы карары чыгудан башланып китте. Берничә ел эчендә киң масштаблы үзгәртеп кору әлеге объектны алга киткән инфраструктуралы һәм күп кенә өстәмә хезмәт күрсәтүләре булган заманча универсаль базарга әйләндерде. Бүген бирегә 2500дән артык эшкуар хезмәт итә. Аренда түләве күләме буенча компания шәһәрдә иң лояль оешмаларның берсе булып санала. Соңгы еллардагы катлаулы икътисадый вазгыятькә дә карамастан, бирегә арендага бирелә торган мәйданның квадрат метры өчен бәя артмады.

Кайчандыр нәкъ менә «Тулпар»да бөтен ил масштабында үз тармагында бердәнбер булган Эшкуарларның иҗтимагый советы төзелде. Советның даими составында ике дистә кеше санала, аларның һәрберсе – актив тормыш позициясе булган зат. Әлеге совет карарларына нигезләнеп, 2000 нче еллар башында эшкуарларның эш шартларын яхшырту, аларны уңайлы итү буенча яңа юнәлешләр эзләү, предприятиеләрнең техник һәм санитар торышын нормага китерү буенча уртак эш башланып китте дә инде. Эшкуарлар базарны үзгәртеп кору, сатып алучылар өчен уңайлы шартлар тудыруда актив катнаша башладылар. Бүген «Тулпар» – «Ваклап сату базарлары турында...» 271 номерлы Федераль законны тулысынча үти торган бик сирәк компанияләрнең берсе.

«Тулпар» бинасы.

Сәүдә шәһәрчегендә бер-бер артлы яңа биналар файдалануга тапшырыла. Аларда сатучылар өчен дә, сатып алучылар өчен дә, шул исәптән мобиль булмаганнарын да исәптә тотып, уңайлы шартлар тудырыла. Монда махсус лифтлар, пандуслар, юл билгеләре бар. Сәүдә комплексына килә торган кеше санын ачыклау максатында үткәрелгән мониторинг эш көннәрендә – 10 меңнән артык, ял һәм бәйрәм көннәрендә 50 меңнән артык кеше йөрүен күрсәтте. Бүген «Тулпар» ике сәүдә-күргәзмә комплексын, европавильонны, 2нче номерлы сәүдә павильонын, «Автозавод» сәүдә комплексын, республикада беренче булган, хәзерге вакытта 4 мең квадрат метрдан артык мәйданга ия Экобазарны үз эченә ала. Экобазар концепциясе ул – традицион сәүдә форматының хәзерге заман сәүдә үзгенең уңайлылыгы, хезмәт күрсәтүнең югары дәрәҗәсе һәм сатыла торган продуктларның сыйфатын каттый контрольдә тоту белән бәйләнеше. Бинаны реконструкцияләү һәм төзекләндерүгә 170 млн сум акча тотылган.

2009 ел нәтиҗәләре буенча холдинг компаниясе, Россия Федерациясендә азык-төлек товарларын сату буенча иң яхшы предприятие буларак танылып, Бөтенроссия сәүдә предприятиеләре бәйгесендә җиңеп чыкты, ә Наил Сөләйманов Россия Федерациясе азык-төлек товарлары сату предприятиесенең иң яхшы җитәкчесе дип танылды. Чираттагы Бөтенроссия сәүдә предприятиеләре бәйгесендә «Тулпар» «Россиянең иң яхшы сәүдә комплексы» (2014) исеменә лаек булды.

Холдинг коллективының хезмәте лаеклы дәрәҗәдә бәяләнде: Наил Сөләйманов «Россиянең икътисадый куркынычсызлыгын тәэмин итүгә керткән өлеше өчен» Мактау билгесе белән бүләкләнде, ә ул җитәкләгән холдинг компаниясенә «Милли әһәмияткә ия предприятие» исеме бирелде.

Еш кына нәкъ менә әлеге компанияләр төркеме сәүдә өлкәсендә тәҗрибә алмашу мәйданына әйләнә, илебезнең азык-төлек куркынычсызлыгы мәсьәләләре һәм сатуның логистик системасын үстерү буенча зур әһәмияткә ия халыкара һәм бөтенроссия конференцияләрен кабул итә.

– Федераль җәмгать структуралары җитәкчеләренең берсе һәм эшкуар буларак, миңа еш кына илнең төрле төбәкләрендә булырга туры килә, – дип сөйли Наил Сөләйманов. – Чагыштырырлык әйберләр бар. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: Татарстан – бизнеска ярдәм күрсәтү ягыннан күп кенә параметрлар буенча шактый алга киткән төбәк. Икътисадый кризисның катлаулы шартларында алдыбызда торган авыр мәсьәләләр буенча хакимияттә аңлау табып, системалы проблемаларны чишүгә ирешәбез. Ә бу – бик зур эш. Тәнкыйтьләү җиңел, ә хәзерге халдә безнең республика җитәкчелеге кебек дөрес юнәлештән тайпылмыйча бару күпкә кыенрак...

«Тулпар» холдинг компаниясе» ЯАҖ
(8552) 59-62-02,
tulpar@list.ru
www.tulpar.biz

ГРУППА КОМПАНИЙ ТУЛПАР

Реклама

ЭШЛИСЕ КИЛӘ!

«Россиядә ике бәла бар: юлсызлык һәм ахмаклык», – дип әйтергә яратабыз. Ләкин тагын да җитдирәк проблема бар – эшсезлек. Югары уку йортларын тәмамлаган яшь белгечләр эш таба алмый азаплана, авыл кешесенең хәлен әйткән дә юк... Кризис белән бәйле яңа кыскартулар, зур оешмаларның банкротка чыгуы, хезмәт базарын тагын да киеренке хәлгә куйды.

Автор:
Руфия Рәхмәтуллина

САННАР – БЕР, ЧЫНБАРЛЫК – ИКЕНЧЕ

Хәер, рәсми саннар, барысы да яхшы, дип күрсәтә. Татарстан хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова узган елга нәтиҗә ясап, шундый саннар китерде: «Татарстанда эшсезлек дәрәҗәсе соңгы 20 елда иң түбән баскычка төште. 2015 елда бу күрсәткеч 0,9 процент күләмендә булса, 2016 елда ул нибары 0,7 процентка калды». Әмма Бөтенроссия җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге (ВЦИОМ) белгечләре, бу саннар чынбарлыктан ерак тора, ди. Дөреслектә аның төгәл санын берәү дә әйтә алмый. Статистика эш сорап мөрәҗәгать итүчеләр саны буенча төзелә. Бәлки аны Эш һәм мәшгульлек үзәкләрендә исәпкә басучылар дип әйтергә кирәктер. Һәрхәлдә, дөреслеккә якынрак булыр иде.

Республикада исә ел башына 14 мең 581 эшсез теркәлгән. Иң күп эшсезләр Казанда – 4 мең 426 кеше, аннан кала, Чаллыда – 1 мең 755, Түбән Камада – 1 мең 433, Әлмәттә – 960 кеше. Ни гаҗәп, авылларда эшсезлек чәчәк атмый, шәһәрләр белән чагыштырганда, халыкның бер проценты эшкә мохтаҗ икән. Бу аңлашыла да, авыл кешесе мәшгульлек үзәкләренә барып исәпкә басмый. Йә ул – сезонлы эштә, яки бөтенләй өендә утыра. Мәшгульлек үзәге белгечләре исә өйдә үз проблемаңа бикләнеп утырмаска киңәш итә. Теләге булган һәркем эш таба ала, дип ышандыра.

W-City Community Research тикшерү төркеме узган ел Россиядә эшсезлек иң югары ноктасына җитте дигән нәтиҗәгә килгән. Алар Россиянең төрле шәһәрләрендә яшәүче 10 мең кешесеннән сораштыру үткәргәннәр. Баксаң, һәр өченче кеше эш турында борчыла, кемдер кыскартылу алдында тора, кемдер өстәмә эш эзли, кайберәүләр бөтенләй эшсез икән. Шуннан чыгып, W-City Community Research тикшерү төркеме белгечләре, 30 миллион россияле эш эзли, дип фаразлый.

Республика мәшгульлек үзәкләренә төрле очракларда мөрәҗәгать итәләр. Мисал өчен, эш урыныннан канәгать булмаучы яки кыскартылу алдында торучы гражданнар да күп. Узган ел шундый 29 мең 976 кешегә вакытлы эш урыны табылган. Һөнәрен үзгәртү буенча аерым курсларга 7 мең 269 кеше җибәрелгән. Һөнәри уку йортларын тәмамлаган 227 егет-кыз да даими эшкә урнаштырылган. Физик мөмкинлекләре чикле булган 8 кешегә эш урыны бирелгән.

«КОЛХОЗ БЕТТЕ, АНЫҢ БЕЛӘН АВЫЛ ДА»

Статистика саннары авылларда эшсезлек зур түгел дип күрсәтсә дә, чынлыкта, мөгаен, иң зур проблема авыл җирлекләрендәдер. «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе рәисе Минсәгыйть Шакиров: «Аерым районнарда авыл халкы ел саен 2 процентка кадәр кими», – дигән иде. Мондый аяныч хәл аеруча Кама Тамагы, Тәтеш, Минзәлә, Чүпрәле районнарында күзәтелә. Чүпрәле

Фотолар ТР Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы матбугат хезмәтеннән алынды.

районында, мәсәлән, ел саен халык саны уртача 500 кешегә кими икән. Әлегә дә баягы, мөэзин абый таягы дигәндәй, сәбәбе тагын шул эшсезлеккә кайтып кала. Районның икътисад һәм финанслар бүлегендә моның сәбәбен төрлечә аңлаттылар: авылда яшьләр калмый, шәһәргә китү ягын карый. «Яшь белгечләргә зур хезмәт хакы кирәк, район җирендә андый мөмкинлекләр юк», – диделәр.

Иске Кәкерле авыл җирлеге башлыгы Сәхәветдин Хөсәенов исә Чүпрәле районында халыкның кимүен колхозлар бетүдә күрә. Унбиш ел «Ялкын» колхозын җитәкләгән ул. Аннан 2005 елда аны авыл җирлеге башлыгы итеп сайлаганнар.

– Иске Кәкерле Чүпрәленең иң зур авылларыннан санала, – дип сөйләде Сәхәветдин Хөсәенов. – Авылда 1025 кеше яши, Иске Кәкерле җирлегенә Татар Төкесе дә керә. Анда 241 кеше гомер итә. Заманында авыллар гөрләп торды. Колхоз нык, бар халыкны эш белән тәэмин итте, меңәрләгән баш дуңгыз, сарык, сыер гына бар иде. Колхозлардан агрофирма ясау башлангач, безне дә «Ялкын» коллектив хуҗалыгыннан Чүпрәле «Ак Барс» холдингы канаты астына керттеләр. Нәтиҗәсе күз алдында: сарык, дуңгызлар бетерелде, фермалар ярым ишелгән хәлдә, 650 башка якын мөгезле эре терлек калды. Аңлашыла ки, авыл кешесенә эш кимеде. Авылның бетүендә төп сәбәп менә шушы, дип уйлыйм.

Мондый фикерне күп кенә элеккеге колхоз җитәкчеләреннән ишетергә туры килә. Яшерен батырын түгел, зур холдингларның төп максаты – акча эшләү, ә авыл кешесенең тормышы, көнкүреше аларны кызыксындырмый. Шулай да күп төбәкләрдә заманга яраклашырга тырышалар: аерым кешеләр үз эшләрен булдыра, гаилә фермалары төзи, читкә йөреп эшли. Иске Кәкерледә дә алма агачтан өзелеп төшкәнне көтеп ятмаучылар бар.

– Ирләрнең күбесе Мәскәү, Казан, Ульяновск, Оренбург, Уфа шәһәрләренә йөреп эшли, – диде Сәхәветдин Хөсәенов. – Безнең халык тырыш бит, тик утырмый. Берәүләр теплица ачты, гаилә фермалары төзүчеләр дә бар. Ләкин яшерен-батырын түгел, авылга яшьләр кайтмый. Бүген Иске Кәкерле урта мәктәбендә 95 бала укый. Балалар саны елдан-ел кими. Моңа гаҗәпләнәсе юк, яшь гаиләләр булмагач, сабыйлар тумый бит.

Элеккеге колхоз рәисе белән авылның киләчәге турында шактый озак сөйләштек. «Чиста су» республика программасы буенча һәр йортка су керткәннәр, халыктан җыелган үзара салым акчасына өч ел инде юлларны карыйлар икән. Бу эшне алга таба да дәвам итәргә исәплиләр. Мәдәният йорты, мәчетләр, берничә

PRESSA.RU

кибет эшләп тора. Тик авылда халык саны барыбер кими бара, ә сәбәбе һәркемгә мәгълүм: эш булмагач яшьләр авылга кайтмый, төпләнеп калганы да читкә китү ягын карый.

АРЧА ҮРНӘГЕ

Чүпрәледән аермалы буларак, Арча районында эшсезлек 0,6 процент тәшкил итә. Бу республика күрсәткеченнән дә түбәнрәк. Хәер, аңлашыла да кебек: Арча Казанга орынып тора, халык башкалага йөреп эшли. Күпләр үзе җитештергән авыл хуҗалыгы продукциясен дә Казанга алып килеп сата. Ләкин эшсезләр саны аз булуның башка сәбәпләре дә бар:

– Арча районында җитештерү предприятиеләре шактый күп, – дип сөйләде районның икътисад һәм финанслар бүлеге җитәкчесе Зөлфәт Шәрәфетдинов. – Аерым саннарга тукталсак, сөт комбинатында – 300, кирпеч заводында – 230 кеше, элеваторда – 110, сэндвич-панельләр заводында – 30, «Раифа» тегү фабрикасында 40 кеше хезмәт куя. Соңгы ике предприятие 2016 елда гына эшен башлады. Көннән-көн зурая алар. Тагын районда алты төзелеш оешмасы бар, анда 1 меңгә якын кеше эшли. Бюджет оешмаларында 4 мең 700 гә якын кеше хезмәт итә. АТП, «Водоканал-Сервис» һәм шундый башка оешмаларда 500 кеше эшли.

Арчада якын киләчәктә тагын меңнән артык эш урыны булдырырга җыеналар. Мисал өчен, 2014 елда ачылган сәнәгать паркын быел зурайтачаклар. Анда ит, сөт ризыклары сатыла. Парк базасында 5 гектар мәйданда теплица кору каралган. Җәмгысе бередә 300 кешегә эш урыны ачылыр, дип көтелә. Шулай ук агымдагы елда балалар күңел ачу үзәге төзеләчәк. Казандагы «Кырлай» паркыннан ким булмас, дип көтелә. Биредә 80 кеше эшләргә тиеш. Киләсе елга исә Арчада бәрәңге эшкәртү комбинаты сафка басачак. Бәрәңгедән ярымфабрикатлар ясап республика кибетләренә җибәрергә ниятлиләр.

– Районыбыз зур: 52 мең 300 кеше яши, шуның 23 меңе Арчаның үзендә көн итә, – дип сүзен дәвам итте районның икътисад һәм финанс бүлеге җитәкчесе. – Бездә ел саен халык саны үсә бару күзәтелә. Бу беренче чиратта Арча шәһәре хисабына шулай. Авылларда исә төрлечә, халык саны арткан, кимегән яклар да бар. 2014 елда гамәлгә кертелгән аерым проектлар нәтиҗәсендә, республика муниципаль районнары буенча төзелгән рейтингта 39нчы урыннан 32нче урынга күтәрелдек. Авыл хуҗалыгы районы өчен бу сан начар, дип уйламыйм. Алга таба тагын үсәргә ниятлибез.

Арчада бер проблема да юк икән дигән фикер туарга мөмкин. Бар, әлбәттә, ансыз булмый. Иң төп проблема – яшь белгечләрнең туган ягына әйләнеп кайтырга ашыкмавы. Монысы инде хезмәт хакы, торак белән дә бәйле. Районда хәзер яшь белгечләргә дәүләт программасы буенча фатирлар салу, төрле грантлар алырга ярдәм итү буенча ныклап эшлиләр.

«КРЕСТЬЯН-ФЕРМЕР ХУҖАЛЫГЫНА ӘЙЛӘНДЕК!»

Арчаның яңа төзелгән йортларын, Боз сараен карап чыкканнан соң, Мәтәскә авылына кузгалдык. Районда бүген җитмешләп фермер хуҗалыгы бар. Айдар Сабиров исә Арчаның иң алдынгы фермеры. Аның турында ишеткәч, гаҗәпкә дә калдым: бер тәҗрибәсе дә булмаган килеш эшен башлар өчен миллионлаган кредит алган. Үзе әйткәнчә: «Кесәсендә 12 сум 50 тиен акчасы булган». Гаиләсе белән шәһәрдә яшәгән ир тормышындагы кискен борылышны болай аңлатты:

– Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясен тәмамлагач та хыял бар иде: авылда үз эшемне булдыру. Берничә юнәлешне карадым, җир эшкәртеп печән, иген үстерү белән шөгыльләнергә кирәк, дигән уйга килдек. Шулай итеп, 2010 елны агрофирмадан үзебезнең, тагын берничә дусның пай җирләрен алып, чәчү чәчтем. Техниканы арендага алдым. 2012 елда крестьян хуҗалыклары өчен «Яшь фермерларга ярдәм итү» республика программасы эшли башлады, документларны җыеп, район авыл хуҗалыгы идарәсенә тапшырдым. Теләк-максатым дистә баш мөгезле эре терлек алып үрчетү иде. Бу эш миңа кечкенәдән таныш: әтием күп еллар ферма мөдире, әнием сыер савучы булып эшләде. Өйдә дә күп итеп мал асрадык. Район җитәкчелеге минем ниятне бик хуплады, әлеге программа буенча 1 миллион сум грант алырга ярдәм итте. Яныпкөеп эшли башладым. Күрше Карабаш авылында иске ферма биналары бар иде, шуларны сатып алып өр-яңадан ясап чыктым. Әлбәттә, кредитсыз булмады: 2012 елда банктан 8 миллион сум акча алдым. Мөгезле эре терлекнең баш санын 30дан 180 гә җиткердек.

Айдар Сабировның Карабаш авылында 5 фермасын карап чыктык. Бу без күреп өйрәнгән тизәккә

баткан хәрәбәләр түгел, бөтен җире ялт иткән. Заманча гына дию аз, Европа югарылыгында. Бер ноктага басу җитә – бар техника «җанлана».

– Сезон вакытында 20 кеше эшли, ә даими рәвештә бездә 13 кеше хезмәт куя, – дип сөйләде Айдар Сабиров. – Февраль ае башында «Вамин» таралды. Район җитәкчелеге аларның 750 баш мөгезле эре терлеген, 2 мең гектар җирләрен миңа алырга тәкъдим итте. Без хезер аерым бер крестьян-фермер хуҗалыгына әйләндек, дөрес, әле рәсмиләштерәсе бар. Кәгазь эше шактый вакытны ала. Планнар зурдан, Аллаһ Тәгалә ярдәменнән ташламас, дип өметләнәм. Җиңел булмаячак, аңлыйм. Фермер булганыма җиде ел була, әле яңа гына эшем табыш китерә башлады. Кергән акча кредит түләргә китеп бара иде. Шулай да сыер асрау бүгенге көндә иң табышлы өлкә, сөткә бәя югары. Шуңа күрә барысы да яхшы булыр, дип ышанам.

Ике ел элек яшь фермер, үзләре сауган сөтне, ясаган эремчекне Казанга илтеп саткан. Ризыкларны урамда сату буенча яңа таләпләр куелганнан соң, Айдар Казанга йөрүен туктаткан. Район җитәкчелеге монда да фермерга ярдәм кулы сузган: Арча базарында сөт, эремчек сату өчен аерым лавка булдырганнар. Ризыклар көнендә сатылып бетеп бара икән.

Мәтәскә фермерының гаиләсе белән дә танышып чыктык, Айдар тормыш иптәше Гөлназ белән өч бала үстерә. Олы кызлары Азалиягә унике, уртанчысы Айгизәгә – тугыз, Аязга биш яшь.

– Айдарга әллә ни ярдәм итә алмыйм, шулай да киңәшләшеп эшлибез, – дип елмайды Гөлназ ханым. – Мин дә авыл хуҗалыгы академиясенең икътисад факультетын тәмамладым. Бу өлкәне яхшы беләм. Ләкин өч бала булгач фермерлык эше белән шөгыльләнергә вакыт бик калмый. Балалар кул арасына керә башладылар инде, эшкә планнар зурдан...

Сабировлар якын киләчәктә үзләре сауган сөтне Казанга, башка өлкәләргә җибәрергә уйлый. Сөт ризыклары ассортиментын киңәйтеп, махсус капларга төреп эшләргә ниятлиләр. Ә бүген алар яңа алынган җирләрне чәчүгә әзерләү, фермаларны төзекләндерү белән мәшгуль.

...Нәрсә генә булса да, мәшгульлек үзәкләренә барырга кирәк, дигән нәтиҗәгә килдем. Эшсезләр өчен махсус программалар барлыгын иң беренче шунда белеп була. Аннан, ай саен 850 сумнан 4 мең 900 гә кадәр акча килеп бара (бу кешенең элеккеге эшендә күпме хезмәт хакы алуына бәйле). Ятып калганчы, атып кал дигәндәй, бәлки күңелгә ятыш берәр эш тә килеп чыгар.

Клара Таҗетдинова, ТР хезмәт, мәшгульлек һәм халыкны социаль яклау министры урынбасары:

– Республика хезмәт базарында хәл тотрыклы. Бу җәһәттән махсус программалар эшли. Алар берничә максатны күздә тота: аерым оешмалар банкротлыкка чыгып, эшсез калган кешеләргә ярдәм итү; халыкның керемен арттыру; икенче һөнәр үзләштерергә ярдәм итү һ.б.

2017 елның 1 февраленә республика буенча 26 мең 353 ачык вакансия бар. Ихтыяҗ төзелеш, эшкәртү сәнәгате, транспорт өлкәсендә аеруча зур.

Шулай ук үз эшләрен булдырырга теләүчеләр өчен дә махсус программалар бар. Мисал өчен, узган ел мәшгульлек үзәкләренә мөрәҗәгать иткән 469 граждан үз эшен ачты. Аерым алганда, Әлмәт районында – 30, Кукмара районында – 22, Саба районында – 21, Чистай районында – 20, Яшел Үзән районында – 15, Буа районында 15 кеше шәхси эшкуар, фермер булып теркәлде.

Республика мәшгульлек үзәкләрендә эшсезләр өчен махсус психологик ярдәм һәм хезмәт базарына социаль адаптация буенча аерым курслар оештырылган. 18–20 яшьлек гражданнар өчен «Беренче эш урыны» дигән программа эшләнгән. Аның нигезендә яшьләргә вакытлыча эш урыны тәкъдим ителә. Социаль яклауга мохтаҗ булган гражданнарның аерым төркемнәре (физик мөмкинлекләре чикле кешеләр, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче ялгыз һәм күп балалы аналар, төрмәдән чыгучылар) өчен, алар үз эшләрен ачкан очракта, аерым компенсацияләр түләү дә каралган.

PRESSA.RU

МОЛЕКУЛАГА... ЭНЦИКЛОПЕДИЯ СЫЯ!

Казан галимнәре оптик мәгълүматны яздыру һәм саклауның яңа принцибын ачтылар. Бу безнең замандагы иң масштаблы бурычларның берсен хәл итүдә ачкыч булырга мөмкин.

Автор:
Ольга Туманская

РОБОТЛАР ЯНӘШӘДӘ ГЕНӘ

Без – Казан федераль университетының нанооптика буенча фәнни-тикшеренү лабораториясендә. Сергей Харинцев тактада графика ясый: Интернет һәм ясалма интеллект дәверендә кешелек тормышын тулаем үзгәртә алмаса да, сизелерлек дәрәҗәдә яхшырта алырдай ачышның асылын шул сызымнар ярдәмендә аңлатмакчы була.

– Күп дигәндә, өч-биш елдан соң, сезнең суыткычыгыз, тостер һәм кофе пешерә торган җайланмагыз, хәтта кухнягызның стенасы ук тулысынча интерактив булачак, – дип дәвам итә сүзен галим. – Суыткыч ул нәрсә, киемегез дә шундыйга әвереләчәк. Бүгенге көндә әйберләр интернеты күз иярмәслек тизлек белән үсә.

КФУ доценты сурәтләп биргән киләчәктә мәгълүмат безне тәмам урап алачак икән. Мобиль кушымталар, социаль челтәрләр, болыт-сервислар һәм ясалма интеллектның гаҗәеп тизлек белән үсеш кичерүе нәкъ менә шушыңа китерәчәк, әгәр аның сүзләренә ышансак. Тиздән, ди ул, кулдан ясалган һәрбер әйбер челтәргә урнаштырылачак һәм, дөньякүләм матрицаның бер өлеше буларак, акылга сыйдыра алмас күләмдә мәгълүмат тарата башлаячак. Киләчәктәге иң төп проблемаларның берсе дә, фаразлар буенча, нәкъ менә шул булачак – мәгълүматны саклау.

МИЛЛИОНГА ТОРЫРЛЫК ИДЕЯ

«Россиядә җитештерелгән оптик дисклар миллион тапкырга күп сыйдырышлырак булачак!» Яңа ел алдыннан мондый башисемнәрне күп кенә абруйлы ММЧның беренче битләрендә күрергә була иде. Фәнни яктан рецензияләнгән Nanoscale журналында басылган мәкаләгә сылтама ясап, алар «оптик мәгълүмат яздыруның перспективада бер дискка миллион тапкырга күбрәк күләмне сыйдырып була алырдай яңа ысулы» турында хәбәр иттеләр. Хәер, авторлар үзләре бу табышны купшы эпитетлар белән атау ягында тормый һәм аңа зур киләчәк юрарга да ашыкмый.

– Моны революцион идея дип атау бик үк дөрес булмас иде, – дип, үз позициясен белдерүне кирәк таба Харинцев. – Ул инде япон галиме Сатоши Кавата тарафыннан белдерелде. Безнең казанышыбыз – нибары аны, башка яктан якын килеп, яктылыкның гигант комбинацион таралышы эффектына нигезләнеп, тормышка ашыру гына.

Бүген виртуаль мәгълүмат дата-үзәкләрнең махсус саклагычларында туплана һәм тотыла, болар – асылда гаять зур биналар. Әлегә хисап эксабайтларда бара (10^{18}). Бу күләмне күз алдына китерер өчен, гади генә мисал китерик. 100 петабайт (10^{15}) мәгълүматны «төягән» 13 метрлы контейнерлар урнаштырылган йөк машиналары 1 эксабайт мәгълүматны бары тик ярты ел эчендә генә ташып бетерә ала. Һәм бу ысул чынлап та үтемле исәпләнә, чөнки мәгълүматны челтәр аша, мәсәлән шул ук «болыт»тан бушату 26 еллап вакытны таләп иткән булыр иде. Хәтта секундына 10 гигабит тизлек булган очракта да.

– Мәгълүматның күләме экспонента буенча үсә, – дип сөйли Сергей Харинцев. – Без инде зетабайтларда (1 Зб = 10^{21}) исәпли торган чиккә җиттек. Дөнья челтәре күзлегеннән караганда, бу алай ук күп тә саналмый. Ә менә аларны яздыру һәм саклау заманның иң масштаблы бурычларыннан берсе булып тора. Шулай булгач, без башкармый, кем башкарсын моны!

Оптик мәгълүматны яздыруның тыгызлыгын арттыру өчен, бу мәгълүмат саклана торган пространствоның күләмен даими кечерәйтеп тору кирәк. Элементар хәтер ячейкалары сыйфатында аерым бер молекулаларны файдалану ноктасына кадәрле. Әмма моны ничек башкарырга соң? Казан галимнәре бу сорауга җавап таптылар.

УТ КЫНА БУЛСЫН!

Лазер тәэсиренә бәйле рәвештә, молекулалар, пространствода үзләренең урынын үзгәртеп, оптик кыр артыннан хәрәкәт итә алалар. КФУ физиклары моны беренче булып күреп алучылар булмый булуын. Әмма башкалар берьюлы миллионлаган молекуланы шул рәвешле бору белән мәшгуль булса, безнекеләр исә локаль рәвештә юнәлтелгән лазер уты ярдәмендә һәрберсенең пространстводагы ориентациясе белән идарә итәргә өйрәнә.

– Ялгыз молекула зурлыгы буенча нибары бер нанометрны тәшкил итә, шул ук вакытта ут дулкынының озынлыгы биш йөз тапкырга артыграк, – дип, тактада ниндидер билгеләр ясый Харинцев. – Аңлыйсыздыр, мондый ут ярдәмендә без молекула белән идарә итә алмыйбыз, чөнки алар фил белән тычкан кебегрәк булачаклар. Проблеманы утны берничә нанометрга кадәр кысып хәл иттек, шуннан соң инде аерым бер молекулалар белән идарә итү мөмкинлеге барлыкка килде.

Шул рәвешле галимнәр үзләре алдында торган олы бурычның төп өлешен хәл итүгә ирештe, ягъни мәгълүматны яздыруның тыгызлыгын арттырды. Миллион тапкырга, ягъни гигабайттан

Фото: Александр Эшкинин

бер квадрат дюймлы петабайтка кадәрле. Мондый сыйдырышлыкка ия булган оптик дисклар киләчәктә болыт-сервисларның һәм дата-үзәкләрнең нәтиҗәле эшчәнлеген һәм җитештерү сәләтен көчәйтәчәк. Алай гына да түгел, «дөнья базарындагы традицион хәтер типлары структурасына сизелерлек үзгәрешләр кертергә дә мөмкиннәр». Дөрес, Харинцев әйтүенчә, бу юнәлештә эшләнәсе эшләр шактый күп әле. Молекуланың ориентациясе белән идарә итәргә өйрәнү – бер нәрсә, ә менә аның торышын озак вакыт дәвамында саклый алу – монысы инде икенчерәк.

– Бу торыш-халәтнең ультрафиолет, югары температуралар, механик стресслар вакытында нинди үзгәреш кичерүен тикшерү дә сорала... Әлеге гамәли бурычны хәл иткәннән соң гына, хәтер ячейкасының прототибын ясарга керешә алачакбыз. Моның өчен 3 елдан алып, 5 елга кадәр вакыт таләп ителергә мөмкин.

АЧЫШЛАР ҺӘМ АЛАРНЫҢ ЯЗМЫШЛАРЫ

Бүгенге көндә безнең илебездә идеяләр туа торган академик университетлар белән әлеге идеяләр нигезендә эшли алырдай һәм технологияләрне җайга салуны тәэмин итәрдәй гамәли институтлар арасындагы бәйләнеш тәмам өзелде, дисәк тә була. Күп кенә ачышлар, үзләренең техник кулланылышын таба алмыйча, лаборатория стеналарында «бикләнеп» калалар. Чөнки базардагы сорау һәм аңарга булган тәкъдим законнары һәрвакытта да уңышлы эшләп китми, һәр ачыш – куркыныч астында. Менә бу яңа яздыру ысулын куллануның да сатудагы эффектын анык кына билгеләп булмый: карар йә артык кыйммәткә төшәргә мөмкин, йә булмаса – технологик яктан үтемсез булырга.

– Без лабораториябездә бизнес белән шөгыльләнмибез, – дип, ситуациягә ачыклык кертергә тырыша Сергей Харинцев. – Без ачышлар ясыйбыз, яңа белемнәр үзләштерәбез һәм аларны сезгә дә җиткерәбез. Шуңа да безнең өчен иң мөһиме – физиканың яңа принципларын ачу, ә инде мәгълүмат саклау чарасын җитештерүчеләр кулланачакмы, юкмы, монысын вакыт күрсәтер.



КФУдагы Сергей Харинцев җитәкчелек итә торган нанооптика лабораториясе өчен көнүзәк булган идеяләр, нигездә, ут белән дифракция чигеннән узып идарә итү, ягъни аны бик нык кысу белән бәйле. Галимнәр моны махсус оптик наноантенналар ярдәмендә башкара. Сүз уңаеннан, бу утны хәтер белән бәйле бурычларны үтәү өчен генә түгел, ә башка фундаменталь һәм гамәли бурычларны хәл итәр өчен дә кулланалар. Мәсәлән, органик кояш батареялары яисә нанокүләмле яктылык чыганаклары булдыру кебек «башваткыч»ларны чишкәндә. Бәлки, бу мәсьәләләрне чишү тагын бер ачышка китерер. Ничек кенә булмасын, ул ачыш кешелек дөньясының астын-өскә әйләндереп кенә калмасын, ә аны яхшыртырга да ярдәм итсен иде.

PRESSA.RU

Әхмәт Мәзһәров – күкерт-органика химиясе, нефть һәм газ эшкәртү, нефть чистарту процесслары технологияләре өлкәсендә дөньякүләм танылуга ия галим. Ике йөздән артык фәнни хезмәт, 137 патент һәм дөньяда нефтьне беренче демеркаптанизацияләү процессы авторы. 2006 елдан 2014 елга кадәр – ТР Фәннәр академиясе президенты. 1982 елдан Волжск углеводород чималы фәнни-тикшеренү институтын җитәкли. 2013 елда «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлар өчен» ордены белән бүләкләнә.

КАРА АЛТЫНГА ТУГРЫЛАР

Ольга Туманская
әзерләде

«Рухым белән мин, җитәкче булуга караганда, күбрәк тикшеренүчедер», – дип сөйли академик Мәзһәров. Хәер, тегесен дә, монысын да бертигез дәрәҗәдә яхшы итеп башкара ул. Ә дөньякүләм танылуны аңа Россиядә, АКШта, Иранда, Болгариядә, Франциядә, Голландиядә һәм башка илләрдә тормышны уңайлы иткән ачышлар китерә.

ПРОБИРКАДАН ҮСЕП ЧЫККАН ЗАВОД

– 70 нче елларда Оренбургта газ конденсаты чыганагын ачалар. Аның сыек өлешен – җиңел нефтьне, һәм шулай ук пропан белән бутанны Салават шәһәренә озаталар. Бу каланы тулысынча газлаштырырга мөмкинлек бирә! Безне тиз генә шунда юлладылар. Иң эре химия комбинатының баш инженеры минем белән йөреп, технология буенча җайланмаларны ничек үзгәртергә кирәклеген акбур белән билгеләп барды. Безнең арттан ук эшчеләр эретеп ябыштыра бардылар. Шуңа да мин һәрвакыт кирәкле, ихтыяҗ булган эш белән шөгыльләндем дип әйтә алам: колбадан башлап, завод төзелешенә кадәр. Chevron нефть компаниясенә иң эре технологияне гамәлгә ашырырга мөмкин булды.

Бу 1995 ел иде, америкалылар Казахстанда Тенгиз чыганагын сатып алдылар. Анда нефть яхшы, җиңел, әмма меркаптан күкерте катнашмасы бар, исе бик яман. Чистартырга кирәк. Дөньяда андый технология юк, ә бездә, Татарстанда, ул инде бар иде – бу турыда америкалыларга «Транснефть»тә җиткергәннәр. Килделәр алар безгә, халатлар киеп алдылар, эксперимент ясарга керештеләр. «Менә сезнең нефть – карагыз, ул начар исле, ә менә безнең технология ярдәмендә ниндигә әйләнә», – дип күрсәтәм үзләренә. «Сере нидә?», – дип сорыйлар. Катализаторда. Сынау өчен катализаторны бирдем. Берничә көннән шалтыраталар: «Алабыз!» Бер ел эчендә җайланманы эшләтеп җибәрделәр, ә аннан соң – тагын берсен. Хәзер АКШта 12 млн тоннадан артык нефтьне Казан технологиясе буенча чистарталар.

«Карале, син америкалыларга проблемаларын хәл итеп бирдең, ә үзебезнең «Татнефть»тә зарланалар», – диде миңа шуннан соң Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов. «Анда башка нефть, – дим, – авыр». «Эшләгез соң!» Ярты елдан соң Нурлатта авыр нефтьне күкерт водородыннан һәм меркаптаннан чистарту җайланмасын эшләтеп җибәрдек. Бүген безнең технологияләрне бөтен дөнья күләмендә кулланалар. Россиядә генә дә мондый установкалар иллеләп артык. Якындагы планнар – Иранда куәтле установканы эшләтеп җибәрү – чират буенча дүртенчесен.

ЮГАЛЫП КАЛМАУ ҺӘМ ҖИТЕЗ АЯКЛАР

– Рухым буенча мин галим, әмма җитәкчелек итү дә начар килеп чыкмый – мин яхшы мәктәп үттем. КХТИ тәмамлаганнан соң, юллама буенча Куйбышев синтетик спирт заводына эшкә килгәч, баш инженер Ризван Чанышев миңа болай диде: «Беләсеңме, әйдә әле, син аппараттан башла әле!» Ярты ел эшләдем – барысына да өйрәндем. Цех башлыгына кадәр үстем. Әлеге тәҗрибә миңа тормышта шулкадәр кирәк булды! Контингент бездә бик катлаулы иде: 150 кешенең яртысы – элеккеге җинаятьчеләр. Әле бит спирт җитештерелә! Ләкин мине хөрмәт итәләр иде – технологияне бик яхшы белгәнем һәм аякларымның җитезлеге өчен. Чаңгы буенча завод командасы тренеры – куып җитәрлек түгел! Гадәттән тыш хәл килеп чыгуга, цехтагыларның барысы да чыгып йөгерә, ә мин бишенче катка атылам – җайланмаларны сүндерергә, аварияне туктатырга. Бу тизлек нәтиҗәсендә берничә мәртәбә шартлаудан котылып калдык. Мин заводка килгәндә үк цех җимерек иде. Мин китеп бер ел үткәннән соң шартлау булган – өлгерә алмаганнар…

Ник киттемме? Кызык булмый башлады. Өч ел эчендә цехны артта сөйрәлүчедән алдынгылыкка чыгара алдык. Күп кенә яңалыклар керттек. Ләкин кайчак шулай да булгалады: кич белән өйгә кайткандә – бар да яхшы, эш бара, ә төнлә, шайтан алгыры, эчәләр, нәрсәне булса да ваталар, авария китереп чыгаралар, тагын барысы да җимерелә… Әйләнә буенча йөгерү кебек тоела башлады. Уйга калдым: ничек итеп миңа уйлап табучылар арасына эләгергә икән, ышанычлы, ныклы, беркем дә вата алмый торган җайланмалар эшләргә! Шулвакыт безгә МХТИдан делегация килде. Уй-фикерләрем белән уртаклаштым, һәм тиздән атаклы профессор Лебедев – СССР Дәүләт премиясе лауреаты, әлеге институтның кафедра мөдиренә әңгәмәгә чакыру алдым. Күпчелек аның хәерхаһлы булуы аркасында мин галим юлын сайладым.

БЕР ФУНДАМЕНТ ТАШЛАРЫ

– Күренекле галим-механик Роберт Нигъмәтуллинның әтисе – профессор Искәндәр абый – үз халкының патриоты иде. Татар һәм башкорт тамырлары булган Мәскәү аспирантларын үзенең дачасына чәйгә чакыру гадәте бар иде аның. Мин дә шул даирәгә эләктем. Роберт белән шунда таныштым. Күп еллар узганнан соң, әлеге дуслыгыбыз аркасында диярлек булдыр, мин аны безнең академия эшенә тарта алдым. Аның белән бергә заманыбызның башка атаклы галимнәрен – Рәшит Сюняев, Роальд Сәгъдиев, Мәхмүт Гәрәевне дә. Һәм бары тик яңгыравык исемнәр генә түгел иде бу! Алар безгә килеп, лекцияләр уку, фәнни җитәкчелек итү өчен килә иде. Ике мәртәбә без татар галимнәренең бөтендөнья форумын оештырдык. Бу безгә танылу алырга ярдәм итте: бөтен дөнья безнең үз академиябез һәм бөек галимнәребез барлыгын күрде. Бу Татарстанга менә дигән реклама түгелмени? Республиканың абруен спорт кына түгел, фән дә күтәрә бит. Болар барысы да бер фундамент ташлары.

ХИМИЯНЕҢ АЛТЫН ЧОРЫ

– Миңа нефть фәне һәм сәнәгатенең алтын чорында эшләргә насыйп булды. Бу КПСС Үзәк комитетының 1958 елгы май пленумы карарларыннан соң, СССРда елына икешәр химия заводын сафка бастырган еллар иде. Без минераль ашламалар җитештерүдә беренчелеккә чыктык, нефть эшкәртү буенча дөнья дәрәҗәсенә күтәрелдек. Һәм барысы да илебез технологияләре нигезендә. Соңгы 25 ел эчендә Россия бары тик бер генә химия заводы – «ТАНЕКО»ны гына эшләтеп җибәрә алды.

Үз вакытында МДУның химия факультеты деканы академик Лунин үзенең Россиядәге коллегаларын берләштерә һәм укытуның иске программасын саклап калауга ирешә. Бүген, КФУ химфак студентлары каршында лекция укыганда, мин бу егет-кызларның белем дәрәҗәсе гаять югары булуын билгеләп үтә алам. Тиздән алар бик яхшы әзерлекле, кызганычка, ихтыяҗ аз булган белгечләр булачак. Утыз процентлабы аспирантурада калачак. Калганнары кайсы кая юл тотачак…

ФӘННЕ НИЧЕК ЭШЛӘТЕРГӘ

– Санкцияләр күпмедер дәрәҗәдә илебез фәне өчен уңай булды, дип әйтергә була. Безгә ешрак мөрәҗәгать итә башладылар. Әлбәттә, мин аңа «бик яхшы» куя алмыйм – 90 нчы елларда артык күп югалттык шул. Шулай да Татарстанда безгә барыбер кадрларны, фән юнәлешләрен, фәнни мәктәпләрне саклап кала алдык. Болар барысы да күпчелек республиканың беренче Президенты Минтимер Шәймиевның ярдәме, аның ТР Фәннәр академиясен төзү идеясен хуплавы нәтиҗәсендә мөмкин булды. Без ул чакта гамәли институтларны ашык-пошык үзгәртеп корудан, кадрлар алмашыннан, милекне сатып бетерүдән яклярлык алгоритм эшләдек. Академия белән килештерми генә андый эшләрне хәл итү мөмкин булмый башлады. Алга таба аларны консорциумга берләштерергә, алар киләчәктә үсә алсын өчен, Фәнне финанслау фондын төзергә тиеш идек. Әмма кайбер сәбәпләр аркасында моны эшләп булмады. Ә идеясе менә дигән – мин бүген дә аннан баш тартмыйм.

Миңа калса, «бөтен фән университетларда яши һәм үсә» дигән заманча агым яшәүгә сәләтле түгел. Һәрхәлдә, якын араларда. Дөнья тәҗрибәсе түбәндәге чылбырга таяна: идея университетларда туа, ә алга таба ул гамәли институтларга күчерелә. Анда аны, технологияләргә әйләндереп, эшләп бетерәләр. Сүз уңаеннан, СССРда да шулай иде. Сикереп узу мөмкин түгел! Кайчан әле университет үзенең технологик базасын булдырачак? Бүген бу элемтәләр югалган диярлек. Нәтиҗәсе шул: хәзерге вакытта технологияләрнең 90 проценты чит илләрдән сатып алына. Шул ук «ТАНЕКО»да ун установканың бары тик икесе генә – Россиянеке. Нишләргә? Тармак институтларын үстерергә.

КОРПОРАТИВ НӘТИҖӘЛЕЛЕК

90 нчы елларга без генә Chevronга ярдәм итмәдек, алар да безгә булышты. Беренчедән, америкалылар акча түләделәр, ә, икенчедән, безнең институт дөнья күләмендә танылды. Әлеге дулкында без яхшы яшәдек, безгә ихтыяҗ булды. Нефтьне демеркаптанизацияләү буенча булган эре проблемаларның барысы да хәл ителде, ә шундый ук күләмдәге яңалары тумады. Һәм безнең өчен тагын авыр вакытлар җитте. Хәер, безнең өчен генә түгел, бүген ил буенча да, дөнья күләмендә дә мондый юнәлештәге институтларга мөстәкыйль яшәү шактый катлаулыга әйләнде. Күбесе «Роснефть», «Лукойл» кебек эре компанияләр составына керде. Безгә дә чират җитте.

Бүген без бер эре нефть компаниясе белән принципиаль килешүгә ирештек. Барлык серләрне дә берьюлы ачмыйм, әмма шунысын гына әйтә алам: инде быел ук без аның составына керергә җыенабыз. Безнең ФТИ өчен бу – авырлыклардан котылу юлы, ә компаниянең куәтле фәнни базасы барлыкка киләчәк. Бүген корпорацияләрнең моңа кискен мохтаҗлыгы күзәтелә. Әгәр элегрәк фән бердәм министрлык канаты астында барлык заводлар мәнфәгатьләре өчен эшләп, бернинди дә сер булмаган булса, бүген федераль компанияләрнең үз институтлары, серләре, үзара көндәшлеге барлыкка килә башлады.

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән ТР дәүләтчелеген үстерүдә, гражданнарның хокукларын һәм азатлыгын тәэмин итүдә, икътисад, мәдәният, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, сәнгать һәм спортны үстерүдәге зур казанышлар, шулай ук җәмәгать тәртибен саклауда күрсәткән кыюлык һәм батырлык өчен бүләкләнәләр. Әлеге билге 925нче пробалы көмештән эшләнгән.

PRESSA.RU

ИНЖЕНЕР ПЬЕДЕСТАЛЫ

Россиянең күп кенә башка төбәкләрендәге кебек, февраль башында Татарстанда да чираттагы «Яшь профессионаллар» чемпионаты узды. Бу бәйгедә республикадагы техникум һәм көллиятләрнең 17 яшьтән 22 яшькә кадәрге укучылары катнашты. Әлеге ярышларда яшьләр илкүләм чемпионатның финал өлешенә эләгү хокукы өчен көрәшә, шул рәвешле алар «тормышка юллама» алырга омтыла. Ә Татарстандагы сәнәгать предприятиеләре эшчеләре WorldSkills* стандартларындагы һөнәри ярышларда алган тәҗрибәне чынбарлыкта сынап карый.

Автор:
Олеся Бондаревская

«АНСАТ» ВИРТУАЛЬ КҮКНЕ ИҢЛИ

Автоматлаштырылган проектлау программасының сызым өсталендә әйләнеп йөргән 3D модельдә без «Ансат» вертолётын танып алабыз. Монда, Казан вертолёт заводының тәҗрибә-конструкторлык бюросында, инженерлар инде гамәлгә кергән модельләрнең башка модификацияләрен булдыра һәм гомумән яңа очкычлар ясый.

– Мин хәзер автоматлаштырылган проектлау системасында эшлим, әлеге программа тулы электрон макет һәм аның аерым бер өлешләре белән бәйле мәсьәләләрне хәл итәргә мөмкинлек бирә. Әйтик, ныклыкка һәм термодинамикага бәйле хисаплаулар башкарырга, сынауларны модельләштереп карарга була. Системаның мөмкинлекләре шулкадәр киң: теләсә нинди катлаулыктагы яки зурлыктагы әйбернең моделен ясый алабыз, – дип сөйли тәҗрибә-конструкторлык бюросының инженер-конструкторы Георгий Пискунов.

Нигездә шундый ук биремнәр – модель проектлау, параметрлар һәм йөкләнешләрне хисаплау, документлар әзерләү, прототип ясау кебек биремнәрне Георгий «Россия вертолётлары» холдингының 2016 елның язында Улан-Удэ каласында узган эчке чемпионатында да үтәгән, ләкин анда таләпчәнлек тагын да югарырак булган, тизрәк тә эшләргә туры килгән. Георгий ул бәйгедә холдингның башка ширкәтләреннән килгән алты кешене узып, үз һөнәре – «CAD (computer-aided design – автоматлаштырылган проектлау системасы) инженерлык графикасы» буенча беренче урын ала. «Ростех» корпорациясенең эчке чемпионатында Казан егете 19 катнашучы арасында алтынчы була. Ә аның теләге – беренче булу һәм сәнәгатьнең югары технологияле тармакларындагы эшче һөнәрләрнең WorldSkills (WorldSkills Hi-Tech – «Ворлдскиллс Хайтек») методикасы буенча илкүләм чемпионатына юллама алу. Әлеге чемпионат һәр елны Екатеринбург шәһәрендә уза, ул ярышка Россиянең 30 дан артык сәнәгать предприятиесеннән командалар җыела. Анда бер генә тапкыр җиңеп була.

– WorldSkills стандартлары буенча эшләү көндәлек хезмәтегезгә охшаган икән, болай ярышып йөрүнең әһәмияте нәрсәдә соң?

– Беренчедән, ярыш мәйданчыгында булу – үзе үк искиткеч тойгы. Монда вакыт ягы чикләнгән, һәм син каушап калмаска, оешканлык кебек сыйфатыңны һәрвакыт эшкә җигә белергә тиеш, чөнки һәр адымың – балларыңны арттыра яки киметә торган бер шарт ул, – дип сөйли Георгий. – Икенчедән, чемпионат алдыннан җитди әзерлек узабыз. Нәтиҗәдә, кайбер хәрәкәтләр шулкадәр автомат рәвештә башкарыла, ә бу исә гадәти хезмәтебезгә дә булыша. Өченчедән, WorldSkills бәйгеләрендә эш процессын камилләштерә торган фикер-тәкъдимнәр хуплана. Шуңа күрә син әнә шундый юнәлештә уйларга өйрәнергә тиеш. Мондый күнекмә тиз генә барлыкка килми, тик шулай да конструктор кеше өчен бик файдалы күнекмә ул.

WORLDSKILLS ТОРМЫШКА ДӘРТ ӨСТИ

– Гомумән, WorldSkills стандартлары буенча бәйгеләр безнең өчен нинди-дер яңалык әле. Предприятиеләрдә инде 50 елдан артык һөнәри осталык конкурслары узып килде, ләкин еллар үтү белән без үз заводларыбызда гына бикләнеп ятмаска кирәклеген аңладык, – дип фикерләре белән уртаклаша Казан вертолёт заводының әзерлек-штамповка ясау буенча баш технолог урынбасары, «Тормыш циклы белән идарә итү» ярышы белгече Александр Евдокимов. – Без бик тыйнак кына башладык: 2014 елда узган WorldSkills Hi-Tech бәйгесендә бездән нибары бер кеше һәм бер белгеч катнашты. Ә инде 2016 елда үзебезне өч ярышта сынадык – ике корпоратив чемпионатта һәм югарыда телгә алынган «Хайтек» чемпионатында. Нәтиҗәдә берничә беренче урын һәм төрле призлы урыннар яуладык. 2015 елда заводтагы WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык конкурсында өч төрле ярышта үзләрен 23 хезмәткәр сынап караса, 2016 елда инде ярыш төрләре саны 10 га җитте, аларда 120 кеше катнашты.

– Ярыш мәйданчыгының ничек кайнап торганын күрсәгез икән! Монда шундый киеренкелек хөкем сөрә, бар нәрсә хәрәкәттә. Һәркем җиңәргә омтыла, һәркем хаталары

Фото: Ната Смирнова, Юлия Плеханова (lnprof.ru)

* Ворлдскиллс

өчен борчыла. Кемнеңдер сабырлыгы да төкәнә. Кайчак перчаткаларын, эш коралларын да болгап ташлыйлар... – дип сөйли оста.

Чемпионатта катнашучылар саны елдан-ел күбәя, бу исә сәнәгать өчен эшче кадрлар әзерләүгә нигез булдыру мөмкинлеген бирә. Чемпионатның бүләк фонды да шактый саллы, ул да артуга бара. Иң күп балл җыйган җиңүче төп приз – миллион сумга ия булачак. Ярышларда катнашкан башка һөнәр осталарына иганәчеләрдән кыйммәтле бүләкләр тапшырыла.

– Бу чемпионатларга предприятиеләр үзләренең иң яхшы хезмәткәрләрен – иң шәп техника күрсәткән, һөнәри үсешнең төп юнәлешләрен билгели алган осталарны алып киләләр. Башкалар шулардан өйрәнеп, монда алган тәҗрибәне үз предприятиеләрендә куллана. Шул рәвешле без базар таләпләрен күздә тотып, технологияләр белән бергә алга барырга тырышабыз. Иң зур плюс – бу һөнәр осталарының яшь булуында. Киләчәктә аларга яхшы карьера ясау мөмкинлеге бар, бу яшьләр үз предприятиеләренең үсешенә бик зур өлеш кертә ала, – дип саный Александр Евдокимов. – Өметле киләчәк – бик күпләр өчен көчле стимул ул, аеруча төрле цехларда эшләүчеләр өчен. Көн дә бер үк төрле хезмәт үзеңне камилләштерүгә, үзүсешкә алла ни теләк уятмыйдыр, ә менә ярышта, хәтта халыкара дәрәҗәдәге бәйгеләрдә чыгыш ясау мөмкинлеге, синең осталыгыңның бик югары бәяләнәчәген аңлау тойгысы боларга юл ача.

Александр Евдокимов фикеренчә, әле күп кенә һөнәри ярыш төрләрендә безгә чит ил осталарыннан үрнәк алыр нәрсәләр бар. Ләкин шул ук вакытта ул Казан вертолёт заводы кебек предприятиеләргә мондый чемпионатларда җиңүнең үзмаксат булмавын да искәртә.

– Әгәр чемпион әзерләү максатын куябыз икән, без шул юнәлештә махсус әзерлек алып барачакбыз, һәм бу хезмәткәр җиңүче булачак. Тик безнең егетләребез ярышларга андый ният белән бармый. Дөрес, җиңү теләге була, әлбәттә, ник дигәндә, җиңү престижны арттыра, хезмәткәрнең үзенең дә, аның оешмасының да абруен күтәрә. Ләкин төп максат – кызыксыну тудыру, үз эшеңә дәрт уяту, иң алдынгылар рәтенә әләгү омтылышы булдыру. Чөнки үз эше белән чын-чынлап мавыккан кешеләр генә фәнни-техник прогрессны алга этәрә, – моңа белгечнең шиге юк.

Һәм, әлбәттә, биремнәрне бергәләп башкару команда хисе барлыкка килүгә булыша. Ә «Тормыш циклы белән идарә итү» бәйгесе, бу яктан караганда, «Ростех» һәм «Россия вертолётлары»ның корпоратив чемпионатларының иң төп үзенчәлегедер.

ЯҢАЛЫККА ЮЛ ЯРУ ӨЧЕН – ӨЧ КӨН

Күз алдына китереп карагыз әле: төрле яшьтәге, төрле тәҗрибәле, бәлки, гомерләрендә тәүге тапкыр очрашкан бер төркем белгечкә ниндидер яңа җиһаз яки тулы бер комплексның эшкә сәләтле концептын уйлап табарга һәм теге яки бу дәрәҗәдә тормышка ашырырга кирәк. Бу, әйтик, электр тапшыру челтәре яки автоматлаштырылган гыйльми лаборатория була ала. Ләкин шундый зур эш өчен аларның нибары өч көн вакыты бар.

– «Тормыш циклы белән идарә итү» төрендәге ярышлар, үзенә күрә, инженерлар командасын чынбарлык шартларында эшләтеп карау тренажёры ул. Гадәттә, предприятиедә яңа проект алдан билгеләнгән план нигезендә этаплап бара, – дип сөйли бу төр ярыш буенча илкүләм эксперт булып торган Илья Гаранкин. – Без исә предприятиенең төрле тармагындагы 7–9 кешедән коллаборация – максатчан хезмәттәшлек булдырырга тәкъдим итәбез. Бу очракта берничә белгеч – конструктордан башлап дизайнерга һәм маркетологка кадәр – бергә эш йөртә. Аларга өч көн эчендә, мәсәлән, бер яхшыртылган деталь эшләп чыгару йөкләнә. Команда эшне сызымнан һәм техник документациядән башлап, әзер прототип дәрәҗәсенә җиткерергә тиеш, бу прототип компьютер ярдәмендә идарә ителә торган станокта сызымнар нигезендә ясала яки, команданың вакыты калса, 3D-принтерда чыгарыла. Инженерлык проекты өчен техник бирем эшләнмәнең тулы «тормыш циклы» таләп иткән тәртиптә башкарыла: базардагы ихтыяҗ һәм тәкъдимнәр өйрәнү, стратегияне билгеләү, проектны әзерләү, продукт проектын булдыру, продукты җитештерү.

Бу һөнәри ярыш төренең төп максаты – яңа продукт тудыруга мөнәсәбәтне тамырдан үзгәртү. Илья Гаранкин әйтүенчә, тәкъдим ителгән эш методикасы теге яки бу яңа продуктны ясап, аны базарга чыгару вакытын сизелерлек кыскартырга мөмкинлек бирә. Мондый эш берничә ай, хәтта берничә көн эчендә башкарыла ала. Шул рәвешле әлеге методика Россия предприятиеләренең көндәшлек сәләте артуына булышлык итә, ә моның әһәмияте – бәхәссез, чөнки бу предприятиеләр алдында эчке һәм тышкы базарларны яулау кебек шактый зур бурычлар тора. Якын киләчәктә әлеге һөнәри ярыш төре сәнәгатьнең югары технологияле тармакларындагы эшче һөнәрләрнең WorldSkills (WorldSkills Hi-Tech) методикасы буенча илкүләм чемпионатындагы төп компетенцияләр исемлегенә кертеләчәк. Бу төрнең практик потенциалы шик уятмый. Әйтик, 2016 елгы WorldSkills Hi-Tech чемпионатында әлеге ярыш кысаларындагы биремнәрнең берсе «Ансат» вертолёты өчен кайбер детальләрне камилләштерү, яңарту белән бәйле иде.

РОССИЯДӘГЕ WORLDSKILLS СТАНДАРТЛАРЫ БУЕНЧА ЯРЫШЛАР ТУРЫНДА

«Яшь профессионаллар» (WorldSkills Russia) төбәк чемпионатлары бөтен ил күләмендә WorldSkills стандартлары буенча көллият һәм техникумнарда белем алучы студентларны һөнәри осталыкта сынау форматында уза. Катнашучыларның яше – 16 дан алып 22 гә кадәр. «Яшь профессионаллар» (WorldSkills Russia) Милли чемпионатының финалында катнашу хокукына сайлап алу турыннан узучылар ия була, үз чиратында, шул нәтиҗәләргә таянып, милли җыелманың составы да формалаша.

JuniorSkills чемпионаты системасы – WorldSkills методикасы буенча 10-17 яшьтәге укучыларның һөнәри осталыгын сынауны күздә тота: «Яшь профессионаллар» (WorldSkills Russia) чемпионатлары системасы кысаларындагы җирле, төбәк, корпоратив, округ һәм милли бәйгеләр дигән сүз бу.

«Яшь профессионаллар» (WorldSkills Russia) корпоратив чемпионаты стандартлары – бу 18 яшьтән алып 28 яшькә кадәрге (29 яшьтән соң – конкурстан тыш) гамәлдәге производствода эшләгән яшь эшчеләр һәм уку йортларында белем алучылар арасындагы һөнәри осталык буенча бәйгеләр. Чемпионатның оештыручы корпорацияләренең бүлендек оешмалары, ведомстводан тыш мәгариф учреждениеләрендә укучылар (конкурстан тыш), шулай ук «Яшь профессионаллар» (Ворлдскиллс Россия) Союзы экспертлары белән бергә эшләнгән компетенцияләре уртак, йә булмаса бер тармакка караган/презентацион булган читтәге оешмалар (тәэминатчылар, шул ук яисә чиктәш булган булган сәнәгать тармаклары) дип исәпләнүче предприятиеләр арасында уздырыла.

WorldSkills (WorldSkills Hi-Tech) методикасы буенча уртак эшче һөнәрләр һәм югары технологиягә ия сәнәгать тармаклары Милли чемпионаты югары технологияле сәнәгать өлкәсенә караган предприятиеләр һәм гамәлдәге производстволар кысаларында белем алучы уку йортлары студентларының, корпоратив чемпионатларда финалга чыгучыларның катнашуын күздә тота. Катнашучыларның яше – 18 дән 28 гә кадәр. Бер предприятие бары тик бер катнашучыны гына тәкъдим итә ала, шулай ук – һәр компетенциядә бердән дә ким булмаган белгечне.

PRESSA.RU

«УҢАЙЛЫЛЫК ЗОНАСЫННАН» КИТИК!

Автор:
Катерина Котова

– Әйдәгез, бераз тәнне язып алыйк әле! – дип мөрәҗәгать итә алып баручы аудиториягә. – Һәркайсында бертигез катнашучы булган өч тигез рәткә тезелегез. Ике минут вакыт сезгә! Бу армия плацы түгел: КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбендә... җитәкчеләр өчен тренинг башлана.

БЕР АДЫМ АЛГА

Вакыт бара, беренче карашка бик гади тоелган бурыч исә һаман үтәлми: кемнәрдер тезелергә маташканда, кайберәүләр аптырап басып тора... Шул арада инде яңа команда яңгырый: «Күршедәге кеше белән аяк чалыштырып, барыгыз да бер үк вакытта бер адым алга атлагыз!» Монда ничек тә егылмаска инде! Ура, авырлык белән булса да, килеп чыга бит, барысы да кире үз урынына килеп утыра. Кайберәүләр һаман аптырашта...

Иң беренче бирем үк – бераз селкенеп алу да, нәтиҗәгә юнәлтелгән команда эшенең күрсәтмә мисалы да. Аның бурычы – аптыраш калдыру, чыгырдан чыгару: катнашучылар үзләре, мәгълүм калыплардан баш тартып, максатка ирешүнең оптималь алгоритмын табарга һәм шуны тормышка ашырырга тиеш.

ШАБЛОННАР КИРӘКМИ

«Нәтиҗәле идарәче» программасы тәҗрибәле җитәкчеләргә тәгаенләнгән. Стратегик фикерләү, кабул ителгән карарлар өчен җаваплылыкны үз өсләренә алу, кул астындагыларга дөрес максатлар куя белү, эшнең нәтиҗәсен күрү һәм идарә стилен вакытында үзгәртү – аларның уңышы менә шулардан җыела. Тыңлаучыларның әлеге категориясенә болар барысы да таныш булырга тиеш кебек – алар җитәкче булуның хәлләреннән килүен күптән раслаган бит инде. Алайса, нигә тагын укырга кирәк соң?

– Тәҗрибә күрсәткәнчә, җитәкче эшендә көн саен әллә никадәр көтелмәгән хәл килеп чыга, яңа сораулар туа, аларга кыска вакыт эчендә һәм чикләнгән ресурслардан торган шартларында җавап бирергә кирәк, – дип сөйли КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе директоры Игорь Привалов. – Безнең «Нәтиҗәле идарәче» программасы җитәкчеләрне аеруча катлаулы бурычларны хәл итәргә өйрәтә. Күп проблемаларга башка яссылыктан карарга мөмкинлек бирә, зирәклекне арттыра – кеше клише-шаблоннар буенча фикерләми башлый.

Әлеге 36 сәгатьлек программаның төп өлешен нон-стоп тренинг тәшкил итә. Кейслар – махсус модельләштерелгән хәлләр – катнашучыны проблематикага тулысынча җәлеп итү мөмкинлеген бирә. Алар чыннан да «чиновниклар тормышыннан» алынган.

– Әлбәттә, аларны әзерләгәндә без дөньядагы тәҗрибәне дә файдаландык, чөнки, күренеш буларак, кейслар үзләре безгә Көнбатыштан килде, – дип аңлата мәктәп директорының урынбасары һәм әлеге юнәлешнең кураторы Наталья Аксенова. – Шул ук вакытта без аеруча уңышлы чит ил программаларын тулысынча күчереп кенә алмадык, бәлки үзебез яңаларны төзедек, алар безнең Татарстан дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләре эше спецификасын күздә тотып һәм аларга максималь файдалы итеп уйланылган.

«Нәтиҗәле идарәче» – кейс методы нигезендә эшләнгән дүрт пилот программаның берсе. Калган өчесе – аларны велкам-тренинг дип атыйлар – үзләренең һөнәри үсешен тизләтергә теләүчеләргә исәпләнгән: «Эшли генә башлаучы муниципаль хезмәткәр», «Эшли генә башлаучы дәүләт хезмәткәре» һәм «Эшли генә башлаучы җитәкче». Алар барысы да узган ел гына гамәлгә кертелгән, әмма инде шактый мактау сүзләренә лаек булган.

– Һәр программадан соң без һәрвакыт аның нәтиҗәлелеген тикшерәбез, – ди Наталья Аксенова. – Моны үзебез түгел, башка оешма башкара, чөнки барысы да гадел булсын өчен тырышабыз. Хисаплар Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына җибәрелә. Тыңлаучыларыбызның канәгатьлек дәрәҗәсе 98 процентка җитә! Кешеләргә интерактив ошый. Шулай да без классик лекцияләрдән тулысынча баш тарту дөрес булмас, дип уйладык. Кайвакыт җитәкчеләргә дә махсус белем җитми – вакыт бит бер урында гына тормый! Безнең бурыч – әлеге белемне бирү. Моңа тагын стресс белән идарә итү, нәтиҗәле коммуникацияләр, тайм-менеджмент һәм ораторлык осталыгы буенча йомгаклау тренингларын да өстәсәгез – искиткеч белем бирү модуле килеп чыга!

СУДА БАТУЧЫНЫ КОТКАРУ – ИДАРӘЧЕЛӘР ЭШЕ

Менә бу «сакаллы» мәзәкне хәтерлисезме икән? Берәү алтын балык тоткан. Балык әйтә икән: «Кире суга җибәр мине, ә мин синең теләгеңне үтәрмен». Ир-ат уйлап торган-торган да: «Советлар Союзы Герое буласым килә!» – дигән. Бах! Икенче мизгелдә ул инде яна торган самолет кабинасында утыра икән, дошман исә ут яудыра. «Үлгәннән соңмыни?» – дип уйларга гына өлгергән ди... Нинди нәтиҗәгә киләбез? Әйе, бурычларны төгәл билгеләргә, максатларны дөрес куярга кирәк, шул вакытта гына эшнең нәтиҗәсе яхшы булачак. КФУ Мәктәбендә сезне нәкъ шуңа өйрәтәчәкләр дә.

– Гадәттә без цейтнот халәтендә эшлибез һәм кеше ресурсларына кытлык кичерәбез, – дип зарлана тренингта катнашучыларның берсе. – Бу очракта ничек нәтиҗәле булырга?

Җавап шунда ук табыла – үзеңә үсәргә һәм үзеңә буйсынучыларның даими үсешен тәэмин итәргә. Бары тик шул очракта гына җаваплылыкны бүлешергә һәм стратегик бурычларны хәл итү өчен вакыт табарга мөмкин булачак. Кейс программада катнашучыларны үзләренең «уңайлылык зонасы» чикләреннән чыгарга мәҗбүр итә. Һәм алар, тәҗрибәле җитәкче буларак, аңлый башлый: аларга үсәргә дә үсәргә әле.

– Хәл итәр өчен көнкемәләребез һәм компетенциябез җитешмәгән проблема белән очрашканда, без «рәхәтлек зонасыннан» китәбез, – дип аңлата бу курсның тренеры Мансур Фәткуллин. – Әмма нәкъ менә шул безгә тәҗрибә тупларга мөмкинлек бирә дә инде. Димәк, без үз кул астыбызда эшләүчеләр алдына куйган максатлар да шактый авыр булырга тиеш. Бу очракта максатны билгеләү... үстерү инструментына әйләнә. Әмма бу очракта, әлбәттә, хезмәткәрләрнең компетенция дәрәҗәсенә игътибар итәргә кирәк.

ЧИНОВНИК ТОРМЫШЫННАН

«Без хәзер кайсыбызның 14нче кабинетка кереп урнашуын хәл итәргә тиеш. Дөресен әйткәндә, мин аның үземнеке булуын телим!» – ди озын буйлы ир-ат. Сөйләшүләр өстәле тирәсенә уйлап чыгарылган бүлек җитәкчеләре җыелган. Һәркайсының төгәл таләпләр күрсәтелгән инструкциясе бар: матбугат үзәгенә эш өчен бар кирәк, архив тагын бер бинага мохтаҗ, пиарчыларга исә презентацияләр урыны булу шарт... Кемнең кайсы кабинетка керәсен хәл итү шактый катлаулы эш булып чыга. Баштарак һәр җитәкче, үз бурычларын гына хәл итү өчен, юрганны үзенә тарта. Уйлап чыгарылган вазгыять көтмәгәндә тагын бер проблеманы ачыклый.

– Үзебезнекен генә тукып, үз амбицияләребезне генә канәгатьләндерергә тырышканда, процессның тулаем нәтиҗәлелегенә зыян килә, – дип аңлата Мансур Фәткуллин. – Чынбарлыкта да шулай бит. Үзебезнең барлык хезмәткәрләребезнең мәнфәгатьләрен, үзенчәлекләрен һәм компетенция дәрәҗәсен исәпкә алганда, без күпкә яхшырак нәтиҗәләргә ирешә алачакбыз.

Мәгълүм булганча, нәтиҗәле эшләүче команда туплау – ул әле уңышның яртысы гына. Аның белән нәтиҗәле идарә итә белү дә мөһим. Һәм әгәр бер җитәкче максатларга катгый контроль һәм дисциплина ярдәмендә авторитар ысул белән ирешә икән, ә икенчесе демократия яклы булса, җитәкчеләкнең бу ике капма-каршы стилен бер-берсенә яраклаштыру һәм берләштерү буенча Мәктәптә конкрет инструментлар бирәләр. Курс тәмамланган вакытка катнашучылар үзләренә кайчан «диктатор», кайчан «демократ» булу нәтиҗәлерәк икәнне бик җиңел билгеләргә өйрәнә.

Тренинг башланып бер генә сәгать үткән әле, ә төркемнең синергиясе инде ташый. Четерекле сорауларга ул инде үзе җавап таба һәм карарлар чыгара. Аларның кайберләре күз алдында ук булган икән бит, тик аларны элегрәк беркем дә формалаштырмаган гына. Эффектка ирешелә – «шаблоннар» юкка чыга.

– Баштарак бераз уңайсыз булды, тик ул миңа үземне кулга алырга булышты! – дип сөйли ТР Дәүләт Советының финанс бүлеге мөдире Гөлгенә Таликова. – Тормышта безне мәгълүмат диңгезе урап алган, күп нәрсә хәтердән чыга, нәрсәдер әһәмиятсез булып тоела. Минем өчен бу тренинг – төп хакыйкатьләрне искә төшерү, дөрес акцентлар кую, коллегаларым белән нәтиҗәле аралашу һәм тәҗрибә уртаклашу. Һәм тренерыбызга түземлеге өчен рәхмәт әйтергә кирәк!

– Еш кына без нииндидер бер тар юнәлештә эшлибез, – дип сөйли ТР Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының оборона комплексы бүлеге җитәкчесе урынбасары Фаил Фәттахов. – Менә син шунда озак вакыт буе көн саен кайнаганда, гәрчә синең берничә югары белемең булса һәм барысын да беләсең кебек тоелса да, күп кенә нәрсәләргә караш тоныклана. Тормыш бер урында гына тормый бит, һәм биредә, квалификация күтәрү курсларында, без кинәт шуны аңлыйбыз: эшне бит башкача да оештырып була икән! Идарә итүнең нәтиҗәле ысул һәм алымнары, чынбарлыктагы бурычларны хәл итүгә яңача якын килү, карарлар кабул итүнең яңа алгоритмнары – боларның барысын да без практикада куллана алачакбыз. Тренинглар безне ача, коллегаларыбыз белән иң актуаль мәсьәләләрне тикшерү мөмкинлеген бирә. Бу кыйммәтле тәҗрибә, мин аны үз хезмәткәрләремә тапшыра алуыма бик шат булачакмын. Т

PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1 февральдән 31 мартка кадәр 2017 елның II яртыеллыгына
«Татарстан» журналына алдан язылу игълан ителә

Индекс:
П 2378 **рус телендә**
864 сум 24 тиен

Индекс:
П 2381 **татар телендә**
864 сум 24 тиен

Реклама 16+

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

«Татарстан» фотобанкы **НИНДИ** фотоларга баеды

Кадыйр Сибгатуллин беренче шигырен **КЕМГӘ** багышлаган

Татарстанның **КАЙСЫ** шәһәрендә солдат мәзәкләре туган

PRESSA.RU



Казан янында Идел елгасы аша автомобиль күпере төзелеше. 1988 ел.

«ТАТАРСТАН»НЫҢ АЛТЫН ЗАПАСЫ

Килешәсездер, йөз яшь гадәти генә итеп билгеләп үтелә торган бәйрәм түгел. Бигрәк тә сүз яраткан республикабыз турында барганда. Әйе-әйе, яшь һәм матур күренгән Татарстанга тиздән, төгәл өч елдан, нәкъ бер гасыр була.

РФ ЭЭМ Алабугадагы махсус милиция мәктәбе. 1985 ел.

Исеме буенча гына түгел, рухы белән дә республикабызның адашы булган журналыбыз юбилейга ФОТОБАНК әзерли. Аның сейфларында бәһасе булмаган хәзинәләр ята – олы тарихның әһәмиятле мизгелләре һәм шул тарихны тудыручы шәхесләр чагылыш тапкан аларда. Республика үзе һәм ул ирешкән уңыш-казанышлар һәм, гомумән, гап-гади тормышның бәхетле мизгелләре теркәлгән елъязма турында бара сүз.

Безнен ФОТОБАНКны озак еллар Казан университетының журналистика факультетында фоторәсем эшен укыткан Җәвит Акчурин ачып җибәргән иде. Ул безнең банкка беренчеләрдән булып үзенең саллы өлешен кертте.

Әлеге изге эшне чираттагы фотограф – Рамил Гали дәвам итә. Ирләр көне искә алынган февраль санында аның узган гасырның 90нчы елларының урыны-урыны белән ир-атлар, урыны белән солдат, урыны белән спорт һәм дә көндәлек темаларга багышланган фотоларына күз салыгыз!

Казан. Солдатларның төшке ашы. 1990 нчы еллар.

Казан. Армиягә чакырылучылар. 1990 нчы еллар.

Кем бозлы су эчендә басып торган килеш фотога төшерә?

Казан урамнарында беренче кораллы патруль. 1990 нчы еллар.

PRESSA.RU



Костя Дзю –
СССР чемпионы. Казан.

Казан тимер
юл вокзалында чыккан
янгынны сүндерү.
1990 нчы еллар.

PRESSA.RU

Фото: Ната Смирнова

КАДЫЙР СИБГАТУЛЛИНГА – КЕЧЕ УКМАСКА

КЕЧЕ ВАТАН ПАТРИОТЛАРЫ

15 февральдә шагыйрь Кадыйр Сибгатуллинга 75 яшь тулган булыр иде. Аның кече ватаны – Балыклы Чүкәй авылы, балачагы Кече Укмаста үткән. Нәкъ менә шунда – сабый чакта тәпи эзләре калган туфракта җирләнгән дә ул. Әйе, гомере буе җирсеп, җырларында данлап яшәгән туфракта.

Автор:
Алсу Троицкая

«ҖИР ҮЗЕНӘ ТАРТА...»

60нчы елларда совет шигъриятендә, шулай ук Татарстан поэзиясендә дә, өр-яңа буын пәйда була. Болар үзләренә кадәрге буын шагыйрьләренә охшамаган: башкача фикерлиләр, тел-стиль белән экспериментлар ясап карыйлар һәм дөньяга караш-мөнәсәбәтләре дә күпмедер дәрәҗәдә бәхәсле тоела ул чакта. «60нчы елгылар» арасында талантлы яшь шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин да була. Без аны Хәсән Туфанның үзеннән фатиха алган сүз остасы икәнлеген беләбез.

Кадыйр Сибгатуллин үзе дә остазы дип Хәсән Туфанны саный. Менә, яшь шагыйрьгә олпат әдипнең язган бер хатыннан өзек: «Кадерле Кадыйр! «Беренче карлыгачлар»дагы шигырьләреңне күздән кичергәннән соң, «...Шатланып мин кысам кулыңны. Иңеңә канатлар үссеннәр» диясем килә сиңа. Шигырьдә үз телең, үзеңә хас үзенчәлегең бар. Шуңа күрә үзсүзле кеше булырга теләвең табигый хәл ул. Туачак җырларыңа «Тузан ерып» каршы бар, әйдә, энекәш!..»

Шагыйрьләрнең тормышын туу белән үлем чикләренә генә

сыйдырып булмый. «1942–1994» – гәрчә шушы еллар аралыгында яшәгән һәм иҗат иткән булса да язмабызның каһарманы. Чөнки шагыйрьнең сүзе ул үзе фани дөньяны калдырып киткәннән соң да яши, кешелекне сискәндерүен, дулкынландыруын дәвам итә. Гади генә булуына карамастан, тетрәндерә:

Ак мендәрдә түгел, әни мине
Тапкан, камылларда тәгәрәп.
Шуңа күрә җир үзенә тарта –
Буйларыма кадәр тәбәнәк.

Кадыйр Сибгатуллин иҗат гомеренең күп өлешен Балык Бистәсе районында уздыра. «Октябрь юлы» (хәзер ул «Авыл офыклары» дип атала. – Ред.) исемле район газетасында күп еллар дәвамында журналист булып эшли. «Кече ватан патриотлары» Кадыйр Сибгатуллинның 75 яшьлек юбилее алдыннан шагыйрьнең туган ягына юл тотты. Каһарманыбызның туганнары, дуслары, коллегалары һәм, әлбәттә инде, якташлары белән очрашып сөйләшер өчен.

«ТУГАНЫМА ҺӘМ ДУСТЫМА»

Кадыйр Сибгатуллинның Илдар Әхмәтгалиевкә бүләк иткән китапларының барысына да шулай дип язылган.

– Хәдичә апам Кадыйр абыйның туганында – Вахитта кияүдә иде. Әнием Гайнелхәят Хәлиловага – үзенең беренче укытучысына – Кадыйр абый һәрвакыт китапларын «яраткан укытучыма» дип язып бүләк итә иде. Ул минем тормышымда һәрчак булды – туганнан башлап. Ә инде исәя төшкәч, мин ул мөдир булып эшләгән авылыбыз клубына еш кереп йөри башладым. Шахмат уйнарга. Кадыйр абый өйрәтте мине ул уенга. Әле тагын укырга китаплар да бирә иде, ул бит, мөдирлек белән беррәттән, китапханәче дә иде.

8нче сыйныфны тәмамлагач, мин Арчага укырга киттем. Армия хезмәтен үтәп, Кече Укмаска яңадан әйләнеп кайткач, дуслыгыбыз дәвам итте. Соңыннан, нәкъ аның шикелле, Балык Бистәсенә күчендем һәм кабат аңарга китап укырга йөри башладым. Бу юлы инде китапханәгә түгел, өенә. Хәер, аның өендәге китапханә дә клубныкыннан ким түгел иде.

Туры сүзле, намуслы кешеләргә яшәү беркайчан да җиңел булмаган, ә 70нче елларда – бигрәк

PRESSA.RU



тә. Кадыйр абыйның район газетасында эшләгән чагындагы бер очракка тукталып узасым килә. Шулай бервакыт аны халык контроле комитеты рәисе чакыртып ала да үзенә доклад эшләп бирүен сорый. Текстны кычкырып әйтеп тора, Кадыйр абый язып бара. Кинәт болай дип әйтеп куймасынмы рәис дигәнебез: «Менә бу урында җәяләр эченә «алкышлар» дип язып куй». Шуннан яздыруын дәвам итә, ара-тирә әйтеп куя: «көчле алкышлар», «залдан «дөрес!» дип кычкырган хуплау тавышы». Бу хәл өч тапкыр кабатланганнан соң, Кадыйр абыйның түземе төкәнә: «Бу генераль секретарь тотасы речь түгел ләбаса!» – ди ул. Табигый ки, доклад бу ахмаклыкларны кертмичә генә язылa. Кадыйр абый андый очракларда җүләр белән бәхәсләшүнең мәгънәсе юк, дияргә ярата иде. Әмма кайбер мөһим очракларда үз карашыннан, фикереннән тайпылмады ул, нык тора иде.

Тагын бер очрак: кайсыдыр республика басмасының редакторы әйтә икән Кадыйр абыйга: «Син шигырьләрне теләсә кайда – хет бәдрәфтә яз». Кадыйр абыйның моңа җавабы кискен булган: «Ә син аларның сасысыннан курыкмыйсыңмы соң?» Шуннан соң Кадыйр абыйның иҗатына ул басмада юл ябылган.

ШАГЫЙРЬНЕҢ ҖАНЛЫ ПОЧМАГЫ

Кадыйр Сибгатуллин музее өчен Балык Бистәсенең 1нче номерлы гимназиясендә экспонатларны күптәннән җыйганнар инде, ә музейны нибары 2001 елда гына ача алганнар. Музей җитәкчесе, гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Асия Мифтахова болай дип сөйли:

– Кечкенә генә булса да, җанлы ул, бирегә даими балалар килеп йөри. Алар Кадыйр Сибгатуллинның иҗатын беләләр һәм яраталар. Ә бит бу – иң әһәмиятлесе. Тобольскиның якташлык җәмгыяте дә безнең музей белән тыгыз элемтәдә тора. Кадыйр Сибгатуллинның иҗаты халыкка якын, ул һәр кешенең йөрәгенә үтеп керә, ул һәр кешегә аңлаешлы.

ШУЛАЙ БЕРВАКЫТ...

– АНДЫЙ КЕШЕЛӘР ОЗАК ЯШИ АЛМЫЙ

Рәмзил Гыйлемханов, дусты һәм коллегасы:

– **ШУЛАЙ БЕРВАКЫТ** Кадыйр Балык Бистәсе районы Биектау авылына командировкага килеп төште. Мин мәктәптә лаборант булып эшли идем. Кичен клубта авыл халкы белән очрашты. Мин аны кунарга үзебезгә чакырдым. Өйдә әни өстәл хәстәрләде. Кич буе сугыш чоры михнәтләре һәм сугыштан соңгы елларның матавыклары турында сөйләшеп утырдык. Командировка атна буе дәвам итте, һәм алдагы кичләр барысы да бер кичтәй узды. Җанга рәхәт әңгәмәләр белән тулы кичәләр. Командировкаларга чыкканда, ул бер генә көнгә түгел, озаккарак килеп, материалларны җентекләп әзерли иде. Мәсьәләнең төбенә төшмичә тынычланмый. Бәлки, шуңа да язмалары кызыклы килеп чыга иде Кадыйр абыйның.

Балык Бистәсенә йомыш белән килеп чыгам икән, мин дә туп-туры аның өенә, йә редакциягә юл тотам. 1972 елның 8 маенда ул мине армиягә озатты. Хат алышып тордык, кайтуымның беренче көнендә үк редакциядә эш тәкъдим итте: "Теләмәсәң, мәҗбүр итәрбез, булдыра алмасаң, өйрәтербез". Өйрәтте дә. Татарстан һәм Россия Журналистлар союзы әгъзасы булуым – шуның нәтиҗәсе. Ул мине энекәшедәй якын күрде.

Ике ел буе редакциянең хатлар бүлегендә бер кабинетта утырып эшләдек. Чын ир-егет иде Кадыйр – үзен дә яклый белә, башкалар өчен дә утка керергә әзер. Шундый үткен итеп яза иде мәкаләләрен, зыяны булмаса ярый инде, дип пошынабыз. Озакламый миңа редакциядән китәргә туры килде. Әмма Кадыйр белән дуслыгыбыз туктамады, гомеренең соңгы көннәренә кадәр аралашып яшәдек. Ул чынлап та дус була белә иде! Кешеләрнең кайгыларын, борчуларын да, шатлыкларын да уртаклаша. Андый кешеләр озак яши алмый.

– БЕРЕНЧЕ ШИГЫРЕ МИҢА БАГЫШЛАНГАН ИДЕ

Әнисә Фазлыева, туганнан туган сеңлесе:

– **ШУЛАЙ БЕРВАКЫТ** Бабам фронтта һәлак булганда, әбием Кадыйр белән йөкле булып кала. Шулай итеп, Кадыйр якты дөньяга әтисез килеш аваз сала. Әтисезлек ачысы аның шигырьләрендә ярылып ята. Ул елларда авыл тулы тол хатын иде. Егетләрен фронтка озатып, кайтуларын еллар буе көтеп яшәгән кызлар да – бихисап. Инде шагыйрь булгач, Кадыйр аларны шигъриятендә сурәтләде.

Әти-әниләр колхоз эшеннән кайтып керми, безгә хуҗалыкны алып бару йөкләнгән. Җиләккә йөрдек, кузак урладык, кәҗәгә печән чаптык. Кадыйр абый мине үзсүзле дип тиргәде, хәер, үзенең холык-фигыле дә ай-һай иде! Ул һәрчак сүзендә тора белде, бала-чагага кадәр нидер вәгъдә итсә дә, аны үтәми калмый иде. Сүзен кистереп әйтә, баскан җиреңнән утырта торган итеп.

10нчыны тәмамлагач, Казанга укырга чыгып китте. Электрик һөнәрен үзләштерде. Армия хезмәтеннән соң, язу эшенә һәвәслеге үзенекен итте – район редакциясенә кайтып урнашты.

Иң беренче шигырен миңа багышлап язды Кадыйр абый, исеме дә «Сеңлемә» иде аның. Кызганыч, без аны эзләп-эзләп тә таба алмадык.

– АНЫҢ ӨЧЕН ЯШЬ АЕРМАСЫ ЮК ИДЕ

Миңвәзыйх Фатыйхов, Балык Бистәсенең «Авыл офыклары» (элеккеге «Октябрь юлы») газетасының редакторы:

– **ШУЛАЙ БЕРВАКЫТ** газетага язма җибәрдем. Язмамны, әлләкемләнеп, «М-Вазыйх» дип тамгаладым. Кадыйр абый миңа җавап хаты язды: «Хөрмәтле М-Вазыйх...» Аның өчен яшь аермасы дигән төшенчә бөтенләй юк иде. Ике генә критерий бар – кеше йә сәләтле, йә юк.

Мәктәпне тәмамлаганда, сайларга кирәк булды: агроном буламмы, журналистмы. Кадыйр абыйның карары катгый иде: «Журналист! Бетте китте!» Басылып чыккан материалларымны җыярга булышты, жанрлар турында лекция укып чыкты. Үзенең зур китапханәсеннән китаплар сайлап алып бирде. Мин Кадыйр абыйга гомерем буе бурычлы.

Ул елларның тупланмаларын карап чыгам да, шундый фикергә киләм: Кадыйр абый эшләгәндә, газетаның күпчелек өлешен әдәби текстлар алып торган булса да, җитәкчеләр бит ни язарлар икән, дип шүрләп тордылар. 1978 елда Кадыйр абый Чаллыга күченде, андагы Язучылар оешмасын җитәкләргә алынды. Әмма ул кече ватанын бик сагынды. Еш кайта иде, гомумән, яңадан кайтып төпләнергә дә омтылып карады. Барып чыкмады. Аннан көнләшүчеләр күп иде, юлын гел кискәләп тордылар.

Без Кадыйр абыйның исемен мәңгеләштерүне күздә тотып, яшь талантларны үстерүне дә максат итеп куеп, аның исемендәге премияне гамәлгә куйдык. Балык Бистәсе гимназиясенең 11нче сыйныф укучысы Алия Хәбибуллина лаек булды премиягә. Япьяшь булуына карамастан, каләме инде шомарып, үткенләнеп килә.

– ИШЕТӘ БЕЛӘ ИДЕ

Факил Сафин – язучы, Чаллы язучылар оешмасының җитәкчесе:

– **ШУЛАЙ БЕРВАКЫТ** Чаллыдагы Язучылар оешмасы җыелышында ТР Язучылар берлегенә әгъзалар тәкъдим итү мәсьәләсе тикшереде. Шөбһәле фикерләр яңгырый. Шул чакта өстәл артында утырган Кадыйр абый торып басты. «Нигә әле иҗатлары өлгермәгән кешеләрне тәкъдим итәбез? Бер дигән яшьләр бар бит. Мин Мирһади Разов белән Факил Әмәкне тәкъдим итәм. Союзга аларны тәкъдим итик, намусыбыз да чиста булыр». Бу утырышта безне чыннан да союзга тәкъдим иттеләр. Тик союзга керү бәхетенә 4 елдан соң гына ирештем. Мирһади – бераз соңрак... 1992 елның язында «Зыялылар оешмасы»на чакыру килде. Бу икенче утырыш иде. Кадыйр абый минем янга утырды. Чыгышлар башланды, китте буш сүз. Ахырда Кадыйр абый түзмәде, трибуна артына чыкты: «Әдәбиятта «мөтәшагыйрь» дигән төшенчә бар. Иҗаты сыек, әмма әрсез кешеләр халыкның зәвыгын боза, әдәбиятка зыян китерә. Без дә бу җыенда әнә шул авторлар кебек тотабыз үзебезне. «Зыялылар оешмасы»ның бурычы нәрсәдә, башкалардан ничек аерылып тора ул? Зыялыларның урыны – халык арасында, алардан бер генә адым да читкә китәргә ярамый. Минем уйлавымча, безне шул рәвешле аерып, сортларга бүлгәләп бетерергә тырышалар. Аң булыйк, җәмәгать!»

Чаллы Язучылар оешмасында җыйнак кына китап кибете бар иде. Сатучы Сәмига ханымның берничә мәртәбә әйткәне булды: «Кадыйр Сибгатуллин, кибеткә кергәч, иң беренче кулын юа торган иде. Кулын юмыйча бер генә китапка да кагылмады...»

Чыннан да Кадыйр абыйда җанга ятышлы затлылык бар иде. Тыңлый һәм, аннан да бигрәк, ишетә белә иде ул. Кирәк тапса гына, үз сүзен кистереп әйтеп куя. Юк икән – сүз куертып тормый. Бәйсез кеше иде ул, хәр, үзфикерле.

ҖИРДӘГЕ ИҢ ШӘП УРЫН

БӨГЕЛМӘ ҺӘМ АНЫҢ ХИКӘЯЛӘРЕ



Фото: Ната Смирнова

Көтмәгәндә-уйламаганда «Татарстан» редакциясе юмор-мәзәк сөючеләр шәһәренә эләкте. Кызык сүз, мәзәкнең очкыннары, кыйпылчыклары һәм бөртекләре сатирик язучы Ярослав Гашек тарафыннан Бөгелмә шәһәренең һәр почмагына сибелеп калган, гәрчә әлеге зат биредә ике айлап кына яшәп алса да. Алай гына да түгел, ул авыр, кайчак сагыш-кайгылы, ләкин шул ук вакытта героик та булган елларны юморга күмә алган.

Әйтик, мәсәлән, тимер юл вокзалы – ыгы-зыгылы, шау-шулы урын кебек: бөтенесе чемодан-букчаларын өстерәп каядыр ашыга-йөгерә-бәрелә-сугыла… Һәм шулчак пассажирлар төркеме эчендә сез күптәнге танышыгыз – солдат Швейкның самими елмаюын шәйләп аласыз. Солдат капчыгын иңенә аскан Швейк Прагадан килгән поездны көтеп тора. Әллә Уфа ягыннан килгәнме? Халык дулкыны туктап кала, йөзләргә елмаю куна, солдатны иңеннән кочарга омтылалар, чаярак кызлар, култыклап алып, битеннән үпп итәргә дә өлгерә. Чарт-чорт фотоаппаратлар эшләп ала, Бөгелмә шәһәрендә булудан канәгать калган халык поезд вагоннары буйлап таралыша. Һәм төрле җирләрдә төрле чорларга караган корылмалар, йортлар, очкыч, машиналарның бер-берсе белән дус-тату яшәвенә соклана-соклана, телефон экраннарын актара башлый.

Бала тудыру йорты, мәсәлән. Кызык бит: керү тыелган. Рөхсәт бары тик – ләкләкләргә генә.

Ләкин тыштан әллә ни күрекле булмаса да, иң истәлекле йорт биредә – 1918 елда Гашек комендант ярдәмчесе булып эшләгән комендатура урнашкан бина. Нәкъ менә биредә шәһәрчек тормышы сурәтләнгән «Бөгелмә хикәяләре» туган да.



БӨГЕЛМӘ: КҮР ӘЛЕ, СИН ЯШӘГӘН ДӨНЬЯ НИНДИ МАТУР!

БӨГЕЛМӘ ХАЛКЫНА!

Бүгенге көннән Бөгелмәдә хакимиятне үз кулыма алам. Элеккеге комендантны булдыксызлыгы һәм куркаклыгы аркасында комендант вазыйфасыннан азат итәм һәм үземнең адьютантым итеп билгелим.

Шәһәр коменданты Ерохимов.

БӨГЕЛМӘ ШӘҺӘРЕ БАШЛЫГЫНА!

Сезгә иске славян гореф-гадәтләре буенча тиз арада ипи-тоз күтәреп шәһәрнең яңа комендантына килеп җитәргә боерам.

Алай итмәгәндә, атылуга дучар ителәчәксез. Һәм йортыгызны да яндырачакмын.

Шәһәр коменданты Ерохимов.

БӨГЕЛМӘ ҺӘМ ӨЯЗ ХАЛКЫНА!

Шәһәрдә һәм өяздә укый-яза белмәгән бөтен кешегә өч көн эчендә өйрәнергә боерам. Шуннан соң укый-яза белми торган булып танылганнар атылуга хөкем ителәчәк.

Шәһәр коменданты Ерохимов.

PRESSA.RU

КОЛХОЗНИК
1941-1945

ОТСЮДА 7-8 НОЯБРЯ
1941 ГОДА УШЛИ
НА ФРОНТ ЭШЕЛОНЫ
СФОРМИРОВАННОЙ
В БУГУЛЬМЕ 352-Й
СТРЕЛКОВОЙ ОРШАН-
СКОЙ КРАСНОЗНАМЕН-
НОЙ ОРДЕНА СУВОРОВА
ДИВИЗИИ

ЕЛМАЕГЫЗ, ӘФӘНДЕЛӘР, ЕЛМАЕГЫЗ! ДӨНЬЯДА ИҢ БӨЕК АХМАКЛЫКЛАР ҖИТДИ ЧЫРАЙ БЕЛӘН ЯСАЛА.

ЯРОСЛАВ ГАШЕК

PRESSA.RU

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Өлеш безгә **КАЙДАН** килгән

Армия һөнәр сайлауга **НИЧЕК** ярдәм иткән

Төрки каганлыгы **КАЙЛАРГА** сузылган

НИ ӨЧЕН җырчы шагыйрь дә була ала

Әдипләр берлеге **НӘРСӘ** ул

Кышкы су кызларын **КАЙДА** очратырга була

PRESSA.RU

КАЙДАН СИН, **СЕРЛЕ ӨЛЕШ?!**

Рецептлар – тарихи документларга тиң язулар. Әби-апалар, туташ-ханымнардан белешү белән генә чикләнмичә, китаплардан да эзләнергә, Татарстан татарлары белән генә аралашып калмыйча, Кырым, Себер, Казахстан татарларының ашлары белән дә танышырга кирәк. Гомумән, киң вә иркен төрки дөньяны иңләп чыгарга. Бәлки, нәкъ менә шул вакытта безнең милли аш-суларыбыз турында «ташка басканнар», ягъни тарихи документлар тулы куәтенә ия булырлар. Чөнки милләтнең йөзен билгеләүче һәм аны башка милләт вәкилләре белән дә дуслаштыручы – ул ризык!

Автор:
Айсылу Хаҗиева

Боларның барысы турында да мин Балтач районына барып кайткач уйлана башладым. Тарих, аш-су, нәсел җепләрен тасвирлаучы шәҗәрәләрне бер йортта таптым. Һәр эшләгән эшен тәмле итеп сөйләп тә бирә белүче уңган хуҗабикәдә кунакта булдым бит. Сүзем Гөлфәния Шәрип кызы Мәхмүтова турында булачак.

«КАРИЛЕНӘ ҖИТ, КАРИЛЕНДӘ – ИТ!»

«Беләсеңме, нәрсә тавышы еракка барып җитә? Ризыкныкы!» – диеп каршы алды мине Гөлфәния ханым. Бер атнага гына булса да, чит илләргә чыгып китәргә туры килсә, шунда ук яңа җирдә безнең ризыкларны хәтерләткәненен эзлисең, кафеларын караштырасың, бер дә булмаса, үзең сатып алып пешерәсең. Дөрес тә әйтә соң, дип уйлап торган мизгелдә Гөлфәния ханым яңа табышмак бирде: «Кариле авылы турында нинди әйтем йөргәнен беләсеңме?» Аптыраштa калдым. Юк, минәйтәм. «Ничек итсәң ит, Кариленә җит, Кариленә җитсәң, табак тулы ит!» Әй, тукта, шушы урыннан тулырак итеп сөйлим әле…

ТОКМАЧНЫҢ ШАКМАКЛЫСЫ

Гөлфәния ханым тумышы белән Балтач районы Кариле авылыннан, ике кыз үстерә, бер нәни оныгы өчен дәү әни дә инде ул. Хуҗабикәбезнең өенә килеп кергәч, шаккатасың. Бу кадәр пөхтәлек, шәһәр фатирларыннан ким булмаган ремонт, шау чәчәктә утыручы бүлмәләр!

Гөлфәния ханым тормыш иптәшен югалту кайгысы турында үзе сүз кузгатмаган булса, мондый йортны кечкенә генә бер хатын-кыз карап торадыр дип һич уйламас идем. Уңганлыгы бар эштә дә сизелә: килеп керешкә – аш, коймак, кош теле…

Аш бүлеп чыгаргач та, токмачына күз төште. «Кибет токмачына да охшамаган, кулдан да киселгән шикелле түгел, махсус җайланма да кулланмаган, ахрысы», – дип сокланып утырганда, хуҗабикәбез, ни уйлавымны аңлап алып: «Шакмак токмач күргәнең булмаган, бугай», – дип елмайды. «Болай бит җайлырак: ашавы да, кисүе дә. Кашыктан токмачың төшеп китми, безнең Балтач якларында мондый үзгә токмач популяр ул. Хәзер аңлатам ничек кисүемне. Түп-түгәрәк итеп камырыңны җәясең, аны тасмаларга кисәсең дә, бераз кыеклатып, ромб фигурасы барлыкка китереп, кисәсең». Мин, гаҗәпләнүемне сиздермәскә тырышып, камыры турында сораша башладым: «Формасы үзенчәлекле булгач, моның камыры да гади түгелдер. Су кушасызмы соң? Ничә йомыркага басасыз?» – дим. «Юк, монда серләр була алмый. Токмач камырын берничек тә төрләндереп булмый аны. Су кушмыйм, кеше санына карап, йомыркасын салам. Сулы камыр йомшак була, тиз җеби. Без элек-электән шулай пешерәбез».

– КАБАРАМЫ? – КАБАРА!

Бу үзенчәлекле ашны ашып бетергән арада күзем тагын түгәрәкләнде: чәй өстәленә Гөлфәния ханым коймак чыгарды. Әгәр Европадан яңа гына кайтып төшкән булсам, мин аны «панкейк», дияр идем, Россиянең башка берәр шәһәрендә яшәсәм, «оладьи», дип атар идем. Әмма чыпчын татар өендә күргәч, мин әлеге коймакларны… бары тик кабартмага гына тиңли алдым. Карап-карап тордым да, өйләрендә мич тә тапмагач, сорарга булдым: «Коймакларыгыз

Фотолар: Ната Смирнова

PRESSA.RU

РЕДАКЦИЯ КУХНЯСЫ

ГӨЛФӘНИЯ МӘХМҮТОВА РЕЦЕПТЫ:

Камыр өчен:
1. Кефир – 250 г
2. Ак май – 250 г
3. 1 йомырка
4. 1/2 бал кашыгы тоз
5. 1/2 бал кашыгы сода
6. Кирәгенчә он

Эчлек өчен:
1. Суган – 3 баш
2. Тавык ите – 700 г
3. Тоз, борыч

зу-у-ур! Моны пешерүнең дә серләре бармы?» – дип төпченә башладым. «Бәй, мич коймагы бит бу! Дөресрәге, духовканыкы. Ә менә ясалышы үзгәрәк. Мин камырны тышка, суыкка чыгарып куям. Шунда яхшы кабара ул», – димәсенме Гөлфәния апам. Без барыбыз да батарея янына урындык куеп, урындык өстенә камырлы кәстрүлне урнаштырып, аны да тастымал белән каплап кабартканда, бу ханым, бер дә борчылмыйча, аны суыкка ук чыгарып куя!

– Кабарамы? – дим, гаҗәпләнеп.

– Кабара! – ди.

– Яхшымы?

– Ничек кенә әле!

Баксаң, Гөлфәния апа мондый кабару ысулын үзе дә ялгыш кына ачкан икән. Бәлеш өчен әзерләнгән камырны кемдер урамга чыгарып куйсаң, яхшырак була, дип әйткән булган аңа кайчандыр. Шулай итә дә. Коймак өчен әзерләнгән камыры да шунда чыгып, урамда онытылып кала бервакыт. Ул коймакны барыбер пешерә Гөлфәния апа, шуннан соң инде болай эшләсәң тәмлерәк тә була икән, дип нәтиҗә ясый. Шул вакыттан башлап, камырны кабартыр өчен, 30 минутка суыткычка куеп тора башлый.

КЫРЫМНАН КИЛГӘН КУНАК

Коймаклар ашалып беткәннән соң, кош теле белән танышырга керештем. Монысы инде чынлап та «безнеке» түгел, ә Кырымныкы! Татарстанда аны кош теле, урама, чәчәк дип атарга күнеккән булсалар да, бу кунак «Кырым хворосты» исемен йөртә. Әлегә тулысынча татарлашып бетмәгән.

Аны пешерер өчен 1 чокыр сөт, 1 кап маргарин, тоз һәм он кирәк булачак. Камырны басабыз да җәябез. Аннан соң, аны рулет формасына кертеп төрәбез дә, юкарак кисәкләргә кисәбез. Кызган майга салып пешерәбез.

Сироп ясарга да онытмыйк: 1 стакан шикәргә 4 аш кашыгы бал кушып, 10 минут кайнатабыз. Аннары майда пешкән һәр кисәкне бер яклап кына сиропка манып алабыз. Моны тиз эшләргә кирәк, чөнки камыр эреп таралып та китәргә мөмкин. Шуннан баллы ягы белән өскә каратып, җылы яктан килгән дустыбызны киптерәбез һәм ашыйбыз. Кырымлылар баллы, майлы ашарга ярата икәнлеген сез инде, шәт, аңлагансыздыр.

«АВЫЛЧА КЕЙТЕРИНГ»

Без бит Балтачка коймак, кош теле, аш пешерергә бармаган идек, әмма шулкадәрле күп нәрсә хакында белеп кайттык. Каян белә икән боларның барысын да Гөлфәния апа, дисәк, сәбәбе бик гади икән – ул да булса туйлар. Никахлар әзерләүче булып эшли икән героинябыз. Шуңа коймакны да, бәлешләрне дә бик күп төрле итеп пешерә белә. Заманчалаштырып, мин

Гөлфәния апаның шөгелен «авылча кейтеринг» дип атар идем. Чөнки аның заказлары күп һәм ул эшенә бик җитди карый: бары бәлеш яисә чәкчәк пешерү белән генә чикләнми. Ә заказ бирүчеләр белән бергә утырып, меню төзи, мәҗлес көнне аларга барып, аш бүлмәсендә мәш килә. Энәсеннән алып җебенә кадәр табын әзерли! Гөбәдияләр, ит бәлешләре, паштетлар да хәстәрли. Паштет – пирог түгел, дип бәхәсләшергә ашыкмагыз. Балтач якларында паштет исемен нәкъ менә өсте ачык пирог йөртә! Сары, кара җимешләрне бүлеп, камырга тезәбез дә өстен ачык калдырабыз. Шул була инде паштет!

«СҮЗ БАШЫМ БИТ ШҮРӘЛЕ...»

Без Балтач якларына Кариле авылына өлеш пешерергә барган идек. Шул ризыкны пешермичә, кайтып китә алмыйбыз бит инде. Өлеш ул – шул ук вак бәлеш, ләкин тавык ите кушып ясала, дип уйлаучылар да бардыр. Сез дә шундыйлар исәбендә йөрисез икән, әйдәгез, иң башта бергәләшеп Юныс Әхмәтҗановның «Татар халык ашлары» китабында тәкъдим ителгән рецепт белән танышыйк. Һәм аларны чагыштырып карыйк.

КИТАПЛАРДА НИГӘ ЮК?!

«Татар халык ашлары» китабында өлеш юк! Вак бәлешләр. Өчпочмаклар, сумса, дучмаклар бар, ә өлеш юк. Алай гына да түгел, вак бәлешкә салынучы итләр исемлегендә дә тавык ите күренми. Бары сыер, сарык, үрдәк, каз.

Ниһаять, тиз пешә торган вак бәлеш эзләп таптым. Ләкин анда да сарык итенең бары йомшак җирләрен салып, бүрттерелгән дөге белән пешерергә кушканнар. Шулай итеп, бу безнең аш-су рубрикасында беренче очрак: 1. Татар халык ашы дип йөртелгән өлеш чынлыкта татарныкы түгел. 2. Өлеш ул – шактый үзгәреш кичергән вак бәлеш булып чыга, димәк.

Ерак-еракларга таралып һәм мәрҗәндәй сибелеп яшәгән төрки туганнарның кайсысыныкы соң син, серле өлеш? Шунысы куандыра: ул безне бергә җыярга сәләтле ризык була ала!

Камыр пилмән камырын хәтерләтергә тиеш. Баскач та аны суыткычка 30 минутка алып куябыз. Соңрак камырны түгәрәкләп җәябез. Өлешләргә кирәк булган түгәрәк рәвешендә җәелгән камырны кисәбез. Гадәттә, моның өчен мин майонез чиләгенең капкачын кулланам. Камыр түгәрәкләп киселгәннән соң, эчлекне салып, кечкенә бәлешләр формасында җыям. Аннары майланмаган табага тезәм дә, 200 градуслы духовкага 40–50 минутка куям.

1. Болгатабыз!

2. Катнаштырабыз!

3. Әвәлибез!

4. Җәябез!

5. Кисәбез!

6. Бөрәбез!

7. Пешерергә әзерлибез!

8. Табынга чыгарабыз!

PRESSA.RU

ЧЫН ИР-ЕГЕТЛӘР ТОРМЫШЫНДА АРМИЯ

Һәрбер чын ир-егетнең тормышында армия хезмәте булырга тиеш, дип исәпли язмабызның каһарманнары. Алар – төрле һөнәр ияләре һәм конфессия вәкилләре. Үз эшенең осталарына әверелергә, менә дигән җитәкче һәм шәп гаилә башлыгы, яхшы әтиләр булып җитешергә нәкъ менә хәрби хезмәт ярдәм итте безгә, дигән караштa тора алар. «Татарстан» фотопроектында – аларның хәрби хезмәт турындагы җаваплары. Нәкъ менә бирелә, үзләренең «дембель альбомнары»н актара-актара, хатирәләргә бирелә-бирелә, Ватанны саклаучылар чын ир-атларның туган иле алдындагы бурычы турында да, имин тормыш хакында да аеруча ихласлык белән сөйлиләр.


Фото: Сергей Фомин

1.

Армия хезмәте сезгә нәрсә бирде? Нинди хатирәләр уята?

2.

Армиядән качып калучыларга карата мөнәсәбәтегез нинди?

3.

Үз улыгызны армиягә җибәрер идегезме?

PRESSA.RU

Васил Шәйхразыев, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары:

1. Минем дембель альбомым хәтер киштәсенең күзгә күренеп торырдай урынында гына ята: теләсә кайсы мизгелдә аны актарып, җанга рәхәт хатирәләргә күмелә алам. 1981 елның язында миңа **Ерак Көнчыгыш хәрби округының Кызыл Байраклы чик буе гаскәренә** әләгү бәхете тәтеде. Ике ел гомерем Устав буенча Хабаровск шәһәрендә узды. Мин анда – туган ягымнан 6 мең километр ераклыкта – бик күп нәрсәләрне өр-яңадан кичереп чыгып, нәтиҗәләр ясый алдым. Әтиәниләремә, туганнарыма, үземә карата булган ихтирам һәм яратуның көчен дә шунда ваемладым... Команда белән эшләргә өйрәндем, лидер булуның нәрсә икәнлегенә төшендем. Әйдәп бару ул үзең кылган гамәлләр өчен генә түгел, ә кул астындагыларның гамәлләре өчен дә җавап тоту икән ул. Сержантлар составы мәктәбенең старшинасы идем, курсантлар белән чикнең аргы ягына чыгарга туры килгәләде. Үземнең «яшь сугышчы» курсын да яхшы хәтерлим. Уку тренировкасына без, өйдән киткәннән соң, әни пешергән ризыкны сагынып интеккән, әле балалыктан чыгып бетмәгән чик буе сакчылары, нәкъ балык сезонында килеп төштек. Амурдагы застава безне кета балыгы өелеп торган өсталләр белән каршы алды. Алай гына да түгел, өстәлдә уылдык тулы касәләр тезелешеп тора, җитмәсә. Һәм... 25 көн буена шулай дәвам итте. «Белое солнце пустыни» фильмын еш искә төшерә идек. Хәтерлисезме андагы атаклы гыйбарәне: «Опять ты мне эту икру поставила! Не могу я ее каждый день, проклятую, есть».

Узган елны, утыз елдан соң, туган отрядым белән заставымны күреп кайту насыйп булды. Бергә хезмәт иткән хәрби иптәшләремә шуннан шалтыраттым! Язмышыма әлеге сәхифәләр өчен зур рәхмәт! Чик буе гаскәрендә хезмәт итү мине чыныктырды, ныгытты.

2. Армия хезмәтеннән качып йөрүчеләргә мөнәсәбәтем тискәре. Моны 90нчы һәм нуленче еллардан калган ямьсез күренеш дип саныйм. СССР җимерелгәч, армиянең дә дәрәҗәсе бик нык какшады бит. Сугышлар, «дедовщина», үлем – армия белән бәйле күзаллаулар шундый иде ул чакта. Аналарның күз яшьләре, ачыргалануы. Нәтиҗәдә, хезмәт итәргә барырга егетләрнең коты алынып тора башлады. 2003 елда мин Яр Чаллы муниципалитетында эшләдем, хәрби хезмәткә чакырылыш буенча җаваплы идем. Без егетләрнең үзләрен дә, әнкәләрен дә хәрби хезмәтнең куркыныч түгеллегенә инандырырга тырыштык. Алар белән күрешеп сөйләшә идек – армия турында сөйлибез, агитация уздырабыз. Шәхси үрнәк тә зур роль уйнады – ул чакта күп кенә җитәкчеләр уларын хезмәт итәргә җибәрде. Хәрби частьлар белән районнар арасында шефларча килешүләр дә төзелде. Ул авыр заманнар артта калды, бүген республикада хәрби чакырылыш мәсьәләсендә проблемалар юк. Егетләр армиягә барырга тели, бу мактауга лаек.

3. Аллаһы Тәгалә безгә кызлар насыйп итте. Әмма гаиләбездә үрнәк булырдай кеше бар – ул безнең киявебез. Армиягә бару карарын мөстәкыйль кабул итте, без аны хупладык. Хезмәт итәргә тиеш егетләр! Кара диңгез флотына эләкте. Өендә аны хатыны белән кечкенә кызы көтәләр.

Фото: Ната Смирнова

– ХАРАКТЕРЫ БУЛГАН КЕШЕГӘ БЕРНИНДИ «ДЕДОВЩИНА» ДА КУРКЫНЫЧ ТҮГЕЛ.

Феофан, Казан һәм Татарстан митрополиты:

1. Мин Ульяновскида хезмәт иттем. Андагы хәрби элемтә училищесы каршында тәэминат ротасы бар иде. Шуны гына әйтә алам: армия мине күп нәрсәгә өйрәтте. Беренчесе – коллектив белән эш итә белү. Икенчесе – характер тәрбияләде, мин хәрби хезмәткә малай гына булып килдем, бирегә ир-егет булып өлгердем. Өченчесе – армиягә килгәч, «ватан» төшенчәсенең нәрсә икәнен аңладым һәм аны ничек сакларга кирәклегенә төшендем. Элек «дедовщина» турында сүзләр күп йөри иде, хәзер акрынлап басылды. Мин хезмәт иткәндә дә бар иде ул «картлачлар» белән «яшьләр»гә бүленеш. Ләкин синең характерың бар икән, сиңа бернинди «дедовщина» да куркыныч түгел, үзеңне барыбер яклый алачаксың. Бу бит сынауларны кичәргә өйрәнү мәктәбе дә. Мин, Аллаһка ышана торган кеше буларак, моны шулай кабул иттем дә – чираттагы сынау итеп. Һич онытасым юк: Пасха вакытында гыйбадәтханәгә барган өчен гауптвахта эләкте миңа. Инануымны сизенеп алгач, кайбер партия хезмәткәрләре «тәрбияләргә» тырышып карады. Шулвакыт бер өлкән яшьтәге подполковник мине яклап чыкты. «Ышанасыңмы, улым?» – дип сорады. «Әйе», – дидем. Һәм ул миңа орынмаска әмер бирде.

Армиядән алган иң зур тәэсирем хәрби ант кабул иткәннән соң… 50 ел узгач булды. Мин ул антны Казан Кремлендә кабул иткән идем. Ярты гасыр үткәч, мин ул урынга инде митрополит буларак, беренче гыйбадәтемне кылырга дип килдем.

2. Армия хезмәтеннән качып йөрүчеләрне өнәмим. Ярый, алар бүген хәрби хезмәттән баш тарттылар, ди, иртәгә исә андыйлар ватаннарыннан, ә аннары әти-әниләреннән дә баш тартырга мөмкиннәр бит… Бу – иманлы, дөрес юл түгел.

3. Мин – рухани, шулай булгач, балаларым, шул исәптән улларым да, күп. Баламны армиягә җибәримме, дигән сорау белән шактый күп мөрәҗәгать итәләр. Мин һәрчак: «Егет кеше хезмәт итәргә тиеш», – дип җавап бирәм. Минем туганнарым күп, аларның ир балалары бар. Шуларның берсе берничә ел элек хәрби училищены тәмамлады. Аны – япь-яшь офицерны – Дагыстанга юлладылар. Бер елга диярлек. Ә ул Дагыстанда сугыш барган чак иде. Егет, билгеле инде, борчылды, әнисе аннан да бигрәк кайгырды. Миңа шалтыраттылар: нишлик икән, диләр. Мин аңа шундый сорау бирдем: «Син бит хәрби ант тоткансыңдыр?» «Әлбәттә», – ди. «Шулай булгач, ватаның өчен кая барырга кушылган, шунда бар», – дип киңәш иттем. Дагыстанның иң «кайнар нокта»сында хезмәт итеп кайтты. Хәзер миңа теге чакта биргән киңәшем өчен рәхмәт укый.

PRESSA.RU

– ИР-АТ «ВАТАН АЛДЫНДАГЫ БУРЫЧ» ТӨШЕНЧӘСЕН АҢЛАРГА ТИЕШ.

Тимур хәзрәт Ибраһимов, Кызыл Байрак авылындагы Йосыпов исемендәге мәчетнең имам-хатыйбы:

1. 1979 ел, Алма-Ата, Кызыл Байраклы Урта Азия хәрби округы. Мин – капитан, АН-26 самолеты очучысы. **Хезмәт иткән көннәрнең берсендә хәрби тревога игълан ителде: Әфганстан безнең өчен шулай башланды.** Әфганстанга үзебезнең командование белән «Первомайка» аэродромыннан очтык. Бурычыбыз – шәхси составны, зур булмаган техника, коралларны күчерү. Ләкин бу гына түгел. Әфганстанның барлык аэродромнарында да булганга, без берьюлы элемтә урнаштыру белән дә шөгыльләнә идек. Ул ил тулаем таулар белән уратып алынган. Ретрансляторлар торуына карамастан, алар аша элемтә узмый диярлек. Сугыш хәрәкәтләре вакытында без, махсус аппаратура белән тәэмин ителгәнгә күрә, таулар өстеннән оча идек – безнең аша команда пунктыннан әмерләр тапшырыла. Очучылар арасында шундый төшенчә бар – еллык санитар норма. Безнең очракта ул бер атна эчендә үтәлә иде. Аэродромда – самолет эчендә йоклыйбыз. Палаткаларга да чыкмый идек хәтта. Дежур торучы килә дә фезюляжга шакый. Шунда ук сикереп торабыз, генератор җайланмасын кабызып җибәрәбез һәм команда пункты белән бәйләнешкә чыгабыз. Анда безгә кайсы ноктага юл тотарга икәнлеген хәбәр итәләр. Сулыш алырга да вакыт булмый торган чаклар була иде. Еш кына Алма-Атага очабыз – самолетларны техник яктан тәэмин итү буенча регламентта каралган эшләр шунда башкарыла. Советлар Союзына буш кул белән кайтмый идек беркайчан да, һәрчак – шыплап тулган самолет белән. Безнең белән өйгә отпускниклар һәм 200 нче тамгалы әрнеткеч йөк кузгала иде…

2. **Армиядән качып калучыларга мөнәсәбәтем тискәре.** Ир-егет «ватан алдындагы бурыч» төшенчәсен аңламый икән, бу юньле күренеш түгел.

3. **Улым Габдуллага 22 яшь. Псков десант-һөҗүм итү дивизиясендә хезмәттә булды.** Армиягә барыр алдыннан парашюттан сикерү белән шөгыльләнде. Аннан соң инде минем эзләремнән китте – Краснодар шәһәрендәге югары хәрби авиация училищесына укырга керде. Очучы булачак!



Фото: Ната Смирнова

– АРМИЯДӘ ПРОФЕССИОНАЛЛАР ХЕЗМӘТ ИТӘРГӘ ТИЕШ!

Рөстәм Абязов, Казан дәүләт «La Primavera» камера оркестрының дирижеры һәм сәнгать җитәкчесе:

1. Армиягә 1982 елда, Мәскәү консерваториясен тәмамлагач, киттем. Үз теләгем белән, чөнки яхшы аңлый идем: тормышта сайлаган юнәлешең нинди, шул юнәлештә эш итәргә кирәк. Җыелу пунктына скрипка күтәреп килдем. Әмма берәүгә дә кирәгем булмавы ачыкланды. Башта Төньяк флотка барасым килгән иде, аннары – «Мосфильм»ның кавалерия полкына, әмма безне икенче көнне генә **СССРның ЭЭМның Эчке гаскәре ансамбленә алдылар. Ул яңа гына тупланган иде һәм, аңлашыла инде, кадрларга кытлык кичерә.** Хәзер генә ул экраннардан даими күренеп килә – барлык эстрада йолдызлары ул оркестр белән җырлап чыкты диярлек инде. Виктор Елисеев исемле генерал-майор – ансамбльнең сәнгать җитәкчесе һәм дирижеры – мин хезмәт иткәндә әле капитан дәрәҗәсендә иде. Мин анда скрипкада уйнадым. Моннан тыш, взвод командирының ярдәмчесе вазыйфасын да башкардым, чөнки минем югары белемем һәм партия билетым бар иде. Ансамбль тарихында махсус укымыйча сержант дәрәҗәсен алган беренче «срочник» булдым. Минем кул астымда 20 кеше иде. Нинди генә булмасын, барыбер командир! Ә бу, үз чиратында, ниндидер өстенлекләр дә, зур җаваплылык та. Хәтерлим, миндә бер төргәк ялган азат итү (увольнительный) кәгазьләре бар иде, мин аларны бик җайлы гына эшкә җибәреп тордым. Җитәкчелекнең музыкада тирән йөзмәве дә файдага булды. Без еш кына «нота станогы», йә булмаса «бемольләр» артыннан шәһәргә чыгып китә идек.

Инде хезмәт итеп кайткач, Казанда, мине бервакыт военкоматка чакыртып алдылар: «Ватанга офицерлар бик кирәк. Без сезнең документларыгызны тикшереп чыктык, безгә туры киләсез...» – диләр. Мин алардан шулчак сорадым: «Кагылмассызмы соң? Сборларга чакырмассызмы?» Вәгъдә бирделәр. Мин хәзер запастагы өлкән лейтенант.

2. **Мин болай уйлыйм: һәр кеше үз профессиональ өлкәсендә эш алып барырга тиеш.** Армиядә дә профессионаллар булсын.

3. **Улымның армиядә хезмәт итүен теләмәс идем.** Дөресен генә әйткәндә, мин үз хезмәт елларымны әллә ни күңелле еллар димәс идем. Әйе, шартлар начар булмады, без гастрольләр белән бөтен СССРны йөреп чыктык, Венгриядә булып кайттык. Миңа тәтегән хезмәт – иң начары булмады, сүз дә юк. Әмма барыбер дә – ирексезлек...

PRESSA.RU

инде! Озын ленталар белән – алары тезгә кадәр диярлек төшеп тора. Болар, билгеле, минем гардеробымда да бар иде. Түбән Камага әйләнеп кайткач, шул форманы киеп, урамнан узу – үзе бер горурлык, кызлар күзләрен алмыйлар...

2. Армиягә бармаучыларны аңламыйм. Чын ир-егет армия сынавын узарга тиеш. Әйе, анда күп нәрсә белән очрашырга туры килә – дедовщина да, сагыну хисе дә... Әмма боларны кичереп карамыйча ярамый, юкса үзеңне чын-чынлап ир-ат итеп тоярга өйрәнеп булмый. Тирә-юньдәгеләр дә армиягә барып кайтучыларга башкача карый – ихтирам белән. Димәк, син чүпрәк түгел. Димәк, син – солдат. Ир кеше. Бу бик мөһим.

3. Улым Саратов янындагы ракета гаскәрләрендә хезмәт итте. Срогы җиткәч тә китте армиягә. Берәү дә көчләмәде, үзе теләде. Менә дигән итеп хезмәт итеп, старшина дәрәҗәсендә кайтты. Мин үзем дә старшина. Икебез дә хәзер армия хезмәтен зур горурлык белән искә алабыз.

Мин бүгенге армиядә нинди хәлләр булып ятуы турында кистереп әйтә алмыйм, әлбәттә, шуны гына беләм: без хезмәт иткән чактагыдан бик нык аерыла ул. Безгә кыенрак булды. Хәзер «дедовщина» белән дә хәлләр икенчерәк, җиңелрәк, чөнки үз заманында бу мәсьәләгә зур игътибар бирелде. Хезмәт срогы да – бер генә ел. Йә, нәрсә инде бу?! Кыш, яз, җәй, көз – һәм син кабат туган йортыңда. Нәрсәдән качып ятарга мөмкин бу очракта? Мин балаларын армиядән алып калырга омтылучы ата-аналарны да аңламыйм. Билгеле, балам белән бер-бер хәл була күрмәсен, дип шикләнәләрдер. Соң, бу бит көлке! Армиядә килеп чыккан гадәттән тыш хәлләр – гадәттә миллионга бер. Ләкин болар җәмгатьчелектә армиягә карата мөнәсәбәтне формалаштыра. Моның дөрес түгел, гадел түгел икәнлеген халыкка аңлату зарур. Армия һәрчак булган һәм булачак! Ватанны сакларга кирәк. Без башка илләрдән ялланган гаскәрләрне файдаланмыйбыз, без үз илебезне үзебез саклыйбыз. Хатын-кызларга да армия хезмәте комачау итмәс иде. Израиль армиясендә алар бар бит.

– ҮЗЕМ ДӘ ХЕЗМӘТ ИТТЕМ, УЛЫМ ДА, ХАТЫН-КЫЗЛАРГА ДА ХЕЗМӘТ ИТҮ КОМАЧАУЛАМАС ИДЕ!

Александр Латышев, «Республика Татарстан» газетасының баш мөхәррире:

1. 1971 елдан 1973 елга кадәр Тын океан флотында Советская Гавань шәһәрендә хезмәт иттем. Инженер гаскәрендә без яр буе корылмаларын тәэмин итү белән шөгыльләндек. Шунда мин эшкә өйрәндем. Кулга чүкеч тотудан башлап, катлаулы төзелеш эшләренә кадәр башкара идек. Сугышка әзерлекле часть та идек без бер үк вакытта: корал тотарга, аның белән эш итәргә өйрәттеләр, дежур да тора идек, вахта да булды. Бар да – хәрби хезмәттә тиешле булганча. Минем өчен «армия» һәм «флот» төшенчәләре коры сүз генә түгел. Инде шуннан бирле күпме еллар үтсә дә, хезмәттәш егетләрне онытмыйм. Миңа армиядә булып кайтырга насыйп иткәне өчен язмышыма чын күңелемнән рәхмәт белдерәм. Клёш чалбарларны да яхшы хәтерлим, бескозыркаларны да – матроска алардан башка ярамый! Мин запаска киткәндә, зур бескозыркаларга мода кергән чор иде, аэродром кадәрле иделәр, әкәмәт

Фото: Ната Смирнова

– ИКЕ УЛЫМ ДА ХЕЗМӘТ ИТӘЧӘК!

Вячеслав Фёдоров, Ми-8 вертолеты командиры, Казан авиация предприятиесе:

1. Мин Ерак Көнчыгыш чик буе округында хезмәт иттем. Шимановск шәһәрчегендә. Бу Амур өлкәсе. Мине анда хәзерге тормышымда кирәкле барлык нәрсәләргә дә өйрәттеләр. Машина йөртергә дә, атарга да, ә иң мөһиме – үз гамәлләрем өчен җавап тотарга. Физик әзерлек тә бик шәп иде безнең: дозорга 15әр километрга китеп йөри идек. Бу әле төшке ашка кадәр генә. Чик буе гаскәрләрендә дедовщина юк, чөнки анда солдатларга коралны һәр көн тапшыралар, сугыш патроннары белән, билгеле. Без хәтта ашханәгә дә корып куелган корал белән йөри идек.

2. Һәр ир-егет армия хезмәтен үтәргә тиеш, мин армиягә бармаган ирләрне хөрмәткә лаек дип санамыйм. Тормышта алар армия мәктәбен узмыйча ничек яшәрләр икән? Гаиләсе, эше, гамәлләре өчен җавап бирергә кайда өйрәнерләр? Алар бит беренче кыенлыклар каршында ук куркып калачаклар.

3. 2 улым һәм 2 кызым бар. Уларым армиягә барачаклар! Олысына тиздән 17 яшь тула. Хатыным да минем фикеремне хуплый: чын ир-егетне армия тәрбияли, ди ул. Шуңа безнең өйдә армиядән коткарып калу буенча берниндi сөйләшүләрнең дә булганы юк. Әйтегез әле миңа, нәрсәдән коткарырга? Тормыш мәктәбеннәнме? Юк, минем улларым ул мәктәпне узачак!

PRESSA.RU



Икенче төрки каганат (687–742 еллар).

ТӨРКИ КАГАНЛЫГЫ: ТАРИХ ҺӘМ МӘДӘНИЯТ

Дөньякүләм танылган шәрык белгече профессор Сергей Кляшторный үзенең хезмәтләрендә Төрки каганлыгын (551–745 еллар) хәзерге Россия җирлегендә барлыкка килгән беренче империя дип атый. Бүгенге төрки халыклар борынгы бабаларының тарихы һәм югары үскән язма мәдәнияте белән нигезле рәвештә горурлана алалар, дип яза ул әлеге дәүләтнең 1450 ел тулуына багышланган бер мәкаләсендә (2001 ел).

Автор:
Фаяз Хуҗин

ТӨРКИЛӘР – ҺУННАР НӘСЕЛЕННӘНМЕ?

Бу сорауга галимнәр анык кына җавап бирә алмыйлар, әмма Үзәк Азия далаларында калган һуннар төркиләрнең халык булып оешуында, һичшиксез, зур роль уйнаганнар. Һәрхәлдә, төркиләр үзләрен һуннар токымы дип санныйлар. Борынгы Кытай тарихчылары теркәп калдырган һәм төрле вариантларда безнең көннәргә кадәр сакланып килгән риваятьләрнең берсендә төркиләрнең килеп чыгышы турында болай әйтелә: имеш, һуннарны күрше кабиләләр тулысынча кырып бетерәләр. Ун яшьлек бер малай гына исән кала, аны да әле дошманнар, кул-аягын кисеп, гарипләндереп, сазлыкка ташлап калдыралар. Малайны бу хәлләрне читтән күзәтеп торган бер ана бүре коткарып кала, ашата-эчертә, таyга алып китеп, мәгарәгә яшерә. Еллар үтә, егет булып үскән һун малае сугышта һәлак була, ана бүре аңардан ун ир бала таба. Тора-бара бу ыруг ишәя. Бүренең бер оныгы Ашина исемен ала. Менә шул Ашина тарих битләрендә төркиләр династиясенә нигез салучы сыйфатында кереп калган. Сүз уңаеннан: Монголия территориясендә табылган 2 метрлы таш стелада югарыда китерелгән легендага иллюстрация рәвешендә бүре сурәте уелган. Татарстан территориясендә, элгәреге болгарлар яшәгән җирләрдә, бронзадан ясалган йозаклар табыла. Аларның бер өлеше бүрегә утырган гарип – бер кулсыз, бер аяксыз җайдак рәвешендә ясалган.

Кытай язмаларында төркиләрнең килеп чыгышы Көнчыгыш Тянь-Шань җирләре белән бәйләп аңлатыла. Биредә төркиләр һәм аларның элгәрләре булган һуннар 460 нчы елларга кадәр яшиләр. Аларга монгол телле сугышчан жужан кабиләләре (*аварлар*) һөҗүм итә. Төркиләр Алтай якларына күченеп утырырга мәҗбүр булалар. Алар баштагы чорда утрак тормышта яшиләр, жужаннарга буйсынган хәлдә, шул тирәдәге халыклар арасында беренчеләрдән булып, Алтай тауларында тимер рудасы чыгару, рудадан тимер эретү, тимердән эш һәм сугыш кораллары ясау белән шөгыльләнәләр. Жужан-

Фотолар автордан алынды

Рун язуы.
Күлтәгингә мәдхия.

Алтын савыт. Шәмши каберлеге.
Кыргызстан.

нарның икътисады һәм сугышчыларының корал белән тәэмин ителүе бөтенләе белән диярлек төркиләргә бәйле була.

ТӨРКИ ДӘҮЛӘТЕ БАРЛЫККА КИЛҮ

VI гасыр башларында «тимерче» төркиләргә, аларның көчен сизеп, якын-тирәдә күчмә тормыш алып баручы кабиләләр дә килеп кушыла башлый. Төрки кабиләләр берләшмәсе башлыгы итеп 534 елда Бумын исемле юлбашчы (*ябгу*) сайлана. Ул идарә иткән чорда яулап алу сугышлары ешая. Бумын үз биләмәләрен көнчыгышка – Хуанхэ үзәннәренә таба киңәйтә, хәтта жуҗаннар белән дә хисаплашмый башлый. Шул ук вакытта Бумын Кытай белән тату мөнәсәбәттә булырга, сәүдә элемтәләре урнаштырырга омтыла. 545 елда Бумын ставкасына Кытай императоры илчелеге килә. «Төркиләр бер-берсен котладылар һәм, хәзер безнең дәүләт чәчәк атачак, безнең илгә бөек дәүләт илчесе килде бит, дип шатландылар». Кытай елъязмаларының берсендә бу хакта әнә шулай язылган. Бумын да җавап йөзеннән Кытайга бик күп бүләкләр белән үзенең илчелеген җибәрә. Ике ил арасында дипломатик мөнәсәбәтләр урнаша.

Тиздән бөтен халык арасында нәфрәт тудырган жуҗаннар бәйлелегеннән тулысынча котылырга уңай очрак туа. Бервакыт жуҗаннар изүеннән интеккән *теле* кабиләләре изүчеләргә каршы баш күтәрәләр. Һөҗүмгә барганда алар төркиләр белән очрашалар. *Теле* сугышчылары Бумынга тулысынча күндәмлек белдерәләр, баш ияләр. Шуннан соң «үзенең көченә һәм гаскәренең күплегенә таянып, тәвәккәл Бумын жуҗан дәүләте башлыгына (*каганга*) аның кызын хатынлыкка сорап мөрәҗәгать итә», – дип яза Кытай тарихчысы. Ачуы чыккан каган: «Син бары тик минем тимер эретүчем, миңа шундый үтенеч белән килергә ничек җөрьәт иттең?» – дип җавап бирә. Бумын ачуын сиздерми. Бераздан ул хатынлыкка Кытай императорының кызын сорый һәм, ризалыгын алып, аңа өйләнә. Оешып килә торган төркиләр дәүләте халыкара танылу ала. Күчмә халыклар арасында Бумынның һәм төркиләрнең абруе үсә. Уңай форсаттан файдаланып, Бумын 551 елда жуҗаннар гаскәрен тар-мар итә, мөстәкыйльлек ала һәм үзен каган (*каһан – каан – хан*) – ил башлыгы дип игълан итә. Шулай итеп, Үзәк Азия җирләрендә яңа дәүләт – Төрки каганлыгы барлыкка килә.

ИСТӘМИ КАГАН ҺӘМ ТӨРКИ ЯУЛАРЫ

552 елда Төрки каганлыгына нигез салучы Бумын каган үлеп китә. Аның варислары, күрше кабиләләр белән өзлексез сугышлар алып барып, яңа җирләр яулап, дәүләт биләмәләрен шактый киңәйтүгә ирешәләр. Төркиләр җиңелгән кабиләләрнең байлыкларын талыйлар, әсирлеккә төшкән кешеләрне кол итәләр. Хәтта чираттагы бәрелешләрнең берсендә җиңелгән Кытай императоры да каганга ел саен ясак – 100 мең кисәк ефәк тукыма җибәреп торырга мәҗбүр була.

Каганлык төзелеп бераз вакыт узуга, төрки гаскәрләре һуннар салган юллар буенча Көнбатышка таба хәрәкәт итә башлыйлар. Бу яу башында Бумынның энесе, акыллы һәм батыр сугышчы, оста дипломат Истәми каган һәм аның улы Кара Чура тора. Көньяк Себер, Арал буе, Көньяк Урал кабиләләрен буйсындырып, алар 558 елда – кыска гына вакыт эчендә! – Алтай тауларыннан Идел елгасына кадәр килеп җитәләр.

Урта Азиядә төркиләр эфталитларның куәтле дәүләтен, согыд берләшмәсен тар-мар итәләр һәм көчле сасанидлар Ираны белән союз төзиләр. Иран белән Төрки каганлыгы Урта Азия җирләрен үзара бүлешәләр. Амударья елгасыннан көнчыгышта һәм төньякта яткан барлык җирләр каганлык составына кертелә. Яулап алынган җирләрдә төркиләргә Бөек ефәк юлын, димәк, халыкара сәүдәне контрольдә тотарга мөмкинлек туа, бу исә дәүләтнең икътисадый куәтен тагын да көчәйтергә булыша.

Төркиләр дәүләтен, дөрестән дә, чын империя дип санарга була. Аның биләмәләре көнчыгышта Сары диңгездән алып, көнбатышта Кара диңгез буендагы далаларга кадәр булган иксез-чиксез җирләрне колачлый. Бу җирләрдә дистәләгән телдә сөйләшүче, төрле дин тотучы,

PRESSA.RU


Борынгы төрки таш һәйкәле.

Бронза савыт.
VII–VIII гасырлар. Алтай.

Борынгы төрки
таш сыны.

Төркиләрнең тире белән тарттырылган агач калкан фрагменты.
Муг ныгытмасы калдыклары. VIII гасыр. Үзбәкстан.

утрак һәм күчмә тормыш алып баручы халыклар яши. Аларның барысы да төрки каганына буйсынырга мәҗбүр ителәләр. Сугыш корбансыз булмый, диләр. Төрки яулары исә артык үлем-төшем алып килми: җирле халык, үзеннән күпкә көчле гаскәрне күреп, сугышмыйча диярлек буйсына. Нәтиҗәдә алар салым, ясак түләү бәрабәренә үзләренең гасырлар буена калыплашкан традицион яшәү рәвешләрен саклап калалар. Урындагы түрәләр дә, хакимият системасында артык үзгәрешләр кичермичә, элекке вазыйфаларын үтәүне дәвам итәләр.

ИМПЕРИЯЛӘРНЕҢ ГОМЕРЕ ОЗЫН ТҮГЕЛ

Бу – меңьеллык тарих белән күп тапкырлар расланган хакыйкать. Ничек кенә булмасын, шулкадәр зур территориядә корал көче белән оешкан империя бердәм булып озак яши алмый. Өлкәләр арасында тыгыз икътисадый бәйләнешләр булмый. Сирәк кенә булса да үзара кабынып киткән сугышлар, аксөяк ыруг вәкилләре арасында кулга төшерелгән җирләр белән мөстәкыйль идарә итүгә омтылыш, хакимият өчен югары катлау кешеләре арасында барган сәяси көрәш дәүләтне какшата. Нәтиҗәдә 581–603 елларда Төрки каганлыгы әкренләп ике өлешкә бүленә. Көнбатыш (Урта Азия) өлешенә Алтайдан алып, Кара диңгезгә кадәрге җирләр керә. Аның үзәге Җидесуда була (хәзерге Казахстанның көньяк-көнчыгыш, Кыргызстанның төньяк өлкәләре). Көнчыгыш Төрки каганлыгы Алтайдан алып, Бөек Кытай стенасына кадәрге җирләрне берләштерә. Аның үзәге Орхон елгасында, хәзерге Монголия территориясендә була. Озак та үтми, 630 елда, ике дәүләт тә яшәүдән туктый – аларны Тан (Кытай) империясе үзенә буйсындыра.

Әмма ярты гасыр чамасы вакыт узгач, 680 елда, Монголиядә Көнчыгыш Төрки каганлыгы яңадан оеша (аны еш кына II Төрк каганлыгы дип тә йөртәләр). Ул 740 елга кадәр яши һәм кешелек дөньясына Күлтәгин, Тоньюкук, Билге каган исемнәре уелган ташларда төркиләрнең югары мәдәниятен чагылдыручы рун язма үрнәкләрен калдыра.

ТӨРКИЛӘРДӘ МӘДӘНИЯТ

Төрки каганлыгы Үзәк һәм Урта Азия, Көнчыгыш Европа халыклары тарихында мөһим роль уйный. Һуннар кебек үк, төркиләрне дә хәзерге төрки халыкларның барысы да үзләренең элгәрләре, борынгы бабалары сыйфатында кабул итә. Бу аңлашыла да, чөнки төрки каганнары төрки телле кабиләләрне һәм халыкларны, чагыштырмача кыска гына вакытка булса да, бер дәүләт кысаларында туплауга ирешәләр, һәм шул берләшмә кысаларында хәзерге төрки халыкларның мәдәнияте формалаша башлый.

Әйтеп үтелгәнчә, төркиләр рун графикасына нигезләнгән язма мәдәният булдыралар. Рун язуын бөтен каганлык халкы кулланган, Идел болгарларында ул хәтта XII гасырга кадәр, ислам дине белән гарәп графикасы таралгач та кулланылышта була. Рун язулы ташлар, металл савыт-сабалар, керамик эшләнмәләр Монголиядә, Алтайда, Көньяк Себердә, Урта Азия илләрендә, Көнчыгыш Европада (Идел, Дон буйларында, Төньяк Кавказда) гына түгел, хәтта Болгария, Венгрия кебек илләрдә дә табыла. Шушы язу нигезендә соңыннан гомумтөрки әдәби теле барлыкка килә. Төрки халыклар бер-берсен бүген дә яхшы аңлыйлар, дибез икән, димәк, әлегә кадәр артык үзгәрешләр кичермәгән шушы уртак телебез белән без борынгы төркиләргә бурычлы. Рун язмаларындагы бик күп сүзләр бүген дә аңлаешлы яңгырый:

ač – ач; adaq – аяк; altun – алтын; ben, men – мин; buz – бозу, вату; eki – ике; er – ир кеше, сугышчы; keling – килен; küč – көч; kümüš – көмеш; nenčä – ничә; qarï – капка; qorq – курку; singil – сеңел; qut (kot) – җан; sač – чәч; sub – су; tümän – ун мең h.б.

Борынгы төркиләр җәмгыятендә без хәзер толерантлык дип еш кабатлый торган, асылда башка халыкларның диннәренә, яшәү рәвешләренә, ата-бабалардан килә

Төркеш каганаты тәңкәләре.
VII–VIII гасырлар.

Борынгы төрки
кабер ташы.

Рун язулы бронза көзге.
VII–IX гасырлар. Көнчыгыш Казахстан.

торган милли традицияләренә ихтирам белән карау, түземлелек күренеше киң таралган булган. Илнең төп халкы Күк алласы Тәңрегә табынган, әмма буйсындырылган башка халыклар арасында мәҗүсиләр дә, несториан-христианнар да, Буддага табынучылар да булган. Һәм аларны берәү дә кыерсытмаган. Дин тоту ирекле булган, көчләп берәүне дә башка дингә күндермәгәннәр. Бу җәһәттән Көнбатыш Төрки каганлыгының башкаласы Суябта (аның калдыклары Кыргызстанның Ак-Бешим шәһәре тирәсендә) үткәрелгән археологик тикшеренүләр нәтиҗәсе кызыклы. Шәһәр уртасында диярлек бер-берсенә якын гына урнашкан христиан-несторианнар чиркәве һәм Будда храмы хәрабәләре сакланган, шәһәр кырыенда исә мәҗүсиләрнең үз аллаларына табына торган изге урыннары булган.

Сүз уңаеннан, Суябтагы археологик тикшеренүләр белән бәйле тагын бер нәрсәне искә төшереп үтәсем килә. Төркиләрне гадәттә, аларның элгәрләре һуннар кебек үк, күчмәннәр дип атыйлар. Нигездә бу дөрес фикер: киез юрталарда яшәгәннәр, төп байлыклары – мал-туар, аяк һәм өс киемнәре – киездән, ашау-эчүләре – сөт һәм ит ризыклары. Әмма аларның зур гына шәһәрләре булуын да истән чыгармаска кирәк. Гомуми мәйданы 100 гектардан артып киткән Суяб – шундыйларның берсе. Биредә йортлар һәм җәмәгать биналары кирпечтән салынган. Урамнарында арыктан чиста су агып яткан, ә ул су шәһәр янындагы тау елгасыннан озынлыгы берничә километрга җитә торган керамик торбалар аша килгән. Якын-тирәдә урнашкан авыл халкы игенчелек белән дә шөгыльләнгән. Игенчелектә, һава шартлары коры булганлыктан, ирригация системасы кулланылган. Менә боларның барысы да борынгы төркиләрнең хуҗалык һәм мәдәният үсешендәге прогрессив күренешләр дип бәяләргә кирәк. Һуннар чорында формалаша башлаган төрки цивилизациясе яңа баскычка күтәрелә.

ТӨРКИЛӘР КАГАНЛЫГЫ ЧОРЫНДА УРТА ИДЕЛ БУЙЛАРЫ

Төрки каганнары Азов, Каспий һәм Кара диңгез буе далалары өчен сугыш алып барган чорда безнең якларга яңа кабиләләр күчеп утыра. Фәндә аларны Имәнкискә кабиләләре дип йөртәләр, чөнки алар турында тәүге мәгълүматлар Татарстанның Лаеш районы Имәнкискә авылы янындагы борынгы шәһәрлекне казулар нәтиҗәсендә табыла.

Имәнкискәлеләрнең матди культурасы җирле кабиләләрнекеннән кискен аерылып торган. Мәсәлән, күмү йолалары: мәетләрне алар башта яндырганнар, аннан соң, калдыкларын балчык чүлмәкләргә салып, кечкенә чокырларга күмә торган булганнар.

Имәнкискәлеләрдә игенчелек нык үсеш алган. Җирле кабиләләр арасында алар беренчеләрдән булып басуларны ат җигеп, тимер төрәнле агач сука белән эшкәрткәннәр. Терлекчелек тә аларның төп шөгыльләренең берсе саналган.

Бу кабилә кешеләре бик ерак өлкәләр, хәтта Урта Азия һәм хәзерге Казахстан җирләрендә яшәгән халыклар белән сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырганнар. Җирле кабиләләр арасында беренчеләрдән булып сәүдә эшләрендә бронзадан чүкеп эшләнгән металл акча кулланганнар.

Имәнкискә кабиләләренең кайсы тарафлардан килеп утыруы, «милләте» ягыннан нинди халык булуы, димәк, нинди телдә сөйләшкәннәре турында фәнни бәхәсләр әлегә кадәр дәвам итә. Кайбер галимнәр аларны төркиләр, икенчеләре – сарматлар (иран телле), дүртенчеләре борынгы славяннар дип атый. Герман телле готлар түгел микән дип фараз кылучылар бар. Бу өлкәдә соңгы елларда җентекле тикшеренүләр алып барыла, әмма нәтиҗәләр ясарга иртәрәк әле. Бары тик шунысы гына билгеле: имәнкискәлеләр, башка кайбер кабиләләр кебек үк, Төрки каганлыгының яулап алу сугышлары аркасында яшәгән җирләрен ташлап китәргә мәҗбүр булганнар.

PRESSA.RU

«ХОДАЙ МИНЕ МАТУРЛЫКНЫ КҮРЕР ӨЧЕН ЯРАТКАНДЫР...»

Әңгәмәдәш:
Луиза Янсуар

Ул дөньяны үзенә бер төрле... нечкә... нәфис... матур итеп күрә белә. Шигъриятендә дә, җырларында да яши бу матурлык. Башак өлгертеп килгән арыш басуында күтәрелгән алтын дулкын белән күрше клевер басуында кузгалган яшел дулкынның, бер-берсе каршына йөгереп килеп, бәрелешү мизгелендә дөньяга яңгыраган музыканы ишетә алу сәләтен Ходай һәр бәндәсенә дә иңдерми. Һәм аныкы кебек кабатланмас тавышны да. Сүзем Георгий Ибушев турында.

ҖЫРНЫҢ БАШЫ КАЙДА?

Мин дә бит, мин дә бит шул җирнең
Былбылы, сөекле баласы...

Георгий Ибушев бу җыруны суз-ганда, күз алдымнан, асты-өскә айкалып, борынгы төрки дала, җай гына искән җилгә җайлашып, канат көчен сынаучы бөркетләр, кайнар тыны белән һаваны ярып юыртучы атлар табуны йөгереп уза. Андрей Тарковский, Грегори Колберт фильмнарындагы кебек, Вакыт, тыгызланып, куерып, тук-тап кала, һәм исәп тә Мәңгелек бәрабәренә тиңләшә.

Без Салих Сәйдәш белән Рөстәм Яхинны аңламаслык дәрәҗәгә төшеп җитүебезне сизми дә калдык... Милләт буларак, Рөстәм Яхинның җыр-романсларын аңларлык биеклеккә күтәрелә алмыйбыз икән, адәм рәтле, чын дәүләт булып беркайчан да оеша алмаячакбыз... Тирән аһәңле җырларның кадере бетсә, кешенең дә кадере югала. Чөнки җыр – җан бит ул. Ә кадерсез җан башканы кадерле, җылыта алмый.

Мин аның шагыйрь икәнен чагыштырмача соң белдем. Китабы басылып чыккач кына. Гәрчә язучылардан: «Сезнең Георгий коеп куйган шагыйрь бит! Чын шагыйрь», – дигәннәрен ишеткәли идем. «Чын шагыйрь» төшенчәсе минем өчен деклартивлыктан азат булган чиста лирик образ белән тәңгәлләшкәнгә, мин аны шулай күзалладым да. Ә инде Георгий Ибушевның шигърият басуларына килеп чыккач, берара сулышым кысылып торды. Ул миңа яраткан Лоркамны хәтерләтте. Есенинны.

Хәер, чагыштырулар беркайчан да юньлегә илтми. Кирәкми дә. Моңарчы «адәм баласына Кодрәт иңдерсә дә иңдерә бит тавышны», дип гаҗәпләнсәм, шул мәлдән инде «шулкадәр дә табигый, ихлас-самими була ала бит шагыйрьнең сүзе» дип сокландым.

– Мин бит көчәнеп язмыйм, шагыйрьлеккә дәгъва кылым да түгел, – ди Георгий дәдәй, очрашкач та, сүзне шигырьдән башлап. – Мин язмыйча түзә алмыйм! Шулкадәр матурлыкны күрә торып... ничек язмаска мөмкин?! Беркайчан да шигырьләр халыкка, милләткә хезмәт итәргә тиеш, дигән лозунглар белән килешмәдем. Аңлый алмыйм мин аларны. Җыр да, шигърият тә матурлыктан, мәхәббәттән ярала һәм кешелекне иң беренче чыганагына – Башлангычына кайтарыр өчен хезмәт итә. Ходайдан иңдерелгән алар һәм Ходай тудырган матурлыкны данлар өчен яратылган.

Менә, соңгы елларда рәсем ясалмый никтер. Үзем дә аңламыйм: ни булды? Берөзлексез ясый идем, югыйсә. Мин, гадәттә, төсле ручкалар белән әллә нинди гаҗәеп сарайлар «торгыза» идем кәгазьдә. Андый сарайларны үз гомеремдә күргәнем дә юк, каян киләдер алар... Нинди архитектура стиленә, кайсы чорга караганнарын да белмим, әмма ясый башлагач, һәр детален, һәр ташын, һәр колоннасын белгәндәй булам...

Кечкенәдән үземнең башкачарак икәнлегемне сизенә идем. Чөнки кешеләр күрмәгән нәрсәләргә игътибар итә идем гел. Берсендә Ольга түти белән кукуруз басуына эт эчәгесе йолкырга бардык. Түти әйтә: «Кукуруз буе гәүдәң юк, керәсе булма басу эченә, адашырсың», – ди. Калдым, уйнап йөрим. Карыйм: ике басу тоташкан чиккә бер яктан алтын дулкын булып арыш башаклары йөгерә, икенче яктан – ямь-яшел клевер. Болар бер-берсенә бәрелештеләр дә, дөньяга чың таралды. Түтигә дәшәм: «Кара әле, кара!» – дим. «Күрмим бит, улым, бернәрсә дә», – ди түти. Әмма ул хисчән иде барыбер. Тормышчан да.

Без кечкенә чакта өйгә кеше күп җыела иде. Минем штабым – мич башы. Шуннан бөтен дөнья хәлләрен тыңлап ятам. Колхоз хәлләрен дә сөйлиләр иде анда, җен күргәннәрен дә, кайсы йортта нәрсә булуын да... Ашлар вакытында нинди генә җырулар җырланмый да, нинди генә кыйссалар бәян ителми... Мине җырулар бик тетрәндерә иде. Берсе аеруча хәтергә уелып калган. Бик зур шом салган иде сабый күңелемә:

Итләрем бетсә, сөягем калыр,
Шул чакта да сине онытмам...

– МИНЕМ ӘТИ – КЫЗЫК КЕШЕ

– Балачагым алтын чор булды. Үземне 4–5 яшьлек чагымнан аермачык хәтерлим. Биш баланың төпчеге булгач, әллә ни авыр эш белән басылып үсмәдем. Авылда эш бетеп тормый инде ул, әмма безне эш белән чыдап булмаслык итеп измәделәр. Бәлки, шуңа да матурлыкны күреп, сокланып йөрергә мөмкин булгандыр...

Әти мин туганда инде чирле иде, әллә ни хәлле тормыш алып бара алмадык. Җил капкалы, салам түбәле йортыбыз әле дә күз алдымда тора. Безнең өебез авылның иң матур очында урнашкан иде. Каршыда үскән таллар йортка керәм, керәм, дип торалар. Җәй көне мин аларның лепердәвен тыңлап кинәнәм, ә менә кышка кергәч, алар туңадыр, дип бик кайгыра идем. Мич башында утырам, юрганга төренгәнмен, ә таллар сыкрап-сыкрап куя, ботаклар җилдә тузгый да тузгый. Юрганымны алып чыгып төрәсем, җылытасым килә иде шуларны – әмма ачуланырлар дип куркам. Аннары без ул нигездән күчендек. И елаган идем ул чакта...

Әтинең тәэсире бик зур булды миңа – бик матур җырлый, гармунда уйный иде ул. Әнием дә җыр-моң ярата торган кеше иде. Гади генә колхозчы гаиләсе булуга карамастан, гомумән бөтен туган-тумача җырлый, китап укый иде безнең. Ул чакта авыл үзе үк бертуктаусыз җырлый иде бит. Радиотәлинкәдән көнозын концертлар тапшыралар. Мин, керәшен мәҗлесләреннән тыш, шуларны тыңлый-тыңлый да җырларга өйрәндем. Алардагы җырлау белән авылдагы җырлауның аерылып торуын сизенә идем. Авыл хатыннарының Ястык урамыннан ат арбасына төялеп фермага барганда сузган җыруларын һич онытасым юк. Күз алдымда тора ул арба һаман – печән җәелгән, ике якка тезелешеп, аякларын салындырып түтиләр утырган...

Үзем дә көне-төне җырлый идем. Мөтлекүл басуы – беренче сәхнәм булгандыр, мөгаен. Өйдә Татый әбинең: «Башны авырттырып бетердең инде», – дип орышканын хәтерлим. Яратып кына орыша иде инде ул, ачуланып түгел.

Әни безне берсендә әти белән җиләккә җибәрде. Миңа шул 5–6 яшьләр чамасы булгандыр. Киттек янәшә теркелдәп Ташлы тау итәгеннән узып урманга, кулыбызда агач тәпәннәр. «Җата басу дулкынланып,

Кечкенә Георгий мәктәптә пионер бәйрәмендә чыгыш ясый. Мамадыш. 1967 ел.

Фотолар: Георгий Ибушев һәм Татар дәүләт филармониясе архивыннан

Концерт алдыннан.

күр син...» – димәсенме шунда әти, тирән итеп сулап. Бик хисле кеше иде ул. Мин инде эчемнән генә уйлап куям: «Минем әти кызык кеше инде. Сөйләшүе дә кызык».

Аягымда яшел сандалилар иде. Аларга тузан куна да, мин учым белән шул тузанны сөртеп алам. Чиста булсыннар, янәсе. Әти мине ул чакта җиләк котырып уңган серле бер урынга алып барды. Исләрем киткән иде! Дус малаем Җәкәүне уйлый-уйлый җыйдым ул җиләкләрне. «Эх, икенче юлы Җәкәүне алып килергә кирәк монда, икебез генә белгән серле урын булыр», – дип.

– НИНДИ ТОНАЛЬНОСТЬТА ИКӘНЕН БЕЛМИМ...

– 5нче класста укыганда, көтмәгәндә-уйламаганда шигырь яза башладым. Баштарак газеталардан хатлар килә иде, әлегә бастыра алмыйбыз, ләкин син яз, каләмеңне шомарт, дип. Бервакыт «Әтиләр» исемле шигырем басылып та чыкты. Әтидән мин 12 яшьтә калдым...

10нчыда укыган чакта «Яшь ленинчы» газетасының 50 еллык юбилеена чакырып алдылар. Мамадышның пионер оешмасы җитәкчесе мине һәм тагын берничә яза торган баланы җитәкләп алып китте Казанга. Шунда беренче тапкыр тере язучыларны күрдем – Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Нури Арслан, Сибгат Хәкимнәрне... Алардан автографлар алдым, кайткач, бу автографларга авыл халкы таң калды. Миңа анда ниндидер грамота да биреп кайтардылар әле...

Мәктәптәге укытучылар җырлавымны бик ярата иделәр. Талантыңны үстерергә кирәк, дип әйтә килделәр. 1975 елда мин «Комсомол җыры-75» бәйгесендә катнаштым. Һәртөрле ВИАлар популярлашкан вакыт. Ә мин сәхнәгә гармун күтәреп чыктым. «Туган җирем Татарстан» белән «Комсомолка Гөлсара»ны җырладым. Дипломант булдым. Нәкъ менә шул конкурста мине Миңгол абый Галиев күреп алган булып чыкты.

– Тавышың бик әйбәт, сиңа укырга кирәк, – диде ул миңа. Кайда килергә икәнлеген әйтте.

Мин, авылда печән эшләре тәмамлангач, август урталарында килеп төштем Казанга. Кабул итү имтиханнары инде тәмаланган булып чыкты. Җәй башында ук килергә кирәк булган икән. Шуңа да карамастан, консерваториянең ул чактагы ректоры Нәҗип Җиһанов тыңлап карарга ризалашты.

– Нинди тональноста җырлыйсың? – дип сорадылар миннән.

– Ул нәрсә була? Белмим, – димен.

Нәҗип абый мине әзерлек курсларына кабул итәргә кушты. Әмма тулай торакта инде урыннар калмау сәбәпле, фатир эзләргә кирәк иде. Котым очты: рус телен дә белмим, каян эзләп табам инде мин ул фатирны... Миңгол абыйга сиздерми генә, авылга шылдым...

– КАЙДА ЙӨРИСЕҢ, КАЧКЫН КЕРӘШЕН?!

– Армиягә киттем. Килгәч, взводны нәрәткә куйдылар. Миңа ашханәдә балык өләшү эләкте. Җырлый-җырлый балык өләшеп йөрим. Шундый мавыгып киткәнмен, дөньяны онытканмын... Берзаман карыйм: ишек төбенә халык җыелган. Авызларын ачып тыңлыйлар.

– Син консерваториядән соңмы әллә?! – диләр.

Армиядә мин рус телемне шомарттым, русча җырлый башладым. Хәрби оркестр белән «Соловьи», «Где же вы теперь, друзья-однополчане», «Смуглянка»ларны башкара идем.

Рота командиры Шестопалов чакыртып алды бервакыт. Казарма артына алып чыгып җырлата иде ул мине. Безне Германиягә җибәрергә тиешләр икән. Әмма Шестопалов мине анда җибәртмәс өчен тырышты. Гомумән, солдат хезмәте вакытында ул миңа күз-колак булды, әтием кебек үз итте, кайгыртты.

Армиядән соң, Түбән Камага барып чыктым, химкомбинатта эшли башладым. Шулчак мине Казанга Миңгол абый чакыртып алды:

– Кайда йөрисең син, качкын керәшен? – дип шелтәләде.

Без подгруппада 20–25 кеше идек. Комиссия алдында барысы да дер килә. Аннары аңладым: алар күбесе музыка мәктәпләрен тәмамлап килгәннәр, училищеларны, музыканың нәрсә икәнлеген беләләр. Ә мин курыкмыйм: ничек җырлый алсам, шулай җырлыйм инде.

Аннан миннән көлделәр:

– Без бит инде сине консерваториягә бер алган идек, Жора, – диделәр.

Укый башлаганда бик авыр булды. Фәнни коммунизм, КПСС тарихын укыталар иде бит. Вокал дәресләрендә мин «головное звучание»не тотып алдым да шаккаттым. Моңарчы тавышны алай көйләргә кирәклеген күз алдына да китерми идем. Ул үзеннән-үзе табигый ага, дип уйлый идем.

1989 елда миңа «Татар җыры» конкурсында катнашырга туры килде. Җырлыйм, биегрәк алдым бугай, дип уйлыйм эчемнән генә. «Нәрсә булды икән бу – до диезмы?» – дим. Аннары миңа, ул чыгышымны искә алып, берничә мәртәбә: «Жора, хәтерлисеңме, теге чакта син чип-чиста фа алган идең», – диделәр.

Нәҗип Җиһанов класска килеп керә иде дә, алып чыгып китә иде мине. «Әйдә, коридордан урап йөреп килик әле бер», – диеп. Үземне Алланың кашка тәкәсе кебек хис итә идем. Эһ, яшьлектә кадерен белеп бетермисең бит ул мизгелләрнең...

– БОЛАР МИНЕ ӨЙГӘ КАЙТАРЫРМЫ ИКӘН?..

– Консерваториядән соң, филармониягә эшкә урнаштым. Урнаштым гына, конкурска барырга куштылар. Краснодарга. Монда без бер гаҗәеп хәлгә юлыктык: чүпрә саталар. Сатып алдык, шул бер җырларбыз да, кайтып китәрбез инде, дип уйлыйбыз. Ә Казанда бит юк чүпрә, менә күчтәнәч була, ичмасам! Әмма мин, барлык турларны да узып, 12 көнгә гастрольләргә калдым. Казанга диплом белән кайттым. Бу филармония өчен зур сөенеч булды инде. Шунда ук минем окладымны 150 сумга күтәрделәр. Ул чакта әле бер исемем дә юк, шул диплом гына. Андый акчаны озак еллар эшләгән артистлар да алмый иде.

Берзаман үзгәртеп кору еллары башланды, китте хәерчелек. Дөресен генә әйткәндә, җыр сәнгатенең кризисы әнә шул чакта башланды

да. Бәясе дә, шул чакта бер төшкәч, бүтән күтәрелмәде инде аның.

Без, җырчы халык, үзенә үзе хуҗа кешеләр түгел. Шулай берсендә мине Мәскәүгә чыгыш ясарга җибәрделәр – Соловьяненко, Соткилава белән бер сәхнәдә җырлыйсы була иде. Соткилава бит инде дөнья сәхнәләрендә чыгыш ясаган кеше, чын мәгънәсендә йолдыз. Мин кем инде болар янында, дип уйлыйм.

Бик әйбәт итеп каршы алдылар – «Чайка»га гына утыртып йөртәләр, ресторанда ашаталар. Кунакханәдәге бүлмәнең 2 кешелек булуы өчен гафу үтенделәр. «Торуын үзегез генә торасыз, әмма 1 кешелек номер булмады шул», – диләр. Мин инде эчемнән генә көләм: «Ай Алла, сез безне ничек яши дип беләсез икән», – дим.

Чыгышлар шәп узды. Соткилаваның 10–15ләп ханымнан гыйбарәт свитасы – яраннары белән йөрүе хәтердә калды. Концертта мин чыгышымны «Әллүки» белән тәмамладым. Татар җырының бөтен матурлыгын күрсәтә алырдай әсәрләр башкарылды анда, халык бик җылы кабул итте. Сәхнә артына кереп, соңыннан рус тамашачысы миңа: «Нечаевтан соң мондый тавышны ишеткәнебез юк иде әле, рәхмәт сезгә», – диделәр. Читтә татар җырларын башкарганда, җаваплылык хисе икеләтә зур – синең милли сәнгатең турында әнә шул бер башкарудан ишетеп калып, нәтиҗә чыгарырлар, бәлки. Планканы гаять югары тотарга тиешсең!

Концертны оештыручы да бик разый калган иде ул чактагы чыгышымнан: «Сезгә ни дә булса кирәкмиме?» – дип сорады ул миннән кат-кат. «Балалар уйный торган кечкенә скрипка кирәк иде», – дим. Икенче көнне ул скрипка минем кулымда иде инде.

Тагын бер очрак. Люксембургтан киләсе делегация алдында чыгыш ясарга кирәк. Чакырдылар безне «Чәй йорты»на – мин, Хәйдәр, Зилә... Төнге 1 гә кадәр көттек. Килделәр. Җырлыйбыз. Карыйм: парламент җитәкчесе булган ханым мин җырлаганда, маңгаена күрсәтеп, тәрҗемәчесенә җыр техникасы турында нидер сөйли. Гаҗәпләндем. Чыгышлар тәмамланып, кайтырга кузгалгач, бу мине коридорда тотып алды, соклануын белдерде. Баксаң, ул әле профессиональ музыкант, Люксембург консерваториясенең вокал факультеты җитәкчесе дә булып чыкты. Сөйләшеп киттек. «Сезне шоферыгыз көтеп торадыр инде, тоткарлыйм үзегезне», – ди миңа бу ханым. «Шоферым юк минем», – дип әйтеп бетерергә өлгермәдем, иңемә авыр бер кул ятты: «Бар, көтә», – ди кул иясе. Карасам, чынлап та машина көтеп тора. Кереп утырдым да, уйлап барам: «Ходаем, – дим, – болар мине өйгә кайтарырмы икән инде...»

Чит илләрдән килгән кунаклар безне, артист халкын, бик зур гонорарлар алып, бай тормышта яши, дип уйлый. Чөнки аларның үзләрендә яхшы тавышлы җырчылар алтын бәясендә йөри, мин әнә теге рәсемнәремдә ясаган кебек затлы сарайларда яшиләр. Әйтеп булмый бит инде аларга, таксига акча җитмәгән чаклар да була, ә төнге сәгать бердә шәһәр буйлап җәяү кайтып җитә алмыйсың, дип...

Шулай да, мин үземне бәхетле җырчы дип саныйм. Халкым да, җитәкчелек тә таныды, зурлады мине. Һәркемнең Ходай бүлеп биргән үз кишәрлеге бар, мин үз өлешемә тигән шул кишәрлеккә шөкер, дип яшим.

Рәхмәт сиңа, җырым, бергә булдык,
Өстә булдык, түбән төшмәдек.
Тамак, диеп, юк-бар чор такмагын
Үзебезгә юлдаш итмәдек.

Син канатлар куйдың бу җаныма,
Ул канатлар булды ак, чиста.
Мин беркемгә зыян китермәдем,
Дан, дәрәҗә даулап тормышта.

– БЕЗ МОНДА ВАКЫТЛЫЧА...

– Хатыным Әдилә белән радиода таныштык. Беренче күрүдә үк ошаттым мин аны. Гаилә корып җибәрдек, ике ул тәрбияләп үстердек. Шөкер, уңдык улларыбыздан, икесе дә музыкантлар, бик төпле, акыллы егетләр. Гаиләдә иминлек булу – зур бәхет, бигрәк тә иҗат дөньясындагы кеше өчен. Хатынымны гомерем буена яратам. Однолюб мин, хисләрдә дә, иҗатта да таралып, чәчелеп йөри белмим. Ул минем табигатемә туры килми. Нәрсә дә булса минеке икән, мин аны шунда ук тоемлап алам.

Авылдагы өйдә мичкә ягып җибәреп, утын чартлавын тыңлыйтыңлый, тышта гүләгән буранга колак сала-сала, уйларыңны тәртипкә китереп, язып утыру – монысы да зур бәхет! Әле мичкә кабыгы әрчелмәгән бәрәңге дә тәгәрәтеп җибәрсәң... Мин ашарга пешерергә яратам. Уңа аш-суым. Иркенләп, онытылып ризык хәстәрләү – ул борынгыдан калган бер серле йола бит. Хәзер без кибет ризыгына ияләшеп барабыз. Ләкин кибет ризыгының сере юк, аны күңел җылысын куша-куша, җырулар суза-суза, догалар пышылдый-пышылдый әзерләмәгәннәр...

Авыл белән балачактан килгән бәйләнешне югалтмадым – шул саклый мине. Казанда яши башлаганыма инде 41 ел. Әмма теләсә кайсы мизгелдә кечкенә генә бер юл чемоданымны эләктереп, чыгып китәргә әзермен. Беләм: мин монда – вакытлыча. Гомер дигән вакыт эчендә бирелгән бар матурлыкны күреп, тоеп, җырга сеңдереп бетерәсе килә.

Менә, тиздән сыерчыклар кайтачак. Безнең авылдагы Праский түти сыерчыкларның авылга кайтуы хөрмәтенә карга ятып ауный иде. Яз килүенә сөенә, табигатьне олылый. Тиздән карлар челтәрләнә башлаячак, гөрләвекләр кузгалачак...

Шәһәрдә ул әллә ни сизелми, ә менә авылда һәр фасылның үз исе бар. Язларын берара шомырт, сирень исеннән исереп утыра авыл. Алмагачлар чәчәк ата. Бераздан елга буйлатып җүкә чәчәге исе агып төшә авылга. Хушбуй сибенгән, өрфия яулыгын бөркәнгән яшь киленмени – урамнардагы ул исне иснәп туеп булмый...

– ҖЫП-ҖЫЛЫ КҮҢЕЛЕМ...

– Гомернең бар тәмен татыдым,
Язмышка бер үпкәм юк минем.
Җанымда якты нур сакладым.
Кагылсаң, җып-җылы күңелем.

Дөньябызны хөсетлек, наданлык басты. Шул эчтән черетә безне. Күңелендә нур булмаган кеше, өстәвенә надан да булса, башкаларны беркайчан да ишетә, аңлый, кабул итә алмаячак. Сәнгатьтә дә һәр адымда очрап тора бу, гадәти тормышта да. Онытабыз: без бит – җырчымы, тәзүчеме, колхозчымы, гарәпме, керәшенме, полякмы – бер-беребездән бик аз аерылабыз. Культура, интеллект ягыннан бик үк мактана алмаса, кеше, әйтик, көнкүрешен, нигезен ныклы итеп төзи алгандыр, бу да – олы эш. Гадәттә, гадирәк тормыш белән яшәүче кешеләр балаларын төпле итеп үстерәләр. Иманлы итеп.

Диннәр арасындагы низаглар да – сафсата. Мине бер очрашуга чакырдылар. Сорау бирәләр: «Ә сезнең аллагыз нинди?» – диләр. «Мин православ дине вәкиле», – дидем. «Алай булгач, сез безнең алланыкы түгел», – дигән җавап ишеттем. Соң, биш алла юк бит инде, барыбызның да шул – берәү ләбаса Ул!

Дини кануннарга караганда, эчке иманга күбрәк ышанам. Иман ул – биш вакыт намаз уку, службаларның барысына да йөрү түгел әле. Иман ул, иң беренче чиратта, ярату. Ярату булмаса, кеше денле була алмый!

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНЫҢ ӘДӘБИ ПРЕМИЯСЕ



«Татарстан» журналының
әдәби премиясе

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы һәм «Татарстан» журналы әдәби премиягә бәйге игълан итә

«Татарстан» журналы әдәби премиясе Татарстан матур әдәбиятына сизелерлек өлеш керткән әдәби әсәрләр иҗат итүче авторларны барлау һәм иҗатларына игътибарны арттыру максатыннан игълан ителде.

Премиягә түбәндәге жанрларда иҗат ителгән кульязмалар дәгъва итә ала: роман, повесть, хикәяләр циклы. **Әсәрләрнең Татарстан турында яки Татарстан авторы тарафыннан иҗат ителгән һәм моңарчы беркайда да басылмаган булуы – бәйгенең төп шарты!**

Кульязмалар Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә – русча һәм татарча – кабул ителә.

2017 ел дәвамында «Татарстан» журналы Экспертлар советы тарафыннан сайлап алынган текстларны журнал битләрендә һәм журнал сайтында protatarstan.ru басылып барачак.

Гран-при – китабыгызның басылып чыгуы.

2017 елның декабрендә бәйгенең жюрие ике телдә иҗат ителгән әсәрләр арасыннан җиңүчеләрне сайлап алачак – татар телендә бер әсәр һәм рус телендә бер әсәр. Икесе дә китап булып басылып чыгачаклар.

Бәйгенең шартлары:

1. Кульязманың электрон версиясе.
2. Номинант турында мәгълүмат – әсәр авторының фамилиясе, исеме, атасының исеме, контактлары – белешмә өчен телефоны, адресы).
3. Авторның кыскача иҗади биографиясе (әгәр әдәби әсәр берничә автор тарафыннан иҗат ителгән булса, һәрберсенеке).
4. Әсәрнең синопсисы.

Кульязма таләп ителгән материалларның тулы пакеты белән килмәгән очракта, жюри рәисе әсәрне кабул итмәскә хокуклы.

Кульязмалар tatarstan@tatmedia.com электрон тартмасына «КОНКУРСКА» тамгасы белән кабул ителә.

Конкурсны уткәрү вакыты 2017 елның 19 гыйнварыннан 2017 елның 15 декабренә кадәр.

Тулырак мәгълүмат protatarstan.ru сайтында.

«МИН БУ КИТАПНЫ ГОМЕРЕМ БУЕ ЯЗДЫМ...»

Шулай дип башлады сүзен Равил абый Фәйзуллин. Ә сүзебез аның Татарстан китап нәшриятында яңа гына басылып чыккан «Татарстан язучылар берлеге» китабы турында. «Татарстан» журналы бу күпьеллык саллы хезмәткә, әлбәттә, игътибарсыз кала алмады.

Автор:
Луиза Янсуар

Чөнки туплама ярты гасырга сузылган кеше һәм әдип гомерен, шулай ук аның заманына туры килгән вакыйгалар калейдоскобын үз эченә ала. Автор аның жанрын тәгаенләргә омтылыш ясапмы, әллә, киресенчә, бу очракта жанрны тәгаенләү мөмкин түгеллеген ассызыкларга теләпме, билгеләмә дә биргән: «публицистик уйланулар, тарихи фактлар, хатирә-күзәтүләр». Һәм язучылар берлеге дигән рәсми атама астына да, җәяләр эченә алып, «әдипләр берлеге» дип өстәүне кирәк тапкан.

Бүгенге заман укучысы гаять популяр булган нон фикшн жанрына өстенлек бирә. Равил Фәйзуллин, бу җәһәттән, нәкъ менә шул укучыга кызыклы була алырдай форманы сайлаган. Әлбәттә, мода артыннан куып түгелдер, чөнки бу хезмәтнең тамырлары әле нон фикшнга мода кергәнчегә кадәрге елларга ук барып тоташа. Автор үзе әйтүенчә, 50–60 ел дәвамында әдәби процессның эпицентрында торып ясаган күзәтүләрнең нәтиҗәсе ул. Үзенә күрә бер протокол, елъязма.

Мин китапны киң җәмәгатьчелеккә укырга тәкъдим итәм – бу безнең тарихыбыз, бу безне үткән белән тоташтыручы һәм дөньяга карашыбызны тагын да ныграк киңәйтергә мөмкинлек бирүче җеп-дисбе. Шуңа да китапка карата мөнәсәбәт белдереп, акыл сатып утыруны гына кирәк дип исәпләмәдем, бу хезмәт басылып чыгу уңае белән, Равил абыйның үзе белән тагын бер кат күрешеп, гәпләшеп алуны урынлырак таптым.

– Равил абый, протокол сүзе рәсмирәк, күңелсезрәк яңгырый кебек. Сез бит инде аны җыелышларда махсус теркәп утырмагансыздыр. Ничек әзерләнде бу китап?

– Рәсми яңгыраса да, китапка ул бик яхшы туры килә, дип уйлыйм. Күз алдыңа китер, мин Татарстан Язучылар берлегенең идарәсендә генә дә даими 50 ел дәвамында торган кеше. Ә идарә ул – язучылар оешмасының нәкъ менә җитди, хәлиткеч карарлар кабул итәр өчен съезд сайлап куйган эшче төркеме. Минем күз алдымнан бу 50 ел эчендә бик күп вакыйгалар узды. Инде шушы яшемә җиткәч, артка борылып карап, бу тәҗрибәне киләчәк буыннарга да калдырырга кирәк бит, дигән уй туды. Башка кешеләр калмады да шикелле инде моның өчен...

– Ләкин сез перспективаны киңәйтәсез...

– Башкача булмый да. Чөнки, әдипләр бер-берсе белән Татарстан Язучылар берлеге оешкан вакыттан гына аралаша башламаган бит. Мин язучыларга гына түгел, ә чын мәгънәсендә милләтнең рухи юлбашчысы, лидеры булган шәхесләргә тукталдым. Мәсәлән, Ризаэддин Фәхретдин, Фатих Кәрими, Дәрдеманд... Шулай ук, уртак оешмалары барлыкка килгәнче, татарның талантлы яшьләрен берләштергән Шәрык клубын искә алмыйча да мөмкин түгел иде... Әмма болары – кереш кенә. Үзенә күрә, темага алып керер киту өлеше. Чын мәгънәсендә хроника 1934 елда Мәскәүнең Союзлар йортындагы Колонналы залында узган язучылар җыеныннан башланып китә. Һәм бүгенгегә килеп

Беренче съездда катнашучылар. Беренче рәттә (сулдан уңга): Кави Нәҗми, Алексей Толстой, Максим Горький; икенче рәттә: Ләбиб Гыйльми, Хәсән Туфан, Гомәр Толымбай, Фатих Сәйфи-Казанлы, Галимҗан Нигъмәти.

тоташа. Әйе, бу чын мәгънәсендә татар язучылары оешмасы барлыкка килгәннән бирле иҗтимагый-тарихи барышның бөртекләп, детальләп, вакыйгалап теркәлеп барган беркетмәсе.

Китап фактлар һәм детальләр белән тулы, шуңа өстәп, Равил Фәйзуллин алар артында нәрсә ятуын, вакыйгалар белән нинди көчләр идарә итүен дә күрсәтеп барырга омтыла үз укучысына. Әйтик, репрессияләр, шәхес культы елларына караган сәхифәләргә генә күз ташлыйк. Укучы буларак, болары миңа аеруча кызыклы. Чөнки, бу шомлы елларда язучы каләменең куәсе, иҗаты ягыннан гына түгел, ә намусы буенча да сынау үткән. Тарих битләрендә кемнең исеме нинди хәрефләр белән язылып калуын нәкъ менә үзеннән соңгы архивлар күрсәтә бит нигездә. Автор фактлар белән сак эш итә, аннан да бигрәк – нәтиҗәләр белән. Кистереп бәя бирергә ашыкмый. Фикер сөрешеннән әзерлекле укучы мөнәсәбәтне үзе сөзеп ала.

Ә менә урыны-урыны белән бәясен кистереп тә әйтеп бирә ул. Әйтик, 1959 елда булып узган съезд турында бәян иткәннән соң, китапның 3нче бүлеген болай йомгаклап куя: «Шул чорның, шул зур җыеннарның тагын бер характерлы ягы: СССР күләмендәме, Россия яки республикалар күләмендәме, язучылар съездына илнең иң югары постында торган җитәкчеләр төркем белән килә иде, чыгыш-докладлар ясап, банкет-приемнарда да утыра иде. Әдәбиятның, язучыларның дәрәҗәсе югары икәнен дәлилләүче күренеш бу, дип уйлыйм. Әдәбиятка ил башлыкларының мөнәсәбәтен, игътибарын күреп, гади халык та язучыларны зурлый, олылый иде...»

– Димәк, үзенә күрә бер вертикаль булган? Сезнеңчә, халыкның язучыга булган мәхәббәте белән хакимиятнең илтифаты арасында турыдан-туры бәйләнеш бармы?

– Хәзер инде болар бер-берсенә бәйләнмәгән кебек тә күренергә мөмкин. Әмма бар, минемчә. Халык хәзер язучының дәрәҗәсе түбән төшкәнне күреп тора, шуңа да аны бик олыламый. Инерция буенча бара әле ул хөрмәт – укытучыларда, китапханә хезмәткәрләрендә... Ә хакимияткә элгәреге заманда язучы идеология булдырыр өчен кирәк иде. Халык аңына тәэсир итәр өчен. Мин ул вакыттагы процедураларны яхшы хәтерлим. Союзга өлкә комитетыннан шалтыратып кына торалар иде. Бигрәк тә премияләр бирер алдыннан. Без инде үз кандидатураларыбызны тәгаенләп, барабыз җитәкчеләр янына. Алар әзерлекле кешеләр иде. Безгә сүз бирәләр, әйтәбез тәкъдимнәребезне. Аннары алар сүз ала: менә без шушы язучыны лаек дип саныйбыз, диләр. Бу очракта инде килешергә генә кала. Һәм шунысы гаҗәп: алар ялгышып сайламыйлар иде. Һәрьяклап уйланган карар була иде ул. Әгәр Тукай премиясенең ул елларда кемнәргә бирелеп барганын күздән кичерсәк, без моңа инана алабыз. Анда очраклы кешеләр юк диярлек. Халык та белә, үз итә иде ул әдипләрне. Ә хәзер Тукай премиясен алган язучыларны халык бик үк белмәскә дә мөмкин.

– Ул чакларда Язучылар берлеге әгъзасы булу зур мәртәбә саналган. Аның матди ягы да үз ролен уйнамый калмаган. Ә хәзерге вазыйфасын нидә күрәсез Татарстан Язучылар берлегенең? Хәзер ул, формация буларак, иҗтимагый оешма рәвешен алгач, киләчәктә иҗатчылар өчен актуаль булырмы?

– Аның вазыйфасы элек тә, хәзер дә бер – әдипләрне бер төенгә, көлтәгә туплап тору. Без үзбаш яшәсәк тә, барыбер уртак бер нигезебез булырга тиеш. Без болай да хәзер хакимияткә әллә ни кирәк түгелбез, чөнки бүгенге коммерциягә генә корылган дөньяда әллә ни зур үзгәрешләр булдыра алмыйбыз. Әмма бүгенге язучының төп вазыйфасы – телне саклау, милли үзаңны күтәрү. Менә шушы безнең бүгенге идеологиябез.

– Әмма бүген язучы каләме белән тамак туйдыра алмый, монысы көн кебек ачык...

– Дөрес әйтәсең, мин бу хакта уйланам-уйланам да, шуны аңлыйм: сезнең буынга безнең буынга караганда күпкә авыррак. Без Язучылар берлеге әгъзасы булган заманда оешманың матди базасы нык, куәтле иде. Литфонд эшләп тора – санаторийларга, Иҗат йортларына бару мөмкинлеге. Әйтик, минем үземә Коктебельда шул заманның атаклы язучылары белән очрашып, якыннан аралашу насыйп булды. Безне кайгыртталар иде. Хәзерге иҗатчыларга карата булган кайгыртучанлык шул юрганның озынлыгына бәйле, билгеле.

90нчы еллар, Милли-азатлык хәрәкәте белән бәйле сәхифәләргә, хөррият җиленең ничегрәк исүенә тукталган өлештә мин инде билгеле бер фактлар, детальләргә орынып, үз хроникам белән параллельләр үткәреп укый башлыйм. Шуңа да минем буын вәкилләре өчен китапның бу өлеше, нигездә, Автор-күзәтүче белән кайсыдыр урында килешү, хуплау, кайсыдыр урыннарда бәхәсләшү кыры булыр. Иң «авырткан урын» милли матбугат язмышына кагылышлы битләр булды. Равил Фәйзуллин, 25 ел дәвамында «Казан утлары» журналының баш мөхәррире вазыйфасын башкарган кеше буларак, биредә нәкъ менә шушы басма мисалында тулы бер татар матбугатының язмышы турында сүз алып бара. Китапта ул бу хакта сүзен оптимистик рухта йомгакласа да, безнең сөйләшү барышында бу оптимизмга шиклерәк мотивлар өсталде. Бигрәк тә – минем тарафтан, бигрәк тә оптимизмның оптимизация төсмерен алуына мөнәсәбәтле рәвештә...

Китап фотоматериалларга бай, аларның уникаль җыелмасы буларак кына да, ул һәр татар интеллигентының китап киштәсендә урын алып торырга тиешле басма, дип бәяләнә алыр иде. Ә инде аларның һәрберсенең җентекләп тикшерелеп, барланып чыгуы – үзе бер олы эш.

Равил абый үзен кайчакта архивариуска тиңли, һәм тикмәгә генә түгел, чөнки ул үз язмалары, архивлары мәсьәләсендә дә гаять төгәл кеше. Моңа әллә ничә тапкыр шаһит булганым бар. Беренче шигыре кайсы елны, ничәнче айда, ничәнче числода һәм кайсы басмада басылып чыгуын, коридорда очратып сорасаң, чатнатып әйтеп бирер!

60нчы елларда әдәбиятка килгән шагыйрьләр. Сулдан уңга: Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим. 1971 ел.

PRESSA.RU

Бер төркем татар язучылары Васильево ял йортында. Беренче рәттә (сулдан уңга): Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Муса Җәлил, Әхмәт Фәйзи; икенче рәттә: Әхмәт Исхак, Шәйхи Маннур. 1940 ел.

– Фотоларны архивларда утырып, редакцияләрдән җыеп алу – бер хәл, Равил абый. Алардагы шәхесләрне, урын-вакыйгаларны барлау – менә анысы четерекле...

– Яшьрәк буын вәкилләре аларда сурәтләнгән шәхесләрнең күбесен инде белми дә. Шуңа да аларны җыеп, туплап калдыру – шулай ук намус эше. Без үткәнебезне белергә тиеш... Заманында Рафаэль Мостафин бик яхшы белә иде фотоархивларны. 70нче еллардан башлап, фотоларны Лирон Хәмидуллин да белә. Литфондта эшләгәч, ул күп нәрсәләрдән хәбәрдар.

– Равил абый, китап язучыларның оешмасы турында булса да, әдәби барышны барыбер дә кешеләр билгели. Әдипләрнең иҗаты, әхлакый йөзе, эстетикасы, аңлашыла ки, чордан-чорга үзгәреп килгәндер. Моны тоймый калмагансыздыр...

– Мин үземне бәхетле кеше саныйм – инде менә өченче буынны күздән кичерәм һәм өч буын иҗат әһелләре белән аралашам. Бу бит һәркемгә тәтеми! Нәкый Исәнбәт, Бакый Урманчелар, мәсәлән, XIX гасырда туган кешеләр иде. Мөхәммәт Мәһдиев, Гомәр Бәширов, Гариф Ахунов, Сибгат Хәким, Хәсән Туфаннар – XX гасырның йөзен билгеләүчеләр, безнең остазлар. Аннары инде – үз буыным, 60нчы елгылар. Һәм менә – сезнең буын. Инде дүртенчесе икән, кара син...

Һәр буында шәхеснең төрлесе булган. Язучының әхлакый-мораль йөзе чор белән билгеләнми. Яшь белән дә... Шуны гына әйтә алам: безнең арада бик вак, шәхси мәнфәгатьләр белән генә йөрүче, арзанлы кешеләр үрчеде соңгы вакытта. Ә әдәбиятны андый кешеләр белән үстереп, алга җибәреп булмый.

– Китапны әзерләгәндә, иң кыены нәрсә булды?

– Бернинди кыенлык та булмады. Мин бу эшне яратып эшләдем, кирәк дип эшләдем, үземә күп нәрсә кызыклы иде.

– Һәм соңгы сорау: ни өчен китап берничә телдә басылмады? Ул рус укучысы өчен дә кызыклы булыр иде, миңа калса.

– Шундый гыйбарә бар бит: өйдәге чүпне тышка чыгармыйлар. Безнең тарихыбызда да әнә шундый «тышка чыгармый» торган сәхифәләр бар. Бу басма әлегә – «өебездәге кулланылыш» өчен. Алга таба ул татар, рус, инглиз телләрендә дә басылачак, насыйп булса. Башка телләргә тәрҗемә ителеп, ул инде буклет буларак чыгар, дип көтелә. T

Кол Галигә һәйкәл.

ГОМЕР БОҖРАСЫ

МОҢСУ ХИКӘЯ

Язучы, шагыйрь, драматург, әдәбият галиме Галимҗан Гыйльманов февраль аенда үзенең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Бу күркәм дата уңаеннан журнал укучыларына аның бер хикәясен тәкъдим итәбез.

Автор:
Галимҗан Гыйльманов

***

Әмирҗан карт бүген дә көнен трамвайда үткәрде. Гүя шунда туды, шунда гомер кичерде, шунда соңгы сулышын алды... Гомеренең соңгы елларын ул шулай трамвайларда яшәп үткәрә: иртә белән беренче очраган трамвайга кереп утыра, кичке эңгер төшкәндә генә кайтып китә. Аңа инде трамвай йөртүчеләр дә, кондуктор-контролерлар да, хәтта трамвайда йөрүче халык та күнегеп беткән. Утлы чыбыкларга тотынып йөрүче бу тимер арбаның бер бик кирәкле әйбере кебек ул хәзер.

Баштарак бик шикләнгәннәр иде. Ялынып-ялварып та карадылар, тиргәп, ачуланып, куып та чыгаргаладылар. «Террорист-мазар түгелме?» – дип, милицияләр дә тикшереп китте. Үз сәерлеге белән Әмирҗан карт күп кешенең канына тоз, җанына борчу салды. Монысы хак.

Җәйге кич озын. Кайтырга җыенып беткәч тә шактый йөрде әле бу Хода бәндәсе трамвай боҗрасын әйләнеп. Аның күңеле инде күптән сизенә: кичкә таба трамвай юлы озынайган кебек була. Еш кына күңеленә: «Бу юлы ахырга кадәр барып җитә алмас микәнни?» дигән курку да керә.

Әмирҗан картның «гомер боҗрасы» белән дә нәкъ шулай: барасы җир якынайганнан-якыная, ә барыр юл озынайганнан озыная...

Аның бүгенге сәер язмышына алып кереп киткән гомер юлы нәкъ шушы урында – «икенче» трамвайда, шәһәрнең үзәк мәйданында урнашкан тукталышта башлана. Шунда тәмамланачак та. Ул моны төгәл белә. Инде менә ничәмә-ничә еллар әйләнә дә килә шушы урынга, әйләнә дә килә... Нәкъ шушы урында ул үзенең мәхәббәтен, язмышын югалтты. Моннан бик күп еллар элек шушы трамвай боҗрасында басып калган иде аның Әминәсе... «Иртәгә шушы урында көт, яме», – дип елмаеп карап калган иде...

Алар бер-берсен ике генә көн белеп калдылар. Шушы «икенче» трамвай баскычында таныштылар. Ачык трамвай ишегеннән күбәләк кебек очып килеп кергән ул кызны Әмирҗан көтеп алган кебек каршы алды. Кыз да, кыенсынып тормады, Әмирҗанның кочагына керердәй булып, янәшә менеп басты. Аннары егеткә акча сузды:

– Билет алып бирегезче, зинһар...

Бирмиме соң!.. Әмирҗан йөрәген биреп калдырырга да әзер иде бу мәлдә. Ул билет алып бирде бирүен, әмма авыз ачып сүз әйтә алмады, кыюлыгы җитмәде. Кызның ал билбаулы озын ак күлмәге дә, озын, саргылт толымнары да, зәңгәр күзләре, бер караудa әсир итә торган шаукымлы-нурлы карашлары да нindидер башка дөньяныкы иде. Әмирҗан әлегә бу дөньяны белми, аның әле чынлап гашыйк булганы, яратканы юк...

Берничә тукталыштан соң кыз, ничек очып кергән булса, шулай ук очып төшеп тә калды. Ул чыгып китүгә трамвай эчендәге нур балкышы да сүнде, югалды... Бу фәрештә затының нурлы чагылышы Әмирҗанның күңелендә, язмышында калды...

Әмирҗан икенче көнне дә, вакытын туры китереп, «икенче» номерлы трамвайга утырды. Тагын килеп кермәсме кичәге бәгырь кисәге?

Керде шул! Әнә ул – озын итәкле ак күлмәген җилфердәтеп, очыпмы-оча! Шулай очып-очып килде дә ачык ишектән трамвай баскычына менеп тә куна-кладыy... Әмирҗан чак кына кулын биреп өлгерде... Ярый әле өлгерде, кыз артыннан ук ишекләр ухылдап ябыла да башлады... Егет көчле куллары белән аны үз кочагына тартып алды...

– Рәхмәт... Гафу итегез, мин сезгә җайсызлыйм бугай...

– Юк-юк, миңа бик уңай...

Кеше күплегенә сөенеп бетә алмады Әмирҗан. Башка вакыт булса, бөтен дөньясын битәрләп, бу кысанлыкка үртәлеп барыр иде. Бүген исә аңа халык белән дыңгычлап тутырылган трамвай моңа кадәр таныш булмаган сихри тойгылар бүләк итте.

– Сез... Сез...

– Әминә минем исемем....

– Мин – Әмирҗан. Сез... Әминә... укудан чыктыгыз бугай?..

– Юк, мин укырга барам гына әле. Ә Сез?

– Мин инде укуны бетердем... Төзелеш институтында... Ә Сез кайда укыйсыз?

– «Мед»та. Менә практика тапшырырга барам...

– Ә иртәгә... иртәгә укыйсызмы? – Әмирҗан, ниндидер бик кыйммәтле әйберен югалтудан курыккандай, әйтеп калырга ашыкты: – Әйдәгез иртәгә дә шушы урында очрашабыз!

– Мин риза! Тик... шаяртканны яратмыйм мин...

– Ә мин шаяртмыйм. Кемдер Сезне трамвайда каршы алырга тиештер бит инде... Ул кеше мин булсам, Сез ризамы?

Икесе дә елмаештылар. Бер-берсенең күзләренә карашып, бермәл тын тордылар... Аннары Әминә Әмирҗанның күңеленә мәңгелеккә уелып калачак сүзләрне әйтте: «Иртәгә үзебезнең тукталышта көт, яме...»

– Ә практика?

– Бүген соңгы көн. Аннары – каникуллар!..

Балаларча кул чәбәкләп алган Әминә тагын да балкып, яктырып китте. Аның самими карашында: «Миңа күренмичә кайда йөрдең син моңа кадәр?» – дигән сорау чагылып узды...

Бу – аларның чын-чынлап беренче һәм соңгы очрашулары булды..

Әмирҗан карт хәтер шаукымыннан айнып бүгенге көнгә кайтканда, трамвай Тукай мәйданындагы «боҗра»га якынлашып килә иде. Бу тукталышка җитәрәк ул аеруча җитдиләнә, җыерчыкка баткан йөзе тартылып, яшәреп китә, аның караве, һәрвакыт дымланып торган күзләре тагын да әчкәрәк батып китә. Бу минутларда аның йөрәге ешрак, ярсыбрак тибә, карашына өмет, рухына егәрлек иңә...

Мондый вакытларда трамвайдагылар да, картның халәтен сизенеп булса кирәк, кинәт тынып, басылып калалар. Пышылдап кына билет сорыйлар, ымлап кына сөйләшәләр... Трамвай тикле трамвай да акрыная, рельсларына йомшаграк басарга тырыша... Шулай алар барысы бергә ниндидер хикмәтле мизгелгә, тылсымга, сергә якынлашалар...

PRESSA.RU

Әмирҗан карт ул «тылсым»ны беренче булып күрде. Бозраның Тукай мәйданына килеп кергән өлешендә япа-ялгызы басып тора иде ул сихри зат. «Әминә! Әминә?.. Әминә...» Ян тәрәзәгә укталып, урамдагы һәр кешегә төбәлеп карап барган карт, яшьләрчә дәррәү калкынып, торып басты. «Әминә?!. Син бит бу!..» Аның язмыш аһы булып яңгыраган, ишетелер-ишетелмәс кенә әйтелгән сүзләрен тирә-юньдәге халык шунда ук ишетеп алды, бер-берсенә пышылдашып, бу хакта трамвай йөртүчегә хәбәр җибәрде.

Трамвай, гомердә булмаганча, урам уртасында тукталып калды. Аның белән бергә дөньядагы хәрәкәт, тормыш тукталды. Гүя кешелекнең «яшәеш бозрасы» кучәреннән чыкты, кендегеннән ычкынды... Бераздан шаулап ачылган ишекләр белән бергә тагын тормыш башланды, «яшәеш бозрасы» үз кучәренә керде... Вагон эчендәге халык, як-якка тайпылып, Әмирҗан карт утыргычыннан ишеккә кадәр юл ачты. Бу гаҗәеп хәлнең шаһиты булган адәм балалары, бер мизгел эчендә бөтен булган гөнаһларыннан, керләреннән, гамьнәреннән арынып, иманнарына, хәтерләренә, хыялларына кайттылар... Дөньяга изгелек иңгән мәл иде бу...

Әмирҗан карт, тәрәзәдән күзләрен алмыйча гына, әзерләп куелган аралыктан ишеккә таба китте. Ишек катына җитәрәк сөрлегә язды, аның илаһи дулкынланудан җиңеләеп калган гәүдәсен көчле куллар тотып алды, шул килеш, күтәреп диярлек аны урамга чыгарып куйдылар...

Менә ул бервакыт, юл өстендә туктап калган трамвайга карап, нишләргә белмичә аптырап торучы кыз каршында пәйда булды.

– Әминә!..

Озын итәкле ап-ак күлмәк кигән, саргылт чәч толымын түш өстенә салган, якты йөзле, зәңгәр күзле кызый исә, әллә трамвай тәрәзәләренә ябырылып, ишек баскычларына асылынып карап торган кешеләрдән куркынып, әллә бөтен йөз-битен җыерчык басып та мөлаемлелеген югалтмаган сәер карттан шикләнеп, читкәрәк тайпылды.

– Әминә! Әминә...

Кызның гаҗәпләнүдән зур булып ачылган зәңгәр күзләрендәге куркуны бераздан кызыксыну алыштырды. Ул хәтта тыйнак кына елмаеп куйды:

– Бабай, Сез ялгыштыгыз. Мин бит Әминә түгел...

– Әминә, нишләп Әминә булмасын?.. Менә бит – күлмәгең дә шул, чәчләрең дә... Үзең дә...

– Күлмәгемне әбием тектерде, сиңа килешә, диде... Чәчләремне дә әбием үрде... Бабакай, Сез мине кем беләндер бутыйсыз...

– Беркем белән дә бутамыйм... Син бу, син, Әминә... Оныттыңмы әллә? Кичә без шушы урында очрашырга сүз куешкан идек, исеңдәме?

– Сез ялгышасыз, бабакай. Мин беркем белән дә очрашырга сүз куешмадым. Кичә мин әбием белән зиратка бардым, бабам каберенә чәчәк салдым, аннары туганнар каберлегендәге исемлек янында тордык, таныш исем эзләдек... Аның яшьлектә сөйгән егете сугышта үлеп калган... Алар очрашырга сүз куешканнар, ә егете килмәгән, ул көнне сугыш башланган... Әбием әйтә: «Сугышка китмәгән булса, килер иде, сугышта үлмәгән булса, табар иде», – ди...

Каушавыннанмы, үзенең Әминә түгеллеген ничек тә расларга теләпме, тотлыга-тотлыга кичәге хәлләрне тәфсилләп сөйләргә керешкән кызны Әмирҗан карт күңел иңрәве белән бүлде:

– Әминә!.. Әминә... Ни сөйлисең Син? Менә бит мин – исән! Менә без икебез дә исән-сау! Мин сине күпме эзләдем, Әминә!.. Менә таптым... Нигә танымаган буласың, ник шаяртасың?

– Шаяртырга уйлаганым да юк. Бабакай, мин Әминә түгел! – Шунда кызга әллә нәрсә булды. Ул, кинәт тотлыгып, тукталып калды. – Бәлки Сезгә минем әбием кирәктер? Менә ул Әминә исемле. Ә, бабакай?

– Нинди әби? Нинди Әминә? Миңа син кирәк, син минем Әминәм... Әйдә минем белән... Мин сине шулкадәр озак эзләдем...

Кыз инде дәшми. Күк кебек зәңгәрсу, саф күзләрен тутырып, елардай булып карап тик тора. Кай арададыр картның кытыршы учларына барып кергән йомшак, зифа кулларын тартып алырга да кыюлыгы җитми аның.

Авыр хәлдән аларның икесен дә трамвай халкы коткарды. Бу ике Хода бәндәсен кай арада гына уратып-сырып алганнар диген!..

– Әмирҗан бабай, әйдәгез, утырыгыз трамвайга... Табылыр эзләгән кешегез, бер табылмаса, бер табылыр... Охшаган кешеләр күп бит алар, Сезнеке дә табылыр... Әйдәгез инде утырыйк – әнә, бөтен юлны каплаганбыз, болай ярамый бит...

Бер һаман әле зиһенен җыя алмыйча газапланган кызга, бер каршысында өзгәләнеп ялваручы кондуктор хатынга карап торганнан соң, Әмирҗан карт трамвайга утырырга булды. Менә ул, сөялгә каткан учларыннан кызның мамыктай кулларын теләмичә генә бушатты да, кырт борылып, трамвай ишегенә юнәлде. Ул арада баягы көчле куллар аның җиңел гәүдәсен ике яктан җәһәт кенә эләктереп, күтәреп диярлек трамвай ишегеннән алып кереп киттеләр, үз утыргычына илтеп куйдылар...

Картның һаман әле урамдагы тылсымнан аерыласы килмәде. Тәрәзәгә төбәлеп баккан килеш, ул һаман сөйләнде, үгетләде, ялварып-ялварып кызның кичерүен сорады... Ләкин: «Нәрсә булды бу?» – дип, һаман әле урам уртасында кымшанмый басып торган кыз аның сүзләрен ишетми иде инде...

– Әминә... Ачуланма миңа...

***

Мин ул вакытта килә алмадым... Каһәр төшкере сугыш башлану белән, икенче көнне үк фронтка киттем... Өйгә килеп алдылар... Ачуланма миңа, Әминә, мин Синең алда бик гаепле...

Трамвай эчендә сәер тынлык урнашты. Замана арбасы, гүя, бу юлы рельслар буенча даңгыр-доңгыр шуышып бармый, бәлки тавыш-тынсыз гына оча... Аның белән бергә трамвайдагы халык оча, үз хыялларында, уй-хатирәләрендә оча, язмыш орбиталарында, гомер бозраларында очып йөри...

Әмирҗан карт та оча. Ул инде тынычланган. Берни дәшми-нитми, башын аска игән дә, йокымсырап тик бара.

Юк, ул йокламый. Ул уйлый. Бу хакта бөтен трамвай халкы белә. Бу хакта бөтен дөнья белә...

«Ник танымадың мине? Мин бит шундый көтеп алдым бу очрашуны!..

Ә син шундый ук яшь, чибәр, газиз... Ә үзең миңа «бабай» дисең... Әйе шул, мин инде озын гомер яшәдем. Сине эзли-эзли картайдым... Шуңа да син миңа үз әбиеңне димлисеңдер... Сиңа охшаса, ул да чибәрдер... Синең әбиең дә минем яшьтәдер... Ә бәлки, мин эзләгән кеше – синең әбиеңдер?.. Ул да «Әминә» исемле бит... Йа Хода! Шул, шул бит минем Әминәм! Ә син, син, кызый, аның оныгы гына!..»

Бу көтелмәгән ачыштан Әмирҗан картның йөрәге, тибүдән баш тарткандай, кысылып, сыкранып куйды. Әмма бераз чыгымчылап торганнан соң, тагын ашыгып йөреп китте. Чөнки ул белә: тукталырга ярамый! Хәзер бигрәк тә ярамый! Алда яңа гомер бозрасы көтә. Бу гомердә аның яшьлек мәхәббәте – Әминәсе бар, Әминәсенең оныгы – мөлаем йөзендә, зифа буй-сынында, игелекле холкында әбисенең яшьлек образын йөртүче оныгы бар! Аз гына мәшәкатьләнергә туры киләчәк килүен: шушы иге-чиге булмаган трамвай бозрасында ничек тә эзләп табарга тиеш ул аларны. Шул гына!

Александр Щепалин рәсеме.

PRESSA.RU

МОРТ

«Татарстан» журналы, кызыклы атамалы татар авылларын, аларның тарихын һәм бүгенге яшәешен яктырту максаты белән, яңа сәхифә башлады. Сез дә безгә үз авылларыгызның хикмәтле яклары, гыйбрәтле хәлләре, уңган-булган кешеләре турында яза аласыз.

Апас районы Аю Көйдергән авылы

МОРТ ДИГӘН ЙОРТ

Морт исемле авыл Татарстанда берәү генә. 10 ел дәвамында район үзәге булып торгангамы, халкы хәзер дә урамга чыкканда да шәһәрчә бизәнеп-ясанып, итек-читекләрен чистартып, матурланып чыга. Ипигә генә килгән идем, дип, халаттан йөрүче бер генә әбекәйне дә очратмассыз. Урамнарында чүп ташлар өчен махсус савытлар куелган. Ә кешеләре бик ачык, кемгә генә сугылсаң да, чәй эчерми чыгарып җибәрмәсләр...

Автор:
Гөлүсә Закирова

БИГӘЙ БАТЫРЛЫГЫ

Морт авылының беренче урыны урман буендагы Мәмет елгасы тирәсендә булган. Явыз Иванның чукындыру сәясәтеннән качып, бирегә күченгәннәр. Урманның арьягында чукындырылган татар авыллары бар: Айталан, Февраль, Елово… Рус баскакларын авылга кертмәс өчен кырыкмаса кырык сәбәп уйлап таба белгән Морт кешеләре. Болай дип тә сөйлиләр: «Пәһлевандай батыр Йозәй һәм Бигәй бабалар, сыерларын кызганмыйча, суя һәм Армалы авылы башына чыгып, учак тергезә. Казан асып, шул ит белән чукындыру сәясәте алып барган урыс миссионерларын шәп итеп сыйлыйлар. Аннан сый-хөрмәттән шактый йомшарган урысларны: «Бу тирәдә чукындырырга яраклы татар авыллары юк», – дип башларын бутап, икенче юнәлештә борып җибәрәләр».

Бигәй батырның даны Казанда да билгеле була. Шәһәр Сабан туенда ел саен батыр кала ул. Аңа каршы чыгарга берәү дә батырчылык итми. Шунда татар байларыннан берәү, күп җирләрен һәм кызын бирергә вәгъдә итеп, бер урысны Бигәй батыр белән бил алышырга күндерә. Көрәш каты була, шулай да урыс җиңелә. Бай вәгъдәсендә тора. Бигәй батырның Чулман елгасын аркылыга йөзеп чыгуы турында да риваятьләр бар. Сабан туенда җиңелүче көрәшче генә аны гафу итә алмый, Чулманда йөзгәндә көймә белән килеп, батырны батырып үтерә.

УМАРТАЛАР МУРТАЙГАН

Мәскәүдәге Борынгы актлар дәүләт архивында сакланган XVIII гасыр документларында авыл Март исеме белән теркәлгән. 1795 елда аның 42 хуҗалыгында 102 ир-ат, 78 хатын-кыз исәпләнә. 1612 дисәтинә 1829 сажин җирләре була. Авыл янәшәсендә Морт һәм Киленбиегән елгалары җәйрәп ята. Малмыждан Алабугага китә торган олы юл үтә. Чыршылы елгасының уң, Акай елгасының сул ярларында, Мәмет, Бурсык, Морт, Киленбиегән елгаларының ике ярында да чишмәләр челтерәп ага. Морт һәм Чыршылы елгаларында берәр тегермән урнашкан, янәшәләрендә берәр амбар бар. Басуларында арыш, арпа, солы, бодай, карабодай, борай үстерәләр, туфрагы соры комлы. Печән җирләре шулай ук уңдырышлы. Халык казна крестьяннары санала, басуда хезмәт итүдән бушаган арада йон эрли, киндер тетә, постау суга.

Урманнары бай: чыршы, ак чыршы (пихта), усак, юкә, өрәңге, каен, миләш, шомырт үсә, аю, бүре, төлке, сусар, ас кебек җәнлекләр, көртлек, бөркет, карчыга, бożыр, карга, чыпчык кебек кошлар тереклек итә. Елгаларында чуртан, алабуга, жумба (налим), шартлака, чабаклар бар.

Морт атамасын авылда төрлечә аңлаталар. Элек-электән авылда муртайган тупылларның күп булуы бу исемнең килеп чыгуына этәргәндер.

Авыл сазлык урынында утыра. Ә тупыллар сазлыкны киптерә, аны шуның өчен утыртканнар да. Профессор Гомәр Саттаров «Татар исемнәре сүзлеге»ндә, Морт сүзенең мәгънәсе мәңге яшел үсемлекне аңлата, дип яза. Монгол телендә «маритой» дигән сүз дә бар, анысы ат менәр җайдак мәгънәсендә йөри. Авыл исеме «умарта» сүзеннән дә алынган булырга мөмкин. Морт урманнарында кыргый умарталар күп булган, хәзер дә кыргый бал кортларына капкын кую гадәте бар. Географик урнашуы белән бәйле тагын бер аңлатма бар: морт – тирән күл дигәнне дә аңлата, удмуртларның «мур», «мурдала» сүзләре тирәнлеккә ишарәли. Ә коми халкы бу сүзне кешелеклелек төшенчәсе белән бәйли.

Фотолар автордан алынды

PRESSA.RU

АХУН ХӘЗРӘТ

Хәбибрахман Мәсәгутов – XX гасыр башында Морт авылының бик дәрәҗәле имамнарыннан була. Хәтта үзенең мөһере дә булган, анда «Ахун» дип язылган, диләр. Дәүләт Думасының III һәм IV чакырылышы депутаты. Талканы коры була ахунның: «Җыр-бию, күңел ачу, музыка Коръәнгә каршы килә, җырлаганчы Аллаһка табынсагыз иде», – ди. Кичләрен «ау»га да чыккалый. Мәче кебек сак кына адымнар белән килә дә, күңел ачкан яшьләрнең башларын, җилкәләрен йодрыклары белән төя икән. Баһадирларча таза гәүдәле хәзрәткә каршы торырлык кеше табылмый.

Морт авылы 1914–1917 еллардагы канлы вакыйгалар шаһиты да була. Дәһшәтле елларда Токмашканың 31 кызылгвардиячесе, Яңа Гришкин һәм Танайка дружиначылары, Морт активистлары революциягә җаннары-тәннәре белән инана һәм аны яклап һәлак була. Кешеләрне терелэй күмүләре, «Үлем баржасы»на ябулары, асулары, атулары турында уйларга да куркыныч.

1917 ел башы. Юеш окопларда өч ел аунап, кичәге иптәшләренең үле гәүдәләре аша атлап йөдәп беткән, яраланган госпитальләрдә дәваланган фронтовик Фәхри Моратов туган авылы Мортка кайтып төшә. Ул вакытта авылда фронттан кайтучылар шактый була. Кичләрен җыелып, төрле мәсьәләләр турында сүз йөртәләр. Байлар да тик тормый. Алабугадан революциягә каршы фикердәге 230нчы запас полктан 20 солдатны алып кайталар. Төне буе эчеп, исерешеп беткәч, активистларны эзәрлекләргә керешәләр. Башта Хөсәенов йортына керәләр, аны үтергәнче кыйныйлар. Моратовны да тотарга уйлыйлар. Әмма ул Алабугага качып китә. Ләкин аның кайдалыгын белеп, кыйнап Мортка алып кайталар. Башка активистларны да кулга алалар. Кайберләрен шунда ук кыйнап үтерәләр. Моратовны исә шәһәр ягына алып китеп атарга боера унтер-офицер. Кече унтер каршы килә, халыкны җыеп, авылдашлары алдында атабыз, ди. Иртәнгә кадәр калдыралар, кыйнап, Земство йортына кертеп биклиләр. Шунда ул тагын биш иптәшен күрә. Берсе үлгән булып чыга. Ике исерек солдат кереп ике иптәшен атып үтерә, Моратовка төбәгәч, фронтовик ачуыннан мылтыкны тартып ала, мылтык түтәсе лампага бәрелә һәм ут сүнә. Шуннан файдаланып, Фәхри чыгып кача. Авылдашлары ярдәме белән хатын-кыз булып киенеп, башына яулык бәйләп авылдан юк була.

АЗИН ҮЗЕ ТУКТАП ТОРГАН

1918 елның июлендә авылга колчаклылар килә. Мамадыш ягыннан Кызыл Армия һөҗүмгә күчә. Менә 1885 елгы Миңнеҗамал әби истәлекләре: «Аклар авылга Акай тау башыннан төштеләр. Мәметтә туплар шартлады, бөтен җир дөңгер-дөңгер килеп торды. Ату тавышлары ишеткәч, авыл халкы кем арба өстерәп, кем атка утырып Юрашка киттек. Гатаулла бабагыз Миңнегул Фатыйхы белән качып, Алабугадан түшләре белән шуышып кайтканнар. Бабагыз: «15 чакрымда бер авыл бар, туплар шартлый башлагач, гаиләне шунда илткән идек, хәл белергә бардык», – дип котылган. Кайткач, ике көн Саттар Саҗидәләренең атлар өе түбәсендә качып ятканнар. Моксиннар акларга бал ташыган».

Морт авылы аша Азин отрядлары уза. Земство йорты каршында Азин үзе дә тукталып торган, диләр. Күп кенә мортлылар Азин отрядына да кушыла.

1920 елда авылда хәтәр ягын чыга. Ефәк Фатыйхның анасы: «Ипи пешергән идем, пеләчә белән чүп түккән идем», – ди. Чүп урынына утлы көл түккән була шул. Янгын шактый йортның башына җитә.

СТАЛИН ГАБДЕЛБӘР

1929 елда Мортта авыл хуҗалыгы артеле оештыралар. 8 март көнне артельнең беренче гомуми җыелышы була. Халыкара хатын-кызлар көне булганга, күмәк хуҗалыкны да «8 Март» исеме белән йөртә башлыйлар. Һәр гаилә 3 сум акча һәм чәчүлек орлык бирә. Атлар, дирбия, сукалар гомуми милеккә әйләнә. Беренче рәисе – «егермебишмеңенче» Фома Тихонов. Берничә ел эчендә хуҗалыкта алма бакчасы утыртыла, балык күле ясала, ат заводы төзелә, тимерче Газизулла Гобәйдуллин болында үлән үстерү өчен су сиптерү җайланмасы төзеп куя. 1933 елда дуңгыз фермасы төзелә. Бу елда зур уңыш алалар: бөртеклеләрнең гектарыннан – 15–16 ц, бәрәңгедән – 205 ц. Һәр хезмәт көненә, ниһаять, колхозчыларга 8әр кило ашлык, яшелчә, 200 г бал бирелә. Колхозда бер яшелчәчелек, бер төзү бригадасы оештырыла.

Шул ук елны Казанда колхоз ударникларының I съездына Ибраһим Йосыпов белән Саҗидә Биктаһировaларны җибәрәләр. Съездда Михаил Калинин да чыгыш ясый. Аннан кайткач, авылдашларының: «Сталинны күрдеңме?» – дип сораштыруларына, «Күрдем, күрдем», – дип шапырына Ибраһим абзый һәм аңа «Сталин» кушаматы ябышып кала...

САМОЛЕТКА АКЧА

Сугыш вакытында хөкүмәткә көн саен 30 ат йөге ашлык озата «8 Март» хуҗалыгы. 1942 елның 10 декабрендә колхозчылар Ватанны саклаучыларга авиаэскадрилья төзергә алына. Бу максатларда халыктан 150 мең акча җыялар. Ул чакта бер пот (16 кг) икмәк бер мең сум тора. Районның «Сталин юлы» газетасы бу хакта язып та чыга: «Тимерче Гобәйдулла Газизуллин үзенең хезмәт хакыннан самолет төзергә 50 мең сум акча кертте. Ул: «Минем ике улым фронтта, фашистларга каршы көрәштә, читтә кала алмыйм», – ди...»

Гобәйдулла абзый кызы Ләбибә апа Мусина бу хакта истәлекләре белән уртаклаша: «Әтием үзебезнең келәттә нәрсә бар, барысын тәяп, бер арба ашлык алып китеп, он итеп тарттырып алып кайтты бер көнне. Эшләп тора бит, ашлык килә тора. Шулай итеп, 50 мең акча белән кайттылар. Тәрәзәләрне одеаллар белән капладылар да идәндә акча санарга керештеләр. Бер-ике төн кунды әле ул акча өйдә. Аннан аны авыл советына төшереп бирделәр».

ПУЛЯ ТИШКӘН МЕДАЛЬ

Ә менә Хөсәен Шәрифуллинның «Сталинград оборонасы өчен» медале үзе бер тарих. Сталинградны саклаганда ул хезмәт иткән бер төркем солдатлар Идел аша кичәргә тиеш була. Дошман пулясы астында көймәләргә төялеп юлга кузгалалар. Янәшәдә генә йөзгән көймә, бомба эләгеп, су астына китә, анда Хөсәеннең якташлары да була. Аннан Сталинград урамнарында сугышлар дәвам итә. Само-

леттан ташлап киткән азык-төлекне дә алып булмый: снайпер чүкеп кенә тора. Менә шулай кайчандыр хуҗалар чыгарып түккән бәрәңге кабыклары, элмә кайрылары ашап, алты ай сугыша алар. Оборонаны өзеп чыккач, сакал-мыек баскан, йончыган солдатларны медаль белән бүләклиләр. Аннан тагын сугыш, тагын атака. Дошман пулясы Хөсәеннең күкрәгенә төбәлә. Әмма яңа гына таккан медаль аның гомерен саклап кала. Пуля тишкән медаль бүген мәктәп музеенда саклана.

«АПА, БИР МИНЕКЕ АШАРГА...»

1942 елда Мортка ленинградлылар килә. 350 бала һәм 25 олы кеше. Алар Ленинградның 300, 320, 321нче интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләр була. Алар арасында табибә Елена Рамбольская һәм аның кызы Лариса да була. Лариса Рамбольская, сугыш бетеп, туган шәһәренә кайтып киткәч тә, озак еллар дәвамында Морт халкы белән аралашып яши. Болай дип хатлар яза ул: «Ул чакта, җәннәткә юлыккандай булдык, тәрәзәләрдә утлар яна, берниндн снаряд һәм бомба тавышлары ишетелми. Әни табибә, авыл халкын да дәвалый, тирә-күрше авылларга да чакыралар үзен. Безне Зөләйха апаларга урнаштырдылар. 1943 елның кышы иде бу. Аннан аерым йорт бирделәр, без анда салкыннан бик интектек. Көннәрнең берендә Тайфә апа Әхмәтҗанова килеп керде дә, берни әйтеп тормый, әйберләребезне җыя башлады. Аннан үзенең өенә алып китте. Өч елдан артык яшәдек без аларда. Катык-сөте белән сыйлады, бәрәңгесен ашатты, бакчасында кыяр, кабак үстерергә рөхсәт итте».

Вакытлар үткәч, Морт урамында таныш булмаган бер кешегә игътибар итәләр. Ул кайчандыр биргә эвакуацияләнгән Анатолий Куликов була. Морт халкына менәниләр сөйли ул: «Без мең газаплар кичеп килдек. Өстә юка, барыбыз да җәйге аяк киеменнән. Морт кешеләре безне Алабугадан олаулар белән килеп алды. Үзләре белән туннар да алганнар. Аларга төренгәч, эреп йокыга киткәнбез. Безне мәчеткә урнаштырдылар. Иртән кая килеп эләктек икән дип, тәрәзәләргә ябырылсак, ишегалды тулы халык, безне кызганып басып торалар. Ятимнәр бит, күбебезнең әти-әниләре Ленинградта ачлыктан кырылган. Тора-бара татар сүзләре өйрәндек, бик ашыйсы килгәндә, берәр йортка керәбез дә: «Апа, бир минеке ашарга», – дибез. Беркайчан да буш чыгармадылар».

Морт зираты кырында Ленинградтан килеп, биредә вафат булган өч бала кабере дә бар. Алар янына мәрмәр ташны Морт мәктәбе укучылары колхоздан бәрәңге алудан килгән акчага куйдырган.

АТКАЗАНГАН ХИМИК

Морт мәктәбе – берничә буын химиклар тәрбияләгән мәктәп тә әле ул. Аның башлангычы дөньяга танылган уйлап табучы химик Тимерхан Әхмәтов белән бәйле. Әтисе – Габдулла абый, «8 Март» колхозы бригадиры, әнисе – гади колхозчы була. 1952 елда КХТИга укырга керә, авылдан килгән башка студентлар кебек ул да портта йөк бушатып тамагын ялгарлык акча юнәтә. Шунда салкын тидереп, урын өстенә егыла. Үпкәләре ялкынсынган егеткә укуны ташларга киңәш итәләр. Әмма ул барысын да шаккатырып, көрәш белән шөгыльләнә башлый һәм авыруын җиңә дә. Казанда гына түгел, Мәскәү шәһәрләрендә дә җиңеп чыга, спорт остасы исемен ала. Диплом алгач, башта туган авылы мәктәбендә укыта, аннан Бондюг (Менделеев) шәһәре химия заводында мастер булып эшли башлый. Цех җитәкчесе итеп билгеләнгәч, рационализаторлык идеяләрен тәкъдим итә башлый. Аеруча хлорид барий технологияләре кызыксындыра аны. Аның исемен Татарстанның уйлап табучылар һәм рационализаторлары Мактау китабына да кертәләр. Һава торышы нинди булуга карамастан, баллистик ракеталарга тиешле нокталарга элөгү өчен кирәк булган порошокны да ул җитәкләгән лаборатория җитештерә. Әлеге чимал контактлы линзалар өчен дә нигез булып тора. Күкерт катнашмасын өйрәнеп, Левенсон кебек инглиз галимнәре фикерләренә каршы килерлек ачыш: составында күкерт булган төзелеш чималларын кулланышка кертә. Сульфит һәм барий тозларын камилләштерү буенча да зур эш башкара. Илдә силикагель өчен мохтаҗлык тугач, анысында да Морт егете җитезлек күрсәтә, моның өчен СССРның атказанган химигы исеменә лаек була. Уйлап табулары өчен 80 патентка ия «СССРның атказанган уйлап табучысы Тимерхан Әхмәтов. Аның авторлыгындагы химия дәреслекләре дә югары уку йортларында популярлык казана.



Үзен хөрмәт иткән һәр авылның берәр, йә булмаса берничә кызыклы легендасы була. Аны сезгә авыл аксакалларыннан берәрсе энәсеннән җебенә чаклы сөйләп тә күрсәтәчәк әле. «Татарстан» әлеге хикәятләрнең барысын бергә тупларга һәм һәр санда үз укучыларына тәкъдим итәргә уйлады. Татарстан буйлап сәяхәткә чыгар алдыннан безне кайда нәрсә көткәнен дә чамаладык: су үгезен кайда очратырга була, кәләшләр авылы, хәтта ки кышкы су кызлары яшәгән авыллар да бар икән. Әйе-әйе, соңгылары Зөя һәм Чуртан елгалары кушылган урында яшиләр икән.

ТАТАРСТАН ЛЕГЕНДАЛАРЫ: КЫШКЫ СУ КЫЗЛАРЫ

Зөя утравының һәр ягы – су. Иксез-чиксез дәрьяда нишләп әле су ияләре булмаска тиеш, ди? Бу чыннан да шулай, дип раслыйлар утрауда яшәүчеләр. Дөрес, бу хәлләр бик күптәннән булган-булуын…

Бервакыт шулай ике гашыйк яр буйлап атлый икән. Икесе дә матурлар, яшьләр. Иртә таңда каяндыр кочаклашып кайтып киләләр, яшьләр бит, таң атканын сизми дә калганнар, күрәсең. Акрын гына атлыйлар икән болар. Шунда әйләндереп капланган көймәне абайлап алалар һәм ял итәргә утыралар, кояшның зур тәгәрмәч булып судан күтәрелгәнен күзәтәләр, янәсе. Егет кинәт кенә ыңгырашкан тавыш ишетеп ала. Хатын-кыз тавышы кебек. Сикереп тора егет, көймә артына күз салса, искиткеч гүзәл бер кыз комда ята, аңы юк кебек, ярты гәүдәсе суда үзенең.

Егет, кыз бата башлаган һәм көч-хәл белән ярга кадәр йөзеп килә алган, дип уйлап, ярдәмгә ашыга. Ә кыз кинәт башын күтәрә дә, озын керфекләрен сирпеп, төпсез яшел күзләрен мөлдерәтеп егеткә бага. Шулчак егеткә әллә ни була, ә тегесе, күз ачып йомганчы, суга чума. Үзе су астыннан егетне аякларыннан тарткандай була, һаман да шул карашы белән егеткә карый, кулларын суза, ыңгыраша. Егет аның артыннан юнәлә, кызның боздай салкын куллары егетне һаман үзенә таба сөйри…

Ул арада егетнең ярдагы сөйгәне дә үзен кулга алырга өлгерә: бәла килүен аңлап, билдән суга баткан ярын тартып ала. Су кызы моңа бик ачулана: егетнең сөйгәнен кинәт кенә эләктереп алып, суга алып кереп китә. Егетебез бары тик суны болгатып җибәргән балык койрыгын гына күреп кала.

Ул һушына килгәндә, сөйгәне дә, су кызы да инде юкка чыккан була. Йөзеп, чумып эзләп карый – беркемне дә тапмый. Кайгыдан исәрләнеп калган егет көн саен әлеге урынга килә, чакыра, ялвара – нәтиҗәсез. Бары тик ара-тирә генә балык койрыгы, суны дулкынландырып, егетне дулкынга коендырып, үтеп китә торган була.

Ул арада кыш та җитә. Кышын да яр буена килә егет. Һәм бервакыт ярда яшел күзле теге кыз күренә һәм аны үзе белән чакыра. Боз өстеннән икенче ярга чыгалар. Ә анда – мәгарә, су да катмаган, шунда бик күп су кызлары йөзә, көлешә. Егет алар арасында сөйгәнен күреп ала. Шатланып, аның янына ашыга. Тегесе көлә, кулларын аңа таба суза. Егетне эләктереп ала да суга тарта. Шуннан бирле егетне утрауда инде күрүче булмый. Ә су кызлары әле хәзер дә күренгәлиләр, ди. Кышны шул мәгарәдә кышлыйлар икән алар. Күрүчеләр булган үзләрен…

ИЛ ЮГАРЫЛЫГЫНДАГЫ МАЯК

Сергей Крайнов – соңгы сигез елда Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең алыштыргысыз җитәкчесе. Шушы еллар эчендә ул торак-коммуналь хуҗалыкның шактый катлаулы мәсьәләләрен уңышлы хәл итеп килә. Нигездә нәкъ менә аның тырышлыгы белән илебезнең башка төбәкләрендә бу тармак вәкилләре Татарстан торак инспекциясенең хезмәт нәтиҗәләреннән үрнәк алып эш йөртәләр. Февральдә Татарстанның баш торак инспекторы 60 яшен билгеләп үтә.

Сергей Крайнов – соңгы сигез елда Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең алыштыргысыз җитәкчесе. Шушы еллар эчендә ул торак-коммуналь хуҗалыкның шактый катлаулы мәсьәләләрен уңышлы хәл итеп килә. Нигездә нәкъ менә аның тырышлыгы белән илебезнең башка төбәкләрендә бу тармак вәкилләре Татарстан торак инспекциясенең хезмәт нәтиҗәләреннән үрнәк алып эш йөртәләр. Февральдә Татарстанның баш торак инспекторы 60 яшен билгеләп үтә.

Хөрмәтле Сергей Аркадьевич!

Татарстан Дәүләт торак инспекциясе коллективы сезне ихлас күңелдән юбилеегыз белән котлый. Һәрчак сау-сәламәт булыгыз, тормыштан канәгатьлек хисе тоеп яшәгез, энергиягез ташып торсын, якыннарыгызга да көч-куәт өстәсен!

Сез хезмәттә дә, тормышта да безнең өчен маяк булып торасыз. Сез тирән акыллы һәм кайгыртучан җитәкче генә түгел, ике баланы тәрбияләп үстергән бик шәп әти дә. Һәм сез шундый аталарча мөнәсәбәтне безнең тату коллектив белән идарә итүгә дә бик уңышлы күчерәсез.

Хезмәтегез, гаиләгез, дусларыгыз сезнең өчен һәрвакыт шатлык кына китерсен, ә уй-ниятләрегез җиңел генә чынга ашсын.

Белеп торыгыз, без сезнең өчен һәрчак таяныч булып калабыз!

Андрей Абриталин,
Самара өлкәсе Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе

Хөрмәтле Сергей Аркадьевич!

Самара өлкәсенең Дәүләт торак инспекциясе коллективы сезне юбилеегыз белән котлый!

Сергей Аркадьевич, сезнең нәтиҗәле хезмәтегез – республикада торак-коммуналь хуҗалык үсешенә керткән чып-чын саллы өлешегез.

Эшкә ихлас бирелгәнлек, үҗәтлек һәм алга куелган бурычларны үтәүнең иң нәтиҗәле юлларын эзләү торак-коммуналь хуҗалыкны үстерүгә юнәлгән күптармаклы эшчәнлегегездә Сезгә ярдәм итә. Гомер бәйрәмегез белән котлап, абруйлы, белемле җитәкче буларак, безнең белән уртаклашкан тәҗрибәгез, югары профессионализм, компетентлык өчен рәхмәт белдерәбез, чөнки Сез шул рәвешле безнең инспекциянең үсешенә дә бәяләп бетергесез өлеш кертәсез. Сезгә ныклы сәламәтлек, авыр хезмәтегездә тагын да зуррак уңышларга ирешүегезне телибез.

Сезнең белән нәтиҗәле хезмәттәшлегебез дәвам итәр дигән өметтә калабыз.

Али Җәбраилов,
Дагыстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе

Хөрмәтле Сергей Аркадьевич!

Сезне, Россия Федерациясе дәүләт торак күзәтчелеге органнарындагы иң югары профессиональлеккә ия җитәкчеләрнең берсен, олуг юбилеегыз белән ихлас күңелдән котлыйм.

Россиянең торак-коммуналь хуҗалык тармагында сез иң күренекле, үз бәясен алган белгеч булып торасыз. Хезмәт юлыгызда Татарстанның торак-коммуналь проблемаларын чишү өчен бик күп эш башкардыгыз. Сезне тәрбияле, принципиаль һәм белемле кеше буларак беләбез. Туып торган мәсьәләләрне хәл итүгә дәүләт күзлегеннән карап фикер йөртүегезне, оештыру сәләтегезне хөрмәт итәбез.

Сез Россиянең иң алдынгы дәүләт торак инспекцияләренең берсе белән уңышлы җитәкчелек итәсез. Сезнең һәм коллективыгызның хезмәте бәяләп бетермәслек, эш нәтиҗәләрегез илебезнең барлык торак инспекцияләре өчен дә өлге булып тора.

Тормышыгыздагы һәр туар көнегез оптимизмга, яңа идеяләргә һәм кызыклы очрашуларга бай, ә тормыштагы теләсә кайсы кыенлык та мизгел эчендә җиңеп узарлык булсын!

PRESSA.RU

ТАТАРСТАН

МИСС ТАТАРСТАН 2017
XIX

ТАТАРСТАН 2017
XIX

XIX

ТАТАРСТАН

Фото: Ната Смирнова



АЙ КӘЕФЕ: **ГҮЗӘЛЛЕК**

Бу айда «Татарстан» сүзенең синонимы гүзәллек булды. Әлеге лингвистик яңалык белән килешмәгәннәрне фотографыбыз белән бергә «Мисс Татарстан-2017» исеме астында үткәреләторган матурлык дөньясына чакырабыз. Гыйнвар ахырында «Пирамида» Кунакханә-күңел ачу комплексында XIX Республика матурлык конкурсының финалы узды. Матурлык бәйгесе финалында Байлар Сабасыннан 22 яшьлек Зөлфия Шәрәфиева җиңеп чыкты.

Ә бүген «Татарстан» журналы битләрен матурлауда ул гына түгел, башка гүзәлләребез дә катнаша: Татарстанның иң матур кызларына карап, сокланыгыз, алар белән горурланыгыз!

ХОЧЕШЬ ЗАРАБАТЫВАТЬ
С НАДЕЖНЫМ И СИЛЬНЫМ ПАРТНЕРОМ?
Входит в группу компаний
КОМОС ГРУПП
ГКЗ
ГЛАЗОВСКИЙ комбикормовый завод
СТАНЬ ДИЛЕРОМ
ГЛАЗОВСКОГО КОМБИКОРМОВОГО ЗАВОДА
В ЛЮБОМ РЕГИОНЕ РОССИИ!
ДИЛЕРАМ МЫ ОБЕСПЕЧИВАЕМ:
бесплатные образцы комбикормов
рекламный баннер на торговую точку
инструкции по кормлению и каталоги продукции
% скидки*
Позвони и уточни условия сотрудничества
+7 (912) 010-53-51, ljapushinds@kombi-korm.ru, www.kombi-korm.ru
* Подробности по телефону +7 (912) 010-53-51. Срок действия скидок до 31 декабря 2017 г.
Реклама